3° 2014

# ФӘННИ ТАТАРСТАН

КАЗАН

*Журнал «2014 — 2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**

МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ФӘТТАХОВ Э.Н., Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары — мәгариф һәм фән министры (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛЬОГЛУ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Мэдисон)

► **БАШ РЕДАКТОР**

Мөдәррис Харис улы ВӘЛИЕВ

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**

ГОМӘРОВ И.Г., ДӘҮЛӘТШИНА Л.Ш. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**

ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХАЕВ Р.Ф. (тел белеме), БӘДЕРТДИНОВА Л.Ш. (әдәбият һәм халык иҗаты),
ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ Д.Р. (фәлсәфи фикер)

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**

Я.М. АБДУЛКАДЫЙРОВА, Н.Т. АБДУЛЛИНА, Г.Р. ХӘКИМОВА

## БУ САНДА:

### • ТЕЛ БЕЛЕМЕ


*Д.Б. Рамазанова.* Татар тарихи лексикологиясенә материаллар: Америка индеецлары телендә төрки сүзләр ........ 5

*И.Б. Бәширова.* Татар телендә сүзнең лексик мәгънәсе һәм лексик-семантик төзелеше ........ 17

*Ф.Ә. Ганиев.* Кушма фигыльләр — лексикабызның зур байлыгы ........ 25

*М.М. Шәкүрова.* Татар халык әкиятләре һәм бәетләренең лексик-семантик һәм стилистик үзенчәлекләре ........ 32


### • ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ


*Д.Ф. Заһидуллина.* Роберт Әхмәтҗанов иҗаты: абстракт образлылык ........ 41

*Ф.Ф. Хәсәнова.* Зиннур Мансуров иҗатында Тукай темасы ........ 55

*Ә.Н. Нәҗипова.* Әдәби әсәр һәм халык җырлары ........ 59

*Ф.Х. Миңнуллина.* XX гасыр ахыры — XXI гасыр башы татар драматургиясендә фаҗигалелек (А. Гыйләҗев һәм М. Гыйләҗев пьесалары мисалында) ........ 63


### • ХАЛЫК ИҖАТЫ


*И.Г. Закирова.* В.В. Радлов хезмәтендәге бер әкият турында ........ 68

*Д.Ш. Гыйльманов.* Сөембикә турындагы фольклор әсәрләрендә мәхбүслек мотивлары ........ 76


### • ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ


*Ә.К. Бустанов.* Изге шәҗәрәләр һәм төньяк Евразия мөселманнарының регионара элемтәләре: XVII—XX гасырларда Шиховлар гаиләсе тарихы ........ 79

*Л.Ф. Байбулатова.* Ризаэддин Фәхретдиннең «Асар»ында мөфти Мөхәммәдҗан Хөсәенов шәхесе ........ 91


### • МИЛЛИ МӘГАРИФ


*Н.В. Максимов.* Телгә өйрәтү технологиясе ........ 106


### • ФӘЛСӘФИ ФИКЕР


*Д.Р. Гыйльметдинов.* Җан, кан вә иман: Госманлы империясе вакытлы матбугатында «татар йөзен» чагылдырган төп чаткылар ........ 113

## • ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*З.Г. Гарипова.* Габделхак Галиуллин (1919—1999) .......... 122

*Л.Х. Хәмидуллин.* Дәрдемәнд даирәсе .......... 127

## • ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН

*Н.Ш. Потеева-Фатыйхова.* Алтын Урдага сәяхәт .......... 146

*М.Р. Булатова.* Гаяз Исхакыйның авылдашы —
Сөембикә ханбикәнең рухи сеңлесе .......... 151

## • ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР

*Риза Газиз.* Табигыйме яки табигый булырга тиеш түгелме?
*Басмага әзерләде: Ш.Н. Асылгәрәев* .......... 154

## • СӘНГАТЬ

*Р.Р. Солтанова.* Таш моңы .......... 158

*М.Р. Газизова.* «Чаян» журналында Тукай
һәм аның персонажлары (1950—1980 еллар) .......... 162

## • ЯҢА КИТАПЛАР

*Ф.Г. Галимуллин.* Төрки «Йосыфнамә»не барлау юлында .......... 167

*Х.Й. Миңнегулов.* Айдар Гайнетдинов. Аднаш хафизның
«Сиражел колуб» әсәре һәм татар әдәбиятында аның традицияләре .......... 174

Фәнни-иҗтимагый тормышыбыздан .......... 176

УДК 811.512.145’373

***Д.Б. Рамазанова***

# ТАТАР ТАРИХИ ЛЕКСИКОЛОГИЯСЕНӘ МАТЕРИАЛЛАР: Америка индеецлары телендә төрки сүзләр

В статье на основе материалов А.Г. Каримуллина, М. Закиева и др. приводятся татарско-тюркские слова из языков индейцев Америки. Они были зафиксированы учеными в трудах различного характера. Приведенные материалы, на наш взгляд, представляют интерес для разработок по вопросам исторической лексикологии татарского языка.

**Ключевые слова**: материалы из языков индейцев Америки, татарско-тюркские слова, историческая лексикология татарского языка.

Татар тел белемендә телебезнең сүзлек фондын тарихи планда өйрәнү актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала килә. Билгеле, бу өлкәдә тарихи аспекттагы җитди тикшеренүләр башкарылган: М.З.Зәкиев, Р.Г.Әхмәтьянов, Ф.М.Хисамова, Ф.С.Хәкимҗанов, Ф.Ш.Нуриева, Э.Х.Кадирова һ.б. галимнәрнең төрле характердагы хезмәтләре татар белемендә генә түгел, гомум тюркологик масштабта да яңалыклы булдылар. Соңгы елларда мин үзем дә татар теленең сүзлек фонды формалашу тарихы һәм үсеше дигән проблема буенча беркадәр эзләнүләр алып барам. Бүгенге көндә татар теленең лексик фонды формалашу тарихы этаплары түбәндәгечә күзаллана:

| | |
|---|---|
| Ностратик чор | 11 мең еллар элек |
| Гомумалтай (бабаалтай) чоры | Б.э.к. X меңьеллык. Б.э.к. VI меңьеллыкта тунгус-маньчжур, корея-япон, төрки-монгол төркемнәре аерылган. |
| Монгол чоры | Б.э.к. IV меңьеллыкта төрки һәм монгол телләре аерылган. |
| Гомумтөрки (бабатөрки, прототюрки) | Төрки халыкларның ваграк төркемнәргә аерылуы. |
| Америка индеецлары | Аларның бабалары 30—20 мең еллар элек, Азиядән Беринг җирләре аша Америкага күчкәннәр дип фаразлана. |
| Шумерлар | Б.э.к. IV—III меңьеллыклардан III—I йөзләргә кадәр |
| Хетлар | Б.э.к. XVIII—XII йөзләр (II меңьеллык) |
| Этрусклар | Б.э.к. XVII—I йөзләрдә (I меңьеллык) |

| | |
|---|---|
| Скифлар | Б.э.к. VIII йөздән яңа эраның IV—V йөзләренә кадәр |
| Болгарлар, хәзәрләр | Б.э.к. II—III гасырлардан дигән фикерләр бар. |
| Аланнар | Б.э.к. I йөздә |
| Борынгы төрки чор | ДТС: VII — XIII гасырлар дип карала. |

Индеецлар XVII — XVIII гасырларда Миссури елгасы бассейнында Миссисипинең, Калифорниядән Арканзаска кадәр булган бассейнында, зур территориядә таралып яшәгәннәр. 1963 елда — 77 мең кеше булганнар. Алар аз өйрәнелгән, аларның теле буенча инглиз теленә һәм, киресенчә, инглиз теленнән индеецлар теленә тәрҗемә сүзлекләр чыгарылган (1866, 1890, 1968 елларда).

Америка индеецлары телендә төрки сүзләр күзәтелүе турындагы мәгълүматлар берничә хезмәттә күрсәтелә. XIX гасырда Отто Рериг дигән телче Төньяк Америкада яшәүче сиу халкы сөйләшеннән төрки телләргә хас күп кенә сүзләрне терки: *tang* — таң, *tani* — яки *tangi* — тану, *ate* — ата, *ina* — ана, *ekta* — якта, читтә, *ta-te* — урын килеше күрсәткече һ.б [Каримуллин, 1976, с. 136—141].

Швед галиме Стиг Викандер майя һәм алтай телләренең үзара якынлыгы турында хезмәтләр бастырып чыгара. Ә.Г. Кәримуллин шул хезмәтләр буенча мондый сүзләрне китерә: аак — юеш (ака>ага, русча «течет»), *baldiz* — балдыз (хатынының сеңлесе), *bayal* — бай, күп, *boya* — буяу, *bur* — ишү, борып, кысып бәйләп кую, зik — күренү (чагыштыр: татар. җек — ярык — *Д.Б*), *tur* — тору, yom — кушу, тоташтыру (чагыштыр: татар. йому) [Каримуллин, 1976, с. 140].

Икенче бер галимнең күзәтүләренә караганда, майя дигән Америка индеецлары телендә *й* һәм *җ* авазлары, төрки-татар фонетикасындагы кебек үк, чиратлашалар икән. Юклык кушымчасы *-ма/-ми* шулай ук төрки телләрдәге юклык формасына якын.

Төрки телләрдәге кебек үк, майя телендә дә йаш сүзе «яңа» (новый), «яшь» (молодой) мәгънәсендә дә кулланыла, ә йашыл сүзе составында яшел дигән төсне аңлата [Де Ланда Диэго, 1955, с. 19, 77, 79; бу мәгълүматлар түбәндәге хезмәттән китерелә: Зәкиев, 2007, с. 47].

Майя индеецларының мәдәнияте һәм язмачылыгы белән бик күп еллар Ю.В. Кнорозов дигән галим шөгыльләнә. Аның язмаларында төрки нигездә аңлатыла торган мондый сүзләр теркәлгән: чак (цвет) — татар. чагылдыру, чак (печь, очаг) — татар. чакма (кресало, огниво — шулай ук ут белән бәйләнгән), яш к'ин (йаш кын) — яшь кояш; борынгы төрки телдә яшык, кын — кояш һ.б. Майя телендә йаш сүзе ут мәгънәсендә дә кулланылган, төрки-татар яшен сүзе дә ут мәгънәсенә якын; аак — якты, ичин — коену, чен — кое, ишиль — Майя иленең бер өлеше һ.б. Де Ланда Диэго материалларында (алар М.Зәкиевнең күрсәтелгән хезмәтеннән китерелә) иль/ель компонентлы күп кенә топонимнар теркәлгән [Де Ланда Диэго, 1955, с. 12, 14, 15, 24, 25, 30 һ.б.; Закиев, 2007, с.47—48].

Майя халкында да, төрки ха-

лыклардагы кебек (кара: Рамазанова, 1991, с. 43, 65, 160—163), туганнар яшь ягыннан катгый рәвештә икегә — сөйләүчедән олыракларга һәм сөйләүчедән кечерәкләргә бүленә икән [Закиев, 2007, с. 48].

Бай әдәбият нигезендә М.З. Зәкиев, Америка индеецлары йә Евразиядә яшәгән төркиләр, яисә төркиләрнең көчле йогынтысына дучар булган халыклар булганнар һәм Евразиядә төркиләр 20—30 мең ел элек формалашкан булган инде, дигән фикергә килә, алар Беринг (ул вакытта ул коры җир булган) аша хәрәкәт иткән булырга мөмкин. Бүтән археологларның хезмәтләрен дә истә тотып, А.Окладников [1975, с. 33] һәм башка галимнәр беренче америкалыларның себер халыклары булуы ихтимал, дигән нәтиҗәгә килә.

Америка индеецларын җентекләп өйрәнгәннән соң, төрек галиме Әхмәт Али Арслан да, бик борынгы чорларда Урта Азия төркиләре Америка материгына җиткәннәр, беренче америкалылар төркиләрнең бабалары булганнар, дигән фикергә туктала [Закиев, 2007: 47—49].

Ә.Г. Кәримуллин шул хезмәтләрдән формалары һәм эчтәлекләре буенча төрки сүзләргә бик якын булган лексемалар китерә.

| Сиу-дакота индеецлары телендә | Русчасы | Төрки телләрдә | Русчасы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Yudek<br>Yuhep | Глотка<br>Глотание | Йотык, йоткы<br>Йоту, йотып | Глотка<br>Глотание |
| Iču | Пить | Эчү | Пить |
| Yasu, yaco | Приговорить, сделать | Ясау | Сделать, произвести, приговорить |
| Kuwa, ozuye | Наступить | Куа, куу<br>Уза, узу | Гонит, пригоняет, обгоняет |
| Capo, capaho | Забрало, покрывало | Капу, кәпә, капка | Ворота, забрало, верх |
| Yuta | Кушает | Йота, йоту | Проглотить |
| Wata | Раздробляет | Вата, вату | Раздробление, ломать |
| Koda | Товарищ | Кода | Деверь |
| Ichi | Вместе, напарник | Иш, ише | Напарник, вместе |
| Kapšuh | Кусать зубами | Кабу | Взять в рот |
| Kan | Сухожилие, вена | Кан | Кровь |

*Таблицаның ахыры*

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Mi | Я | Мин | Я |
| Bagana | Сделать метку | Багана, баганалау | Столб, застолбить |
| Canke | Трасса, дорога | Чаңгы | Лыжня, лыжи, лыжная дорога |
| Baba | Старый человек | Баба, бабай | Дедушка |
| Ik, ic | Два | Ике | Два |

[Каримуллин, 1955, с. 25]

Джон Свентон, Флоридада яши торган тимуча исемле индеецларның теле барлык индеецлардан да, шул исәптән сиулардан да аерылып тора, дип күрсәтә, аларның туганлык терминнарына туктала. Түбәндәге туганлык атамалары язылышлары белән дә, мәгънәләре ягыннан да төрки туганлык атамалары кебек:

*Isa* — мать — ана

*Isanam* — моя мама — минем анам

*Isaya* — твоя мама — синең анаң

*Iti* — отец — ата

Itinam — мой отец — минем атам

*Itaye* — твой отец, его отец — атаң, аның атасы

*Ule* — имя, данное ребенку женщиной — бала, ул

*Ulema* — мой ребенок — минем балам, минем улым

*Inihi* — замужняя женщина — кияүдәге хатын-кыз

*Qul* — ребенок вообще — гомумән бала (казакъ телендә куй — бала, бәрән) [Каримуллин, 1995, с. 27—28].

Ә.Г.Кәримуллин Америка антропологы Т.Кребер дигән галимнең хезмәтеннән гаҗәп бер мисал китерә: Яна дигән Америка индеецы «Син кем?» — дигән сорауга «иши» дип җавап бирә.

Билгеле булганча, күп кенә этнонимнар кеше мәгънәсенә туры киләләр. Монда да шундый ук хәл. Сүз башындагы к авазының, татар теленең касыйм сөйләшендәге кебек, әйтелмәве мөмкин.

Индеецларның тарихы һәм теле буенча зур белгеч, рус галиме Ю.В. Кнорозов «Письменность индейцев майя» [Кнозоров, 1963] дигән китабында майя индеецларының теле буенча сүзлек бирә. Шулардан төрки телләрдәге сүзләргә бик охшаш булганнарының кайберләрен карап китик:

| Майя индеецлары телендә | Русчасы | Төрки телләрдә | Русчасы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Йаш | Новый, зеленый | Яшь, яшел | Молодой (молодо-зелено) зеленый |
| К'ун | Солнце | Көн | День, солнце |
| Ич | Внутри | Эч | Живот, внутренность |
| Ош | Три | Өч | Три |
| Куч | Ноша | Көч | Сила |

*Таблицаның ахыры*

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| К’улл | Поднять руку | Кул | Рука |
| Чаб, чабкуна | Повалить дерево | Чап, чабу | Руби, рубить |
| Ч’акаан | Срубленное | Чапкан | Срубленный |
| Чукул | Рубить дерево | Чуку | Долбить |
| Ах-чы | Охотник | Аучы | Охотник |

[Каримуллин, 1995, с. 31]

Ә.Г. Кәримуллин майя индеецларына караган башка хезмәтләрдән дә төрки телгә бик якын булган күп кенә сүзләр китерә. Мәсәлән, бака — татарча да шундый ук мәгънәдә, Юкотан ярымутравындагы Кинтако-Роо дигән җирлектә бер култык Бакалар дигән исем йөртә икән.

Майя индеецларының мәдәниятенә багышланган хезмәтләрдә мондый материаллар чагылган:

| Майя индеецлары телендә | Русчасы | Төрки телләрдә | Русчасы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Кош | Вид птицы | Кош | Птица, вообще птица |
| Имиш ящче | Зеленое фруктовое дерево | Җимеш, йемеш, яшел җимеш | Фрукты, зеленый, незрелый фруктовый плод |
| Ичин | Колодец | Эчү | Пить |
| Яшь к’ин | Новое солнце | Яшь көн | Новый день, новое солнце |
| Аак | Белый, светлый | Ак | Белый, светлый |
| Ик | Два | Ике | Два |
| Моль, мооль | Много, сбор урожая | Мул | Изобилие, много |
| Мулук | Богатый год | Муллык | Изобилие |
| Па, Пао | Вода | Су, һу | Вода |
| Ку | Дух | Кот | Дух, душа |
| Чачак | Очень красивый | Чәчәк | Цветы,очень красиво |
| Цик | Ограда, край | Чик | Ограда, край |
| Чул | Вода | Чул | Вода (в тувин.яз.) |
| Бин | Я | Мин, бин | Я |
| Ичил | Внутри | Эч | Живот, внутренность |
| Ими | Женская грудь | Ими | Женская грудь |
| Чалан | Змея | Елан (җылан) | Змея |

*Таблицаның ахыры*

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Ват | Ломать | Ват, вату | Ломать |
| Ооч | Пища | Аш | Пища |
| Ба | Рыба | Балык | Рыба |
| Акан | Дядя по матери | Ага | Дядя, уважаемый человек |
| Соц | Летучая | Соц | Летучая мышь |
| Шаган | Вид дерева | Чаган | Вид дерева |
| Аль | Сын, ребенок | Ул | Сын |

[Каримуллин, 1995, с. 34. ]

Галимнәр Америка индеецларының күп кенә кабиләләрен өйрәнгәннәр һәм аларның кайберләренең бер-берсенә бик якын торуын да ачыклаганнар. Алай гына да түгел, Америка индеецлары теленең алтай гаиләсе телләре белән уртак яклары мәсьәләсен дә күтәреп чыкканнар. Бу юнәлештә Швециядән Стиг Викандер дигән галим (Упсал университеты ориенталисты) зур эшчәнлек алып бара һәм берничә мәкалә бастырып чыгаруга да ирешә (1967; 1970; 1971). Ул төрки һәм башка телләрне дә тикшереп хезмәтләр бастыра һәм майя теленең төрек теленә бик якын икәнен күреп исе китә. Әлеге телләрнең грамматик төзелешләре белән дә бер-берсенә охшаш икәнлеген ачыклый.

С.Викандер материалларында сиу-дакота индеецлары теле белән уртаклыклар да ачык күренеп тора.

*Im* — сосать

*Imi* — сосок, женская грудь

*Chu* — молоко

*Chupar* — сосание (чагыштыр.: татарча чүпер-чүпер суыру, эчү һ.б).

С.Викандер төрки телләр һәм майя индеецлары теле арасындагы аваз тәңгәллекләрен дә тикшерә һәм түбәндәге мисалларны китерә:

| Майя индеецлары телендә | Русчасы | Төрки телләрдә | Русчасы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Bicil | Кишки, внутренности | Bagirsak | Кишки, внутренности |
| Bul | Пена | Buram | Пена, водоворот |
| Bul | Разрывать | Burmak | Вить, закручивать |
| Bolan | Большая масса | Bol, mol | Обильный |
| Chopol | Извращенный | Çapur | Рябой |
| Yoklei | Тлеющие угли | Yak | Сжигать |
| Chek | Прикрывать | Çek | Делать ход |
| Chik | Появляться | Cik | Появляться, выйти |

*Таблицаның ахыры*

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Tic | Сажать | Dik | Втыкать, сажать |
| Tur | Останавливаться | Dur | Останавливаться |
| Tuy | Пучок волос | Düy | Волос |

[Каримуллин, 1995, с. 40]

Ә.Г. Кәримуллин майя индеецлары теле белән төрки телләр арасындагы лексик уртаклыкларны чагылдырган тагын бер таблица тәкъдим итә.

| Майя индеецлары телендә | Русчасы | Төрки телләрдә | Русчасы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Acan | Кричать, крик | Agit, agla (акыру) | Кричать, крик (орать, кричать) |
| Aak | Течение, течь | Ак (агым) | Течение, течь |
| Bet | Закончить | Bit (бет, бетерү) | Закончить |
| Bagir | Грудь | Bagir (бәгырь) | Грудь |
| Bikfit | Маленький мальчик | Егет | Парень |
| Bilim | Знак, знание, печать | Белем | Знание |
| Bin | Подниматься, поднимись | Мен | Подниматься, поднимись |
| Box | Голый | Boş | Пустой |
| Ceh | Олень | Kiyik | Олень |
| Chem | Лодка | Gemi, kami (көймә) | Лодка |
| Cuch | Ноша, бремя | Guç (көч) | Сила |
| Kat | Менять | Kat (кату) | Смешивать |
| Kil | Приди, прийти | Кил, килү | Прийти |
| Oc | Ступня ноги | Ökce (оч — конец; уч — ладонь) | Каблук |
| Poloc | Полный, упитанный | Big, ulug | Большой, великий |
| Poy | Игрушка | Oyna (уйын) | Игра, играй |
| Pudz | Исчезнуть | Uç | Улетать |
| Q’anil | Кровь | K’an (кан) | Кровь |
| Ti | Кусать | Tiş, diş (теш) | Зуб |

*Таблицаның ахыры*

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Toqmaq | Колотушка | Тукмак | Колотушка |
| Tzucul | Жилище | Чокыр | Яма, берлога |
| U | Луна | Ау (Ай) | Луна |
| Uayoh | Дремать | Uyu (ою) | Дремать |
| Wach | Развязывать | Aç (ач) | Открой |
| Yaklel | Пылать, сжигать | Уак (як, ягу) | Сжигать |
| Yom | Соединять | Yum (йом) | Соединить |
| Chal | Скала | Cal | Насыпь, откос |
| Taš | Приносить | Tašy (ташу) | Таскать |
| Baldiz | Младшая сестра (жены) | Балдыз | Младшая сестра жены |
| Bats | Обезьяна | Bičin | Обезьяна |
| Bil | Знать | Belgü (белү) (билге) | Знать<br>Знак |
| Boya | Краска, картина | Буяу | Краска, красить |
| Ciiol | Веселиться | Güll (көлү) | Смеяться |
| Ch'i | Край, берег | Чик | Край, граница |
| Ike | Два | Ике | Два |
| Its, itz | Сок растения | Iç (эчү) | Пить |
| Pulut | Курить, дымить | Bulut (болыт) | Туча |
| Sat | Расходовать | Sat (сату) | Продавать |

[Каримуллин, 1995, с. 40, 41]

Хәзерге көндә Үзәк һәм Көньяк Америка индеецларының кечуа индеецлары телендә сөйләшүе билгеле. Бу тел сиу-хока теленнән чыккан. Кечуа теле Перу, Эквадор, Боливия, өлешчә Аргентинада, Чилида да яшәп килә, кайберләрендә хәтта дәүләт теле статусына да ия. С.Викандер үзенең хезмәтендә кечуа теленнән дә төрки телләр белән уртак булган сүзләр китерә:

| Кечуа индеецлары телендә | Русчасы | Төрки телләрдә | Русчасы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Bulan | Вращать, вертеть, водоворот | Buram | Верчу, кручу |
| Col, gol | Спасти | Kurtar | Спасти |
| Oğri | Вор, воровство | Ogri | Вор |
| Por | Сжечь | Ört | Сжечь |

*Таблицаның ахыры*

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Poy | Ира, игрушка | Oy | Игра, игрушка |
| Pus | Текущая вода | Us | Выливание |
| Puz | Резать жертву | Uz, öz | Отрезать |
| Tok | Ломать, ударять | Toqu | Ударять |
| Tsar, tzap | Поймать | Çap | Грабить |

[Каримуллин, 1995]

Америка индеецларының теле белән төрле белгечләр кызыксыналар һәм барысы да әлеге телләрнең төрки телләр белән якынлыгына игътибар итәләр. Шундыйлардан тагын бер авторны күрсәтергә мөмкин.

1935 елда Рим шәһәрендә уздырылган Көнчыгыш буенча белгечләрнең XIX халыкара конгрессында Б. Феррарио дигән кеше кечуа теленең төрки һәм алтай телләре белән тугандаш булу мөмкинлеге турында доклад ясый. Үзенең гипотезасын дәлилләү өчен уртак булган морфологик формаларга, сүзьясалыш, төрләнеш алымнарына туктала, лексик мисаллар китерә.

| Кечуа индеецлары телендә | Русчасы | Төрки телләрдә | Русчасы |
|---|---|---|---|
| Ipa | Сестра отца | Apa | Старшая сестра |
| Učuk | Молюсенький | kücük | Малюсенький |
| Acikua<br>Kok | Объяснить<br>Небо, небосвод, небесный | Aciq<br>Kök | Открытый, ясный<br>Небо, небесный цвет |
| Wage | Дядя по отцу | Aga | Дядя, уважаемый человек |
| Tata, tayta | Отец | Ada, ata, dada | Отец |
| Misi | Кошка | Misik | Кошка |
| Sunqa | Борода | Sukal | Волосы, борода |
| Čubča | Пучок волос | Tük | Пучок волос |
| Na | Вещь, что-то | Ne | Вещь, что-то |
| As | Небольшой, немного | Az | Мало, немного |
| Ari | Худой | Arig, ariq | Тощий, худой |
| Qo | Гнать | Qo, qomak | Гнать |
| Kača | Перенести в другое место | Keč, geč | Перейти, пересесть |

[Каримуллин, 1995, с. 44]

Кечуа теле Георг Дюмезель дигән француз ориенталистының да игътибарын җәлеп итә. Бу автор да кечуа телен төрки телләр белән чагыштырып тикшерә, бердән алып алтыга кадәр булган сан исемнәренең ике телдә дә генетик яктан бер булуын раслый, морфологик категорияләрнең уртак булуын яза. Аның лексик материаллары арасында майя һәм сиу телләре белән уртак сүзләр күп очрый.

Түбәндә шуларның бер өлеше тәкъдим ителә:

| Кечуа индеецлары телендә | Русчасы | Төрки телләрдә | Русчасы |
|---|---|---|---|
| Č'aqla | Борода | Sacal | Борода |
| Čani | Цена | San | Число |
| Thugu | Плевать, выливать | Tükur (түгү) | Плевать, выливать |
| Tuqu | Ударять | Tik, tuqu | Колоть, втыкать, стегать |
| Pak, paku | Смотреть | Bak, bagu | Смотреть |
| Tawqa | Куча | Tağ, taw | Гора |
| Qhačun | Сноха, невестка | Katun, katin | Замужняя женщина |
| Qarwin | Пищевод | Karin | Желудок |
| Cunqa | Последний, 10-ый палец руки | Soh | Последний, конечный |

[Каримуллин, 1995, с. 45]

Америка индеецлары теленнән югарыда китерелгән сүзләрне лексик семантик төркемнәргә аерып күрсәтик.

Туганлык атамалары: *isa* — ана, *iti* — ата, *ulema* — улым, балам, *inihi* — кияүдәге хатын, *qul* — гомумән бала, акан — ага (ана ягыннан), аль — ул бала, малайы, *bikfit* — егет, *baldiz* — балдыз, *ipa* — әтисенең апасы, *wage* — ага, әтисе ягыннан булган ир туган, *tata: tayta* — ата, *qhačun* — килен, җиңгә, *koda* — иптәш, иренең абыйсы яки энесе, *ichi* — иш, ише, *baha* — карт кеше (бабай).

Кешенең тән төзелеше белән бәйле сүзләр: *yudek* — йотык, йоткы) — йоткылык, *yuhep* (йоту, йотып) — йоту, *kan* — вена, сеңер, *к'улл* — кул күтәрү, *ич* — эчтәге (эч —живот), *č'aqla* — сакал, *qarwin* — *уңәч* (төрки: карын — желудок), *cynqa* — кулда соңгы, 10 нчы бармак (*soh* — последний, конечный), *ими* — ими, *bicil* — эчәкләр (*bagirsak* — эчәкләр), *chopol* — извращенный (çapur — шадра), *tuy* — чәч тотымы (güy — волос), *bagir* — күкрәк, *ос* — аяк башы (ökce — үкчә — каблук), *q'anil* — кан, *sunqa* — сакал, čubč*a* — чәч тотымы (рус телен-дә — чуб), *ичил* — эчтә, *ич* — эчтә, *box* — ялангач (буш), *cuch* — йөк (көч).

Кешенең эшчәнлеге, башкара торган эшләре: *yuher* — йоту, *iču* — эчү, yasu, *Yaco* — карар чыгару, ясау (чагыштыр: ясак) — ясау, *kuwa*, *ozuye* — куып җитү, узу, *yuta* — ашый, *wata* — вата, *kapšuh* — тешләү (теш белән),

кабу; *чаб* — (повалить) (чап — кисү, чабу); *ч'акаан* — кискән, чапкан, *чукул* — агач кисү, *чуку* — тишү, *thugu* (tükyr) — төкерү, түгү; *tugu* — сугу (*tik, tuqu* — чәнчү, тыгу, тегү); *рак, раkи* — карау (бак — карау), *bat* — вату, *bul* — ерту *(вurmak* — ишү, бору), *chek* — яшерү (*çek* — делать ход), *chik* — күренү, чыгу, *tic* — утырту (төртеп утырту), *tur* — туктау, *acan* — кычкыру, кычкырган тавыш, *bet* — бетерү, *bin* — күтәрелү, менү, *kat* — алышу (кату — кушу), *kil* — килү, *pudz* — юкка чыгу (uç — очып китү), *te* — тешләү (төрки *tiş, di*ş — теш), *uayoh* — йокымсырау, йокыга ою, *wach* — чишү (*aç, ач* — ачу), *yaklel* — яндыру, яну, ягу, *yom* — кушу, йому, *taš* — китерү, ташу, *bil* — белү, *sat* — тоту, сату; ахчы — аучы, *por* — яндыру (диал. *пор* — корым), *ört* — яндыру, *bagana* — тамга салу, билге кую (баганалау), *ačikya* — аңлату, ачыклау; *qo* — куу, *kača* — башка урынга күчерү (*keč* — күчү) һ.б.

Кием-салым: *caро, caраho* — ябынгыч, ябу (покрывало) (төрки: *капу, көпө* — капка; ябынчык; кием төре).

Аш-су белән бәйле сүзләр: *ооч* — азык (аш), *its, itz* — үсемлекләрнең согы (*iç* — эчү), *pulut* — тарту (тәмәке), төтен (болыт).

Алмашлыклар: *mi* — мин, бин — мин, *па* — әйбер, ни.

Саннар: ик, *ic* — ике, ош — өч, *čanl* — бәя (san — сан), ик — ике, моль, мооль — күп, уңыш җыю (мул), *bolan* — зур күләмдәге (*bol, mol* — мул), *ike* — ике, *as* — аз, кечкенә.

Үсемлекләр: *чабкуна* — агач (чапкан — киселгән), *имиш яшче* — яшел җимеш агачы, *шаган* — агачның бер төре (чагыштыр: *чаган* — өрәңге, шыган кебек — төз, озын буйлы).

Хайваннар дөньясы: *кош* — кошның бер төре, *чалан* — елан, *ба* — балык, *соц* — оча торган, ярканат, *ceh* — болан (*kiyik* — болан), *bats* — маймыл (*bicin*), *misi* — песи, мәче (*misik* — песи).

Көнкүреш-кулланмалар һ.б.: *ичин* — кое (эчү), *цик* — киртә, чик; *yoktel* — янып ята торган күмер, утлы күмер (*уак* — ягу, яндыру), *chem* — көймә (*gemi, kami* — көймә), *toqmaq* — тукмак, *canke* — трасса, юл (чаңгы).

Табигать күренешләре: *яшь к'ин* — яңа кояш, *мулук* — бай ел (муллык), *па, пао* — су, чул — су, *аак* — агым, *и* — ай (ау - ай), (луна), *chal* — кыя (*cal* — насыпь, откос), *puz* — корбанны чалу (*uz, öz* — өзү), *кок* — күк йөзе, *к'ун* — кояш, *tawqa* — өем (куга) (төрки: *tağ, taw* — гора).

Сыйфатлар: *аак* — ак, *чачак* — бик матур, *poloc* — тулы, тыгыз (*big, ulug* — зур, бөек, олы), *ичик* — бик кечкенә (küсük), *ari* — ябык (арык).

Рухи тормышны яктырткан сүзләр: *ку* — рух (кот), *bilim* — тамга, белем, печать, *рои* — уенчык (*оуna* —уен), *bil* — белү, *boya* — буяу, рәсем, *ciiol* — күңел ачу (*güll* — көлү), *oğri* — карак.

Америка индеецлары теле һәм төрки телләр арасындагы уртаклыклар мәсьәләсе соңгырак чор галимнәре тарафыннан да тикшерелгән.

Чили Республикасының Икике шәһәрендәге Боливариана университеты укытучысы Конрад Попп (ул Европа, Көнчыгыш, Америка индеецлары, төрек телләрен белә торган галим) Көньяк Америкадагы җирле халыклар (кечуа, аймара, гуарани, мапуче) һәм төрки (казакъ, кыргыз, татар, төрек) халыклар телләренең мәдәни яктан уртаклыкларын күрсәтеп үтә: тышкы кыя-

фәтләрен, торак төзелеше, күмү йолаларын, рухи мәдәният йолаларын, фикер йөртү һәм дөньяга карашлары белән бәйле уртаклыкларын яза [Конрад, 2008,с. 167—170].

Алга таба автор атап үтелгән халыкларның телләре арасындагы структур охшашлыкларны тикшереп чыга: род (с. 174), агглютинация (с.174), күплек формасының ясалышы (с. 176), сыйфатлар белән исемнәрнең грамматик күрсәткечләрсез ярашмавы (с. 177), фигыльнең юклык формасы (с. 179), билгеләү артикленың юклыгы (с. 180), иҗекнең бер аваздан башлануы (с. 180—181) кебек күренешләр буенча әлеге телләрнең уртаклык күрсәтүләрен ачыклый, 182 биттә бу күренешләрнең уртаклыгы таблицасын урнаштыра һәм охшашлыкларны процентларда да күрсәтә. Мәсәлән, кечуа, аймара индеецларының телләренең күрсәтелгән төрки телләр белән охшашлыклары (төрки телләрнең үзенчәлекләрен 100% дип алганда) 90%, гуарани теленең төрки телләр белән охшашлыгы 70%, мапуче теленең 60% дип исәпли [Конрад, 2008, с. 183].

Хезмәтенең азагында автор түбәндәге нәтиҗәгә килә: Америкага беренче булып килеп утырган халыклар, чыгышлары белән, Азиядән булганнар. Азия һәм Америка халыклары арасындагы уртаклыклар һәм матди, һәм рухи мәдәнияттә дә чагылалар. Конрад Попп фикеренчә, кечуа һәм аймара индеецлары теле белән төрки халыкларның телләре арасындагы 90% уртаклык аларның чыгышларының уртак булуы турындагы фаразны шактый нык көчәйтә [Конрад, 2008, с. 183—184].

Шулай итеп, киңрәк күләмдәге материалларны барлап, соңгы чорлардагы казанышларны да (мәсәлән, протетик авазлар белән бәйле фактларны һ.б.ны) файдаланып тикшеренүләр, халыклар һәм аларның мәдәниятләрен комплекслы өйрәнүләр фәнне баета, яңа фикерләр тудыра.

### Әдәбият


*Закиев М.З.* Древние тюркоязычные ареалы // Актуальные вопросы татарского языкознания. Вып. 6. Казань, 2007. С.41—73.

*Каримуллин А.Г.* О возможном родстве отдельных индейских языков с тюркскими // Вопросы тюркского языкознания. Казань: изд-во КГПИ, 1976. — С. 135—143.

*Каримуллин А.Г.* Прототюрки и индейцы Америки по следам одной гипотезы. М.: Инсан, 1995. 80 с.

*Кнорозов Ю.В.* Письменность индейцев майя. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1963. 663 с.

*Конрад Попп.* К вопросу о структурных сходствах между отдельными языками коренных жителей Южной Америки и тюркскими // Языковые уровни и их анализ (на материале языков разных систем). Казань, 2008. С.167—186.

*Окладников А.* Первыми американцами были сибиряки // Наука и жизнь. 1975. №12. С.33—36.



***Рамазанова Дария Бәйрәм кызы**, филология фәннәре докторы,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145›373

***И.Б. Бәширова***

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СҮЗНЕҢ ЛЕКСИК МӘГЪНӘСЕ ҺӘМ ЛЕКСИК-СЕМАНТИК ТӨЗЕЛЕШЕ

**Аннотация.** В статье рассматриваются проблемы соотношения понятия и лексического значения, а также вопросы методологии изучения лексико-семантической структуры слова в татарском языке.

**Ключевые слова:** семасиология, слово, понятие, лексическое значение слова, сема, лексико-семантическая структура слова.

Махсус фәнни әдәбиятта семасиология тармагы ике өлештән тора дип аңлатыла: беренчедән, теләсә кайсы тел берәмлегенең мәгънәсен (эчтәлеген) тикшерү, икенчедән, сүз һәм тотрыклы сүз тезмәләренең лексик мәгънәсен, аларның мәгънәви үзгәрешен өйрәнү [Ахманова, 1969, с. 401].

Рус һәм татар телләрендә язылган лексикология дәреслекләреннән күренгәнчә, семасиология бүлегендә, телнең теләсә кайсы берәмлегенең мәгънәсе түгел, фәкать сүз һәм тотрыклы сүз тезмәләренең мәгънәсе, аларның үзгәреше генә өйрәнелә [Сабиров, 1969, с. 11; Сафиуллина, 1999, б. 5—56]. Әлеге хезмәтләрдә сүзнең лексик мәгънәсен аңлатырга керешкәндә, сүзнең чынбарлыктагы предмет, күренеш, эш-хәрәкәт, билгеләрнең атамасы була алуына игътибар ителә. Сүзнең тагын күреп, ишетеп, тоеп, тәмләп, сизеп булмый торган предмет, күренеш, хәлләрне дә исемли алуы билгеләнелә. Аннан соң, фикерләү нәтиҗәсендә, бер сүзнең бер үк типтагы күп санлы предметларны гомумиләштерә (абстракцияләштерә) алу үзенчәлегенә дә басым ясала. Шулай итеп, сүзнең ничек итеп мәгънә белдерә алуын аңлатканда, аның чынбарлыкта булган предмет һәм күренешләрне, чынбарлыкта булмаган предмет һәм күренешләрне атый алуына, фикерләү эшчәнлеге белән бәйле булган төшенчә нигезендә аерым предмет, күренешләрне гомумиләштерә алуына игътибар ителә. Мәгълүм булганча, әлеге аңлатуда, сүзнең лексик табигате (сема, семема — сүзнең сүзлектә теркәлә торган реаль төп лексик мәгънәсе) билгеләнми, аның ике вазыйфасы, ягъни атау һәм гомумиләштерә алу функцияләре турында фикер әйтелә.

Сүз чынбарлыкта булган, ягъни күреп, ишетеп, тоеп, тәмләп, сизеп карарга мөмкин булган һәм чынбарлыкта булмаган предмет, күренешләрне ничек итеп атый соң? Ул аларны ничек итеп гомумиләштерә? Сүзнең лексик мәгънәсе нәкъ менә шушы сорауларга җавап бирү юнәлешендә генә ачыклана ала, билгеле була.

Мәгънә (значение) дигән төшенчә философия, логика, психология, психофизиология кебек озын гасырлар буе формалашкан традицион фәннәрдә дә, семиотека, математик логика, информатика, кибернетика һ.б. кебек яңа фәннәрдә дә, һәр фәннең үз предметы, максат-бурычлары таләп иткән дәрәҗәдә, үзенә генә кирәк булган метод-ысуллары белән анализлана. Әлеге мәсьәләләргә нисбәтле рәвештә бик күп хезмәтләр язылган һәм бу хезмәтләрнең барысында да диярлек, мәгънә төшенчәсенең

асыл табигатен җентекләп аңлату өчен, табигый тел, табигый сөйләм, табигый сүз һәм аларның категорияләре файдаланыла [Философский ..., 1980, с. 118, 127, 205—206, 325—326].

Шуның белән бергә, мәгънә белдерелә алу, теләсә кайсы аспекттан караганда да, чынбарлыктагы предметларның объектив функциясе, кешеләрнең үзара аралашуы өчен төп шарт булып торганга, табигый тел берәмлекләренең мәгънә белдерә алу мөмкинлеге дә лингвофилософик проблема булып күтәрелә. Тел белемендә сүз тамгасының мәгънәсен билгеләгәндә, әлеге мәсьәләнең философик яктан ничек итеп аңлатылуына игътибар ителә. Бу юнәлештә төрле караш-гипотезалар булу менә шуның нәтиҗәсе дә инде. Мәсәлән, сүзнең мәгънәсе — шул сүз белдергән төшенчә ул, сүзнең мәгънәсе — шул сүзнең предметка, төшенчәгә, башка сүзләргә карата булган мөнәсәбәте ул, сүзнең мәгънәсе — аң эшчәнлеге нәтиҗәсендә, аерым предмет, күренешләрнең сүздә чагылыш табуы ул, дигән һәм башка гипотезаларның озак гасырлар дәвамында яшәештә булуы мәгълүм [Березин, 1979, с. 122—128].

Бу төрдәге өйрәтүләр, билгеле бер дәрәҗәдә, татар теле белемендә дә чагылыш таба. XX гасырның 60 нчы елларында язылган лексикология дәреслегендә мәгънә һәм төшенчә берсе икенчесен алмаштырып килә ала торган абсолют синоним буларак кулланыла: «…Мөстәкыйль сүзләр, нинди төшенчә белдерүләренә карап, конкрет һәм абстракт мәгънәле булалар. Әйберне, күренешне, эшхәрәкәтне һ.б.ны барлык билгеләре белән тулысынча күз алдына китереп бастыра торган сүзләр конкрет мәгънәле сүзләр дип атала. Төшенчәнең берәр үзенчәлеге, сыйфаты буенча гына предметны, күренешне гомумиләштереп исемли торган сүзләр абстракт мәгънәле сүзләр дип аталалар. …Кешелек җәмгыятендә элек конкрет төшенчәле сүзләр барлыкка килеп, кешеләрнең уйлау-фикерләү сәләтләре тирәнәю, алга китүгә бәйләнешле рәвештә абстракт төшенчәле сүзләр ясала башлаган» [Сабиров, 1969, с. 21]. Аңлашылганча, мәгънә һәм төшенчә сүзләре абсолют синонимнар буларак кулланыла. Димәк, сүзнең мәгънәсе — шул сүз белдергән төшенчә ул, дигән өйрәтү татар лексикологиясендә XX гасырның икенче яртысына кадәр яшәештә була.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә дә шулай теркәлә: «Сүз *и.* 1. Бер яки берничә аваздан төзелеп, мәгълүм грамматик форма алган (сөйләмдә җөмлә кисәге яки җөмлә булып кулланыла торган) һәм төшенчә белдерә торган иң кечкенә лексик берәмлек» [Татар ..., 1979, Т. 2, б. 721].

Шуның белән бергә, бу вакытларда аерым авторлар төшенчә, мәгънә, сүз категорияләренең берсе икенчесеннән аерымланырга тиешлеген аңлыйлар һәм шуннан чыгып эш йөртәләр. Мәсәлән, татар телендә синонимия мәсьәләсен җентекләп өйрәнүче Ш.С. Ханбикова үзенең «Татар телендә синонимия һәм сүзлекләр» дигән хезмәтендә болай дип яза: «Төшенчә — чынбарлык предметы турында безнең белем, аң дәрәҗәбез булса, сүзнең мәгънәсе исә сүз яңгырашы белән төшенчә арасындагы тарихи бәйләнешне чыгылдыра, бу бәйләнеш кеше аңында туып, тел системасында гәүдәләнеш таба. Ягъни төшенчә — аң процессы белән бәйле реаль сыйфат (логик категория); сүзнең мәгънәсе — гносеологик процесс нәтиҗәсендә төшенчә нигезендә туа, тел системасында аерым семантик буын буларак яши һәм үсә торган сүзнең мәгънәви (смысловой) эчтә-

леге (лексик-семантик категория); сүз исә — сүз мәгънәсенең авазлар системасындагы реаль яңгырашы, сүз мәгънәсенең тышкы формасы (лингвистик категория)» (Ханбикова, 1980, б. 8—10).

XX гасырның соңгы чирегендә язылган лексикология дәреслекләрендә бу төр аңлатулар өлешчә чагылыш таба. Мәсәлән, Ф.С.Сафиуллина үзенең «Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология» хезмәтендә болай дип белдерә: «Сүзнең мәгънәсен төшенчә белән тиңләштерергә ярамый. Сүзнең мәгънәсе төшенчә мәгънәсеннән ярлырак була. ...Эчтәлекле төшенчәдән ярлырак булганы хәлдә, сүз мәгънәсендә төшенчәдә булмаган өстәмә элементлар катнаша. Шулай итеп, сүз, эчтәлекле төшенчәгә караганда, баерак, киңрәк булып чыга. Сүзнең төп мәгънәсенә өстәмә мәгънәләр килеп кушыла. ...Бер үк сүз берничә төшенчә дә белдерергә мөмкин. ... Телдә теге яки бу өстәмә эмоциональ төсмерләрдән азат булган чиста төшенчәләр була. Аларны термин (латин. *terminus* — чик) дип атыйлар. ...Төшенчәләр сүзләр ярдәмендә барлыкка киләләр» [Сафиуллина, 1999, б. 12—13].

Шулай итеп, сүзнең мәгънәсе шул сүз белән әйтелә торган төшенчәгә тәңгәл булмый, сүзнең лексик мәгънәсе чынбарлыкка, аңга (фикерләүгә), тел структурасындагы аерым сүзләрнең үзара мөнәсәбәтенә нигезләп аңлатыла: «Лексик мәгънәләр чынбарлыктагы әйбер яки күренешләргә мөнәсәбәтле рәвештә төркемләнәләр. Бу принцип буенча атау һәм сигнал, туры һәм күчерелмә, конкрет һәм абстракт мәгънәләр аерылып чыга. ...Лексик мәгънәләрнең аңга (фикерләүгә) мөнәсәбәтенә бәйле рәвештә сүздә терминологик һәм гомуми, образсыз һәм образлы, эмоциональ һәм эмоциональ булмаган мәгънәләр аерылып чыга. ...Тел структурасындагы лексик мәгънәләрнең үзара бәйләнешендәге аермаларга карап, синонимик һәм антонимик, монолексик һәм омонимик, мотивлашкан һәм мотивлашмаган, нигез һәм ясалма мәгънәләр аерыла» [Сафиуллина, 1999, б. 15—19].

Әлеге аңлату шактый тәфсилле, әмма монда, лексик мәгънәнең типларын билгеләгәндә нигез итеп алына торган мөнәсәбәтләрне төгәлрәк итеп күзалдына китерәсе килә. Чынбарлыктагы әйбер яки күренешләргә мөнәсәбәтле рәвештә төркемләнә торган лексик мәгънәләрнең шул әйбер яки күренешләргә карата булган мөнәсәбәте ничек хасил була? Аңга (фикерләүгә) мөнәсәбәтле рәвештә төркемләнә торган лексик мәгънәләрнең аңга (фикерләүгә) карата булган мөнәсәбәте ничек барлыкка килә? Лексик мәгънәләрнең үзара бәйләнешендәге аермалыкларны билгеләү өчен, иң башта лексик мәгънәнең үзен конкретлаштырып күрсәтү кирәкмиме икән? кебек сорауларга җавап көтелә.

Югарыда куелган әлеге сорауларга җавап эзләп, лексик мәгънәне махсус рәвештә өйрәнә яисә аларны гомумиләштереп бирә торган аерым хезмәтләргә мөрәҗәгать итәргә кирәк була. Шундый хезмәтнең берсе — телнең шартлы тамгалар системасы буларак яшәвен һәм әлеге тамгаларның мәгънә белдерә алуын өйрәнүнең методологик нигезен төгәлләп бирә торган «Гомуми тел гыйлеме» курсы.

Хәзерге лингвистикада, барлык тел тамгаларының да, шул исәптән лексик берәмлекләрнең дә, мәгънә белдерүен тикшергән вакытта, аларның тик торган, статик халәттә (сүзлектә теркәлгән) һәм сөйләмдәге (эш башкарган) вакытында дип,

ике аспектка нигезләнүе, мәгънәне билгеләгәндә төп методологик җирлек итеп санала. Димәк, аерым сүзләрнең үзләренә генә хас булган индивидуаль лексик мәгънәсен аның тик торган чагындагы һәм шул ук мәгънәнең сөйләмдә, контекстка бәйле хәлендәге мәгънәсе дип аңлатырга тиеш булабыз. Тик торган халәттә сүзнең лексик табигате (сема), ягъни сүзлектә теркәлә торган реаль сүз мәгънәсе билгеләнелә. Сүзнең тик торгандагы (субстанциональ) мәгънәсе аның эш башкарган вакыттагы (функциональ) мәгънәсе белән тулылана һәм киңәйтелә, ягъни аның информация бирү колачы киңәя.

Сүзнең тик торган халәттәге мәгънәсе, беренче чиратта, сүз белән шул сүз атый торган чынбарлыктагы предметның ике планлы чагылышына нигезләп аңлатыла. Физиолог И.П. Павлов хезмәтләреннән аңлашылганча, беренче сигнал системасы нигезендә, икенче сигнал системасын хасил итү процессында, аерым бер сүз үзенең әйтелеше яисә укылышы белән безнең миебезгә табигатьтәге башка барлык ярсыткычлар (төрле тавышлар, рәсемсурәтләр һ.б.) кебек үк тәэсир итә һәм безнең күз алдыбызда шул сүз атый торган предметның образы пәйдә була. Һәм, киресенчә, билгеле бер предметны күрү, хәтерләүуйлау белән кеше аңында шул предметның атамасы булган сүз образы хасил була. Әлеге катлаулы психофизиологик процессның бер өзлексез баруы, кеше миенең зур ярымшарларында икенче сигнал системасын барлыкка китерә торган шартлы рефлекторлар хасил итә. Нәкъ менә шушы ике планлы психофизиологик чагылышның (сүз-предмет — предмет-сүз) үзара бәйләнеше сүзнең тик торган хәлдәге субстанциональ мәгънәсе була.

Реаль чынбарлыкта булган аерым бер предмет атамасындагы (мәгънәсендәге) конкретлык (*каен, кыяр, күлмәк, ат* һ.б.), фикер эшчәнлеге белән, күп предметларда да табыла торган уртак билгенең бер өлеше буларак күзаллана, ягъни гомумиләштерелә, шул предметларның абстракцияләшкән чагылышы булган төшенчә хасил була һәм сүзе — атамасы белән тәгъбир ителә (*агач, яшелчә, кием, хайван* һ.б.). Бу процесста предмет-атама белән төшенчә-атама бәйләнешендәге ике планлы чагылыш пәйдә була: предмет-атама — төшенчә-атама — төшенчә-атама — предмет-атама.

Тел үсеше, фикер эшчәнлегенең камилләшүе җирлегендә, сүзнең тик торган халәтендәге мәгънәсе, чынбарлыкта булган предметларның исеме, яисә аларның гомумиләштерелгән төшенчә-атамалары белән генә түгел (И.П. Павлов хезмәтләрендә бу мөмкинлек шартлы рефлекторлар барлыкка килүнең беренче этабы дип атала), бәлки әлеге чагылышларны белдерә торган сүз-образларының икенче сүзләр белән исемләнүе нәтиҗәсендә дә барлыкка килә башлый. Бу процесста төшенчә-атама белән яңа мәгънә аңлата торган сүз бәйләнешендәге ике планлы чагылыш пәйдә була: *агач — агачлык, яшелчә — яшелчәлек, күлмәк — күлмәклек, хайван — хайванчылык* һ.б.

Аңлашылганча, сүз-предмет бәйләнеше нигезендә хасил булган мәгънәдә конкретлык көчлерәк була, төшенчә-сүз бәйләнеше нигезендә хасил булган мәгънәдә әлеге конкретлык гомумиләштерелгән була, сүзобразлар белән икенче сүз бәйләнешенә нигезләнеп барлыкка килгән мәгънәдә исә, төшенчә буларак гомумиләштерелгән мәгънә дә шактый абстрактлашкан рәвештә була. Әмма өч төрле тармактагы бу халәт,

асылда, теоретик планда гына шулай кискен булып аерымлана, ә гамәлдә, ягъни сөйләмдә, бу бүленешләр берсе икенчесенә керешкән хәлдә була. Мәсәлән, без *каен* дип әйткән вакытта да әлеге сүз белән атала торган бердәнбер предмет күз алдында тотылмый бит, бәлки күп төрле каеннар турында әйткән булабыз. *Агач* дигәндә дә кулыбызда тотып тора торган агач кисәге гомумиләшкән хәлдә генә түгел, бәлки конкрет мәгънәгә дә ия. Абстракт мәгънәгә ия булган *күлмәклек* дигән сүз атый торган материяне без конкрет хәлендә кулыбызда тотып, җентекләп карый алырга мөмкин. Шулай итеп, сүз мәгънәсен тик торгандагы предметлык — төшенчәлек — абстрактлык мәсьәләсе, теге яки бу сүздә аларның кайсысының күбрәк микъдарда булуы, сүз мәгънәсенең эш башкарган вакытында, ягъни сөйләмдә нинди функция үтәвенә бәйле хәлдә конкретлаша. Димәк, сүзнең мәгънәсен билгеләгәндә, аның тик торган халәтендәге мәгънәсе барлыгын белү белән бергә, әлеге сүзнең сөйләм эчендә (аерым грамматик формалары белән сүз тезмәләрендә, гади һәм кушма җөмләдә, тулы бер текстта, абзацта, тулы бер әсәрдә һ.б. да) нинди функция үти алуына да игътибар итәргә тиеш булабыз. Дөресен әйткән вакытта, тел (сүз) турында сөйли башлаганда ук, без аның функциясеннән башлыйбыз: тел — ул аралашу чарасы, сүз бу предметны атый, сүз бу мәгънәне гомумиләштерә һ.б. дигәндә, асылда, гомумән телнең һәм аерым сүзләрнең тик торган хәлдәге мәгънәсенә түгел, бәлки аның эш башкаргандагы хасиятенә игътибар иткән булабыз.

Функциональ аспектта, барлык тел тамгалары кебек үк, аерым бер сүзнең мәгънәсе дә билгеле бер информацияне алып килә алуы белән характерлана. Телнең (сүзнең) информатив функциясе тулы бер җәмгыятьтә, социаль коллективта барлыкка килә, кешеләрнең үзара аралашуын тәэмин итә һәм шул җәмгыятьне яшәтү көченә ия була.

Аралашу, тел берәмлекләрен ничек итеп кулланылуына карап, телдән һәм язма рәвештә бара. Сөйләүче (язучы) үзенә кирәк информацияне тыңлаучыга (укучыга) җиткерә, тыңлаучы (укучы) әлеге информацияне сүзләрнең (сөйләмнең) тәэсире белән кабул итә, нәрсә турында сүз баруын — мәгънәне аңларга тырыша [Татар ..., 1998, б. 156].

Сүзнең һәм гомумән тел берәмлекләренең мәгънә белдерүе катлаулы булганга, әлеге мәгънәне өйрәнгән вакытта, аны берничә нигезгә аерып карарга кирәк була.

Беренче нигез — сүз белдерә торган информациянең чыганагы нинди булу: информациянең чыганагы чынбарлыкта булса — объектлы мәгънә, аң-фикерләүдә булса — субъектлы мәгънә, телнең үз системасында булса — структур мәгънә. Аңлашылганча, бу тип мәгънәләр сүзләрнең телдә һәм сөйләмдә денотатив, сигнификатив һәм структур дип атала торган мөнәсәбәтләренә бәйле хәлдә карала.

Икенче нигез — сүзнең һәм башка тел берәмлекләренең мәгънә тибын билгеләгәндә, информациянең тел структурасына нигезләнүе: ягъни, нинди информация белдерүләренә карап, фонеманың мәгънәсен, морфеманың мәгънәсен, сүзнең лексик мәгънәсен, сүзьясалыш типларының мәгънәсен, морфологик һәм синтаксик категорияләрнең мәгънәсен билгеләү.

Өченче нигез — мәгънәнең функциясе: номинатив мәгънәләр (сүзнең предметны атавы), сигнификатив мәгънәләр (сүзнең төшенчәне белдерүе һәм исемләве), дейктив

мәгънәләр (сүзнең предметны күрсәтә алуы), экспрессив мәгънәләр (сүзнең хис-кичерешләрне белдерүе), коммуникатив мәгънәләр (кешеләр арасында аралашуны тәэмин итү). Бу соңгы мәгънәне, җөмлә статусына ия булмаса, аерым бер сүз генә үти алмый, аны тулы бер җөмлә генә башкара.

Дүртенче нигез, аң һәм чынбарлыкның төрле аспектларына, категорияләренә нигезләнеп барлыкка килгән мәгънәләр: бу нигездә предметлык, процесслык, сыйфат, сан, бәйләнеш һәм мөнәсәбәт, эмоциональлек һ.б. мәгънәләр аерымлана.

Бишенче нигез — мәгънәләрнең тел-сөйләм системасындагы үзара мөнәсәбәте. Әлеге нигездә түбәндәге мәгънәләр аерымлана: нигез мәгънә — ясалма мәгънә, мотивлашкан (сүзне аерым лексик морфемаларга бүләргә мөмкин булу) — мотивлашмаган (сүзне аерым лексик морфемаларга бүлеп карарга мөмкин булмау), иректә һәм бәйле мәгънәләр, туры — күчерелмә, синонимик — антонимик, бер мәгънәле — күп мәгънәле, телдәге мәгънәләр — сөйләмдәге мәгънәләр һ.б.

Алтынчысы — җәмгыятьнең социаль төзелеше белән бәйле рәвештә тормыш-көнкүрешнең телгә карата булган таләбе һәм телнең әлеге таләпләргә җавап бирүенә нигезләнгән мәгънәләр: әдәби — диалекталь — жаргон, гомумкулланылыш — профессиональ кулланылыш, терминологик — образлы һәм башка мәгънәләр. Аңлашылганча, тел тамгаларының, шул исәптән сүзнең дә, мәгънә типлары күп төрле һәм бик тә катлаулы [Березин, 1979, с. 130].

Әлеге катлаулылыкның сәбәпләрен болай дип аңлатып була: һәрбер тел тамгасының, шул исәптән сүзнең дә, үзенә генә хас булган формасы (яңгырашы) бар һәм ул үзенә генә хас булган мәгънә белдерә алу мөмкинлегенә ия: фонема, асылда, структур мәгънәне белдерә, тамыр морфема объектлы һәм субъектлы мәгънәгә ия, аффиксаль морфемалар субъектлы һәм структур мәгънәне алып килә, лексик мәгънә һәр өч мәгънәне дә белдерә ала, морфологик мәгънәләр дә объектлы да, субъектлы да, структур да була ала.

Шул ук вакытта, һәр тел тамгасының, шул исәптән сүзнең дә, тел системасында һәм сөйләм системасында яши алуы мәгълүм. Тел тамгасының мәгънәсен билгеләгәндә, әлеге системаларның һәр икесенең дә нигез булып тора алуы мәгълүм. Санап кителгән типларда да икенче, өлешчә, дүртенче һәм бишенче мәгънәләрнең тел системасына, ә калганнарының чынбарлыкка, аң-фикергә мөнәсәбәткә һәм сөйләмгә нигезләнүе билгеле.

Лексик мәгънә хакында махсус язылган хезмәтләрдә дә сүзнең, бер яктан, телгә хас булган лексик-семантик системаның берәмлеге булуы, икенчедән, аралашу чарасы буларак, лексик-грамматик мәгънә берлегенә ия булуы, туры һәм күчерелмә мәгънәләрдә яши алуы дәлилләнә [Виноградов, 1953, с. 6].

Лексикология дәреслегендә [Сафиуллина, б. 15] һәм югары уку йортлары студентлар өчен төзелгән Программада [Хәзерге ..., б. 6] сүзнең тел күренеше һәм сөйләм күренеше булып яши алуы хакында әйтеп үтелә. Татар теленең өч томлык аңлатмалы сүзлегендә дә бу мәсьәлә шактый тәгаенләнеп аңлатыла, ягъни сүзләрнең тик торган халәтендәге мәгънәсен билгеләү белән бергә, аларның кулланылыш чикләре дә аерымлана: «Сүз кулланылышының хәзерге нормаларына нигезләнеп, сүзләргә стилистик характеристика бирелде,

аларның кулланылыш чикләре, эмоциональ төсмерләре күрсәтелде. Мәсәлән: кит. (китап теле сүзе), диал. (диалекталь сүз), күч. (күчмә мәгънәдә), мыск. (мыскыллап әйтү), махс. (махсус термин), лингв. (лингвистик термин) һ.б.» [Татар ... , 1979, Т. 1, б. 14]. Сүзлектән файдаланучылар өчен бирелгән белешмәдән күренгәнчә, кулланылыштагы сүзләрнең бүленеше түбәндәгечә: гомумкулланыштагы лексика һәм фразеология, әдәби әсәрләрдә очраган яки хәзерге телдә еш кулланыла торган гади сөйләм сүзләре, кайбер тупас һәм жаргон сүзләр, тарихи фактларны һәм электәге тормыш-көнкүрешне чагылдырган сүзләр, хәзер архаиклашкан яки искереп барган сүзләр, формалар һәм алынмалар, дингә, мифологиягә, ырым-йолаларга бәйләнешле төшенчәләрне белдерә торган сүзләр, киң кулланылышка кергән терминнар һәм махсус сүзләр, әдәбиятта еш очраган һәм киң кулланылышка кереп, әдәби телне баетырга ярдәм итә торган дип табылган диалекталь сүзләр, киң кулланылышка кергән неологизмнар һ.б. Аңлашылганча, сүзлеккә сүзләр алу аларның кулланылышына, ягъни сөйләмдә эш башкарган вазифаларына бәйле хәлдә чагылыш таба.

Сүзлеккә теркәлгән сүзләрнең мәгънәләрен билгеләгән вакытта да, аларның кулланылыш үзенчәлеге истә тотыла: «Мәгънәләрне алу сүзләрне алу принципларына туры китереп эшләнде. …Мәгънәләргә һәм мәгънә төсмерләренә аңлатма биргәндә, стилистик яктан нейтраль, туры мәгънәдәге һәм гомуми кулланыштагы сүзләр генә файдаланылды, тар кулланышлы (гади сөйләмдәге, поэтик, диалекталь, махсус һ.б.) сирәк очрый торган, искергән яки күчмә мәгънәдәге, шулай ук бу Сүзлеккә кертелми торган сүзләр кулланылмады» [Татар ..., Т. 1, б. 12]. Тагын шунысы да игътибарны җәлеп итә, сүзнең мәгънәсенә аңлатма аның кулланылышын билгели торган грамматик һәм стилистик үзенчәлекләрдән соң бирелә. Сүзнең барлык мәгънәләре һәм мәгънә төсмерләре теркәлә, аннан соң шул сүз белән хасил ителгән тезмәләр һәм фразеологик әйтелмәләр барлана. Шулай итеп, аерым бер сүз һәрьяклап характерлана. Сүзлекне төзүчеләрнең берсе һәм редакторы булган М.Г.Мөхәммәдиев әлеге мәсьәләне яктыртып махсус мәкалә яза һәм болай дип белдерә: «Татар теленең өч томлык Аңлатмалы сүзлегендә, лексикография практикабызда беренче буларак, сүзләргә тоташ һәм тулы грамматик характеристика бирү бурычы куелган иде. Башкарылган эшкә күз салсак, беренче карашка ул (әле беренче генә тәҗрибә булуын да искә алсак) уңай тәэсир калдыра ... һәр телдәге кебек, татар телендә дә сүзлек составы сүз төркемнәре, ягъни лексик-грамматик разрядлар буенча классификацияләнгәннәр. Бу хәлтелне, грамматиканы өйрәнү өчен генә түгел, лексикография эше өчен дә гаять әһәмиятле. Гадәтләнгән бүленеш (исем, сыйфат, фигыль, рәвеш һ.б.) сүзлектән файдалануны җиңеләйтә, укучыга теге яки бу сүзнең морфологик үзенчәлекләрен генә күрсәтеп калмый, аның төрле кулланыш мөмкинлекләрен, синтаксик-стилистик функцияләрен чамаларга да ориентирлаштыра. Шулай булгач, һәр сүз үзенә хас тип лексик-грамматик характеристика ала» [Мөхәммәдиев, б. 98—99]. Сүзнең мәгънәсен болай итеп барлау һәм анализлау үз чорының Европа һәм русистика фәне — лексикографиясе үсеше дәрәҗәсендә бара, ягъни «сүзнең лексик һәм грамматик

мәгънәләренең конструктив бирлеген» [Виноградов, 1947, с. 15] хасил иткән семантик структурасы аңлатыла.

**Әдәбият**

*Ахманова О.С.* Словарь лингвистических терминов. М.: Сов. Энциклопедия. 1969. 608 с.

*Березин Ф.М.* Общее языкознание: учебное пособие для студентов пед. ин-тов / Ф.М.Березин, Б.Н.Головин. М.: Просвещение, 1979. 415 с.

*Виноградов В.В.* Русский язык. Грамматическое учение о слове. М.- Л., 1947; М., 1972. 2-е изд..

*Виноградов В.В.* Основные типы лексических слов // Вопросы языкознания. М., 1953. №5. С. 3—29.

*Виноградов В.В.* Избранные труды. Лексикология и лексикография. М., 1977.

*Мөхәммәдиев М.Г.* Аңлатмалы сүзлектә сүзләрнең грамматик характеристикасы // Исследования по татарскому языкознанию. Казань: ИЯЛИ. 1984. 162 б.

*Сабиров К.С.* Лексикология // Хәзерге татар әдәби теле: югары уку йорты студентлары һәм урта мәктәп укытучылары өчен. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. Б. 17—40.

*Сабиров К.С.* Лексикология // Современный татарский литературный язык. М. : Наука, 1969. С. 52—80.

*Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология: югары уку йорты студентлары өчен. Казан: Хәтер, 1999. 288 б.

Татар грамматикасы: өч томда. Т. 1. Мәскәү: Инсан; Казан: Фикер. 1998. 512 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. Т. 1. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 475 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. Т. 2. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 726 б.

Философский словарь. М.: Изд-во Политической литературы, 1980. 444 с.

*Ханбикова Ш.С.* Татар телендә синонимия һәм сүзлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 208 б.

Хәзерге татар әдәби теле. Югары уку йортлары өчен программа: Тулыландырылган һәм төзәтелгән дүртенче басма. Казан, 2002. 51 б.

***Бәширова Илида Басыйр кызы**, филология фәннәре докторы,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*гомуми лингвистика бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145´366

***Ф.Ә. Ганиев***

# КУШМА ФИГЫЛЬЛӘР — ЛЕКСИКАБЫЗНЫҢ ЗУР БАЙЛЫГЫ

Татарский язык, как стало известно по последним исследованиям, является синтетико-аналитическим языком. В образовании его лексики значительную роль играют аналитические средства. В статье исследуются сложные глаголы татарского языка, имеющие две формы: 1) собственно сложные глаголы; 2) составные глаголы. Описывается их суть, даются критерии их различения.

**Ключевые слова:** сложные глаголы, собственно сложные глаголы, составные глаголы, модифицирующие глаголы, язык хинди, японский язык.

Татар телендә, башка төрки телләрдәге кебек, кушма фигыльләрнең ике төре бар: саф кушма фигыльләр һәм тезмә фигыльләр (русчасы: составные глаголы).

**Саф кушма фигыльләр.** Саф кушма фигыльләр *фигыль булмаган сүз + ярдәмче фигыль* яки *ярдәмче фигыль мәгънәсендә килгән фигыль* тибында ясалалар: *ярдәм итү, карар чыгару, харап булу, гашыйк булу, юкка чыгу, бүләк итү, киңәш итү, елт итү, ах итү, туры килү, хәл кылу, маневр ясау, хәбәр бирү, хәл алу* һ.б. Бу фигыльләрдә нигез булып исем (*тәэсир* итү), ияртем (*җем-җем* итү*, чымыр-чымыр* килү), сыйфат (*ап-пак* булу), хәбәрлек сүзләре (*юк* булу*, бар* булу) һ.б. килергә мөмкин.

Әлбәттә, бу төр саф кушма фигыльләр, кайбер галимнәр уйлаганча, рус теленең совершенный һәм несовершенный вид мәгънәләрен белдермиләр (мәсәлән, *ярдәм итү* фигыле рус теленең «*помочь*» һәм «*помогать*» фигыльләренең мәгънәсенә, *гашыйк булу* «*влюбиться*» һәм «*влюбляться*» фигыльләренең мәгънәләренә туры килә). Контекста бу төр кушма фигыльләр, бернинди дә кушымча алмыйча, ике төрнең дә («вид»ның да) мәгънәсен бирергә мөмкиннәр.

Бу төр кушма фигыльләр, сүзлекләрдә системалылык күзәтелмәсә дә, тегеләйме-болаймы биреләләр. Алар, һичшиксез, татар теленең мөстәкыйль сүзләрен, лексик берәмлекләрен тәшкил итәләр һәм алар сүзлекләрдә урын алырга тиеш.

Фигыль булмаган сүзләрдән кушма фигыльләр ясалышы турында беренче мәгълүматны без А.Казимбәк грамматикасында очратабыз [Казембек, 1846, с.161—162]. «Алтай теле грамматикасында» мондый кушма фигыльләр турында кыскача гына мәгълүмат та биреп үтелә [Грамматика..., с. 46].

Бу төр кушма фигыльләрне үзләренең грамматикаларында М.Терентьев һәм А.Архангельский күрсәтеп узалар [Терентьев, с. 187, 196; Архангельский, 63].

Алар турында тюркологиядә В.А.Гордлевский, А.Н.Кононов, Н.П.Дыренкова, Х.Байлиев, А.А.Юлдашев, Ә.Н.Нәҗип, А.Г.Алекперов, К.М.Мусаев, А.И.Искаков, В.А.Исенгалиева, М.М.Текуев һ.б.ның хезмәтләрендә дә [Гордлевский, с.101; Кононов, с.117—118; Кононов, с.259; Дыренкова, с.193; Байлиев, с.55; Юлдашев, с.104; Наджип, с.209; Алекперов, с.55; Мусаев, с.241; Искаков, с.88; Исенгалиева;

Текуев, с.7] шактый мәгълүмат китерелә.

Татар тел белеменең беренче грамматикаларында саф кушма фигыльләр турында мәгълүмат бик кыска һәм бик саран бирелгән.

И.Гиганов һәм А.Троянский үзләренең грамматикаларында мондый кушма фигыльләргә мисаллар гына китерәләр. К.Насыйри исә бу төр кушма фигыльләргә киңрәк туктала. Җ.Вәлиди, Г.Алпаров, Ш.Рамазанов, В.Хангилдин, Д.Тумашева, Ф.Миңнуллин хезмәтләрендә дә алар турында шактый мәгълүмат урын алган [Гиганов, с. 50; Троянский,1814, с. 60; Насыйри, б. 78; Вәлиди, б. 50; Алпаров, б. 178—180; Хангилдин, б.159; Тумашева, б. 233].

Күренгәнчә, һәм татар тел белемендә, һәм тюркологиядә саф кушма фигыльләр үзләренә лексик берәмлек буларак танылу тапканнар. Мәгълүм булганча, шул нигездә аларның бер өлеше татар теле сүзлекләрендә дә, төрки телләр сүзлекләрендә дә бирелеп киләләр.

Тезмә фигыльләр. Тезмә фигыльләр татар телендә -ып/ -еп, -п яисә -а, -ә, -й, -и кушымчаларына тәмамланган хәл фигыльләргә модификацияләүче фигыльләр кушылып ясалалар. Кушма фигыльләрнең бер төре булган тезмә фигыльләр татар теленең үзенчәлекле бер күренешен тәшкил итәләр.

Кушма фигыльләрнең мондый тибы, мәсәлән, япон һәм һинд телләрендә дә очрый.

Тюркологларның күпчелеге хәл фигыльгә модификацияләүче фигыль кушылып ясалган кушма фигыльләрне, тезмә фигыль, дип атыйлар. Грамматикаларның, фәнни хезмәтләрнең күпчелегендә, тезмә фигыльләр мөстәкыйль сүз, лексик берәмлек, дип таныла.

Беренче мәртәбә алар И.Гиганов, А.Казимбәк, М.Иванов, А.Троянскийның грамматикаларында искә алына [Гиганов, с. 171; Казембек, 1839, с. 161; Иванов, с. 89; Троянский, 1869, с. 39]. Тезмә фигыль («составной глагол») дигән терминны беренче башлап А.Казимбәк куллана.

Тюркологлардан А.Н.Кононов, В.М.Насилов, Н.А.Баскаков үзләренең хезмәтләрендә тезмә фигыльләрнең үзенчәлеген билгеләп, аларны нигездә мөстәкыйль фигыльләргә кертеп карыйлар [Кононов, 1960, с. 263—264; Насилов, 1947; Баскаков, с. 352].

Азәрбайҗан теле белгече А.Г.Алекперов, алтай теле белгече А.Т.Тыбыкова, казакъ теле белгече Н.О.Оралбаева, карачай-балкар теле белгече М.М.Текуев тезмә фигыльләрне, лексик берәмлек, дип һәм, төр («вид») категориясен белдерми, дип саныйлар [Алекперов, с. 55; Тыбыкова; Текуев; Оралбаева].

Октябрь революциясенә кадәр үк татар галимнәре Ә.Максудый, Г.Нугайбәк, Г.Сәгъди һ.б. үзләренең грамматикаларында тезмә фигыльләр турында мәгълүмат бирәләр [Максуди, 1910; Нугайбәк, 1911; Сәгъди, 1913].

Октябрь революциясеннән соң тезмә фигыльләргә ныграк игътибар ителә башлады. Г.Ибраһимов, М.Корбангалиев, Х.Бәдигый, Җ.Вәлиди, Г.Алпаров хезмәтләрендә тезмә фигыльләргә кыскача анализ ясала [Ибраһимов, 1918; Корбан-Гали, Бәдигый, 1918; Вәлиди, 1919; Алпаров, 1945]. Г.Алпаров, Р.Газизов, В.Хангилдин, ярдәмче фигыльләр төп фигыльгә өстәмә мәгънә бирәләр, тезмә фигыльләр мөстәкыйль фигыль булып тора, дип саныйлар [Алпаров, 1945; Газизов, 1959; Хангилдин, 1959].

Тезмә фигыльләр дөнья телләре өчен бөтенләй ят нәрсә түгелләр. Әйтеп узганыбызча, алар һинд һәм

япон телләрендә бар. Һинд телләре белгече А.П.Баранников, кушма фигыльләрнең бу тибы һинд телендә оригиналь күренеш булып тора, алар һинд фигыльләренең яртысыннан ким түгел, ясалышлары нигез фигыльнең күп булмаган ярдәмче фигыльләр кушылуыннан гыйбарәт, икенче фигыль төп фигыльнең мәгънәсен модификацияли, дип яза [Баранников, с. 106].

Япон теле белгече А.А.Пашковский «Япон телендәге кушма сүзләрне классификацияләү» дигән мәкаләсендә, япон телендә, фигыльнең ике нигезен кушып, кушма фигыльләр ясау бик киң кулланыла, бу фигыльләр япон теленең сүзлекләрендә бирелә, дип яза. *Каку* «язу» дигән гади фигыль янында сүзлекләрдә *какидасу* «яза башлау», *какиреру* «күчереп алу» дигән кушма фигыльләр китерелүен күрсәтә [Японский..., с. 36].

Кайбер белгечләр әйткәнчә (Н.З.Бакеева, Ә.И.Харисов һ.б.), тезмә фигыльләр төгәлләнгән һәм төгәлләнмәгән төр («вид») категориясен белдермиләр. Бу турыда соңгы вакытта ике төрле фикер юк. Модификацияләүче фигыльләр (аларны еш кына бик төгәл булмаган термин белән «ярдәмче фигыльләр» дип атыйлар) һәрвакыт тезмә фигыльгә өстәмә лексик төсмер бирәләр. Барлык тезмә фигыльләр хәзерге заман формасында кулланыла алалар, тәмамланганлык-тәмамланмаганлык ягыннан икегә бүленмиләр. Бу үзенчәлекләр тезмә фигыльләрнең (төр) категориясен китереп чыгармыйлар.

Төрки телләрдәге тезмә фигыльләр, нәкъ япон һәм һинд телендәге кебек, мөстәкыйль фигыль, лексик берәмлек булып торалар.

Тюркологиядә, соңгы вакытка кадәр диярлек, тезмә фигыльләргә тиешле игътибар бирелмәде, аларны лексик берәмлек буларак танып сүзлекләргә кертү мәсьәләсе дә көн тәртибенә куелмады.

Югарыда әйтелгәнчә, тезмә фигыльләр *«п»*га яки *«а, ә, й, и»* гә тәмамланган хәл фигыль белән модификацияләүче фигыльдән гыйбарәтләр.

Телдә шундый ук мөстәкыйль синтаксик конструкцияләр дә очрый. Шуңа күрә мондый тезмәләрнең синтаксик конструкцияме, әллә тезмә фигыльме икәнен билгеләү кайвакыт җиңел булмый.

Мондый конструкцияләр түбәндәге очракларда синтаксик конструкция тәшкил итәләр: 1) хәл фигыль — хәлне, ә аның артыннан кулланылган фигыль төп эш-хәрәкәтне белдерсә; 2) хәл фигыль һәм аның артыннан килгән фигыль параллель яки эзлекле эш-хәрәкәтне белдерсә.

1. Беренче очракта хәл фигыль рәвеш, сәбәп һ.б. хәлләрне белдерә, хәл фигыльгә затланышлы формада кушылып килгән фигыль нинди дә булса башка җөмлә кисәге, гадәттә хәбәр булып килә: *Бу хатны ничек башларга белмичә бик озак* ***аптырап утырдык*** (Г.Бәширов).

Югарыда китерелгән җөмләдә *аптырап утырдык* комбинациясе арасына җөмләнең мәгънәсенә һәм бөтенлегенә зыян китермичә, өченче сүз кертергә мөмкин: *Бу хатны ничек башларга белмичә бик озак* ***аптырап, уйланып утырдык***. Күренгәнчә, җөмләнең бөтенлеге җөмләгә бер сүз китереп кертүдән җуелмады. Шул ук комбинациядә хәл фигыль бөтенләй төшеп тә калырга мөмкин: *Бу хатны ничек башларга белмичә бик озак ...* ***утырдык***. Хәл фигыльне төшереп калдырудан җөмләнең бөтенлеге бозылмый.

Димәк, фигыльләрдән гыйбарәт ирекле сүзтезмәләр (бу очракта

хәлнең хәбәр белән бергә килүе), тышкы структурасы ягыннан тезмә фигыльләргә охшасалар да, аларны тезмә фигыльләрдән аера торган берничә үзенчәлек бар: ул конструкциягә кергән сүзләрнең өченче сүз белән аерыла алу ягъни ике фигыль арасына өченче сүзне кертә алу мөмкинлеге; хәл фигыльне төшереп калдырганда җөмләнең бөтенлеге җуелмавы; ике фигыльнең семантикаларының мөстәкыйльлеге, синтаксис күзлегеннән караганда икесенең дә ике җөмлә кисәге булып килүе; ике фигыльнең дә мөстәкыйль басымга ия булуы. Тезмә фигыльләргә бу билгеләр хас түгел.

2. Икенче очракта хәл фигыль һәм аның артыннан килә торган фигыль параллель яки эзлекле эш-хәрәкәтне белдерәләр: *Ул җилтерәп кенә чыгып, сыерын ябып, **юынып керде*** (Г.Бәширов). *Бала тудыру йортына **кереп чыкты**.* (Г.Әпсәләмов). Югарыда китерелгән мисалларда *хәл фигыль+затланышлы формадагы фигыль* үзләренең тышкы структурасы ягыннан сүз тезмәләрен хәтерләтәләр, әмма эчтәлекләре ягыннан сүз тезмәләреннән тамырыннан аерылалар, чөнки алар бердәм мәгънә хасыйл итмиләр, икесе ике төрле мәгънә, эзлекле башкарылган эш-хәрәкәтне белдерәләр. Өстәвенә ул комбинациягә кергән сүзләр арасына өченче сүзне кертергә мөмкин: *Бала тудыру йортына **кереп, табибны күреп чыкты**.* Ул конструкцияләргә кергән сүзләр арасында үзара семантик бәйләнгәнлек, мәгънә керешүе күзәтелми. Алар бу яктан автоном, мөстәкыйль сүз булып торалар.

Шуны да искәртеп китү артык булмас: тезмә фигыльләр фигыльләрнең кушма грамматик формаларыннан да аерылалар, чөнки алар телдә яңа сүз тәшкил итмиләр. Мәсәлән, *бара иде, барган иде, бара торган иде* кебек заман формаларында соңгы элементлары яңа лексик мәгънә алып килмиләр, ә саф грамматик мәгънә генә белдерәләр. Кушма модаль формалар да тезмә фигыль булып тормыйлар, чөнки *яза алу, укый алу, эшли белү* кебек модаль формаларда икенче компонент лексик мәгънәгә ия түгел, бары грамматик функция генә, модаль мәгънә генә белдерә.

Күренгәнчә, кушма заман формалары да, кушма модаль формалар да кушма сүз булып тормыйлар, ягъни теләсә нинди кушма форма кушма сүз дигәннне аңлатмый. Кушма формалар рус телендә дә очрый: *самый хороший, буду писать* һ.б. Әмма бу кушма формаларны кушма сүзләр дип санап булмый, чөнки аларның компонентларының берсе реаль мәгънәгә ия түгел, бары грамматик функциядә генә килә.

Кушма сүз статусына тезмә фигыльләр ия булып торалар. Алар түбәндәге үзенчәлекләр белән характерланалар.

*Беренчедән,* тезмә фигыльләр бер мәгънә белдерәләр. Мәсәлән, *Мин бу китапны укып чыктым* җөмләсендә *укып чыктым* дигән тезмә фигыль яңа бер мәгънә белдерә. Билгеле булганча, рус, немец телләрендә бу мәгънә приставкалы фигыльләр белән белдерелә: *прочитать, überlesen.* Ә тезмә фигыльләргә охшаган ирекле сүзтезмәләр икесе ике төрле мәгънә (хәл һәм хәбәр яки эзлекле һәм параллель башкарыла торган ике төрле эш-хәрәкәтне) белдерәләр.

Татар телендә кайбер тезмә фигыльләр аларны тәшкил иткән компонентларның мәгънәләре суммасын тәшкил итәргә мөмкиннәр: *укып бетерү, ашап бетерү*. Ләкин күпчелек тезмә фигыльләрнең мәгънәләрен турыдан-туры компонентларының мәгънәләреннән китереп

чыгарып булмый: *укып чыгу, каушап төшү, карап алу* һ.б.

*Икенчедән*, тезмә фигыльләр җөмлә составында бары бер генә җөмлә кисәген белдерәләр. Әйтик, *Мин бу китапны укып чыктым* җөмләсендә *мин* сүзе — ия, *бу* — аергыч, *китапны* — тәмамлык, *укып чыктым* — хәбәр. Ә ирекле сүзтезмәләргә караган сүзләр икесе ике җөмлә кисәген тәшкил итәләр.

*Өченчедән*, тезмә фигыльләр составына кергән компонентлар, җөмләне бозмыйча, бер-берсеннән аерыла алмыйлар. Мәсәлән, *Мин чыктым укып бу китапны* дип әйтү татар теле нормасына туры килми.

Татар телендә тезмә фигыльләргә кергән компонентлар арасында бары мөстәкыйль булмаган кайбер сүзләрне генә кулланырга мөмкин: *-да/-дә(-та/-тә), -гына/-генә (-кына/-кенә)*: *Наташа сәхнәгә менеп тә җитте* (Г.Бәширов).

*Дүртенчедән*, тезмә фигыльләргә кергән компонентлар арасына өченче бер сүзне куеп булмый: *Мин бу китапны укып кичә чыктым* дисәң, җөмлә татарча булып чыкмый. Ирекле сүз тезмәләрендә исә сүзләр арасында өченче сүзне (сүзләрне) бик иркен кулланырга мөмкин. Мәсәлән, *Мин шәһәргә барып кайттым* җөмләсендәге эзлекле эш-хәрәкәтне белдергән *барып кайттым* сүзтезмәсендәге сүзләр арасына *Мин шәһәргә барып кире кайттым. Мин шәһәргә барып костюм алып кайттым* һ.б. дип, җөмләнең бөтенлеген бозмыйча, сүзтезмәдәге сүзләр арасына өченче сүзне кертергә мөмкин.

*Бишенчедән*, тезмә фигыльләрдә, ирекле сүз тезмәләрендәге кебек, үзара синтаксик мөнәсәбәт күзәтелми. *Укып чыктым* тезмә фигылендә бернинди дә синтаксик мөнәсәбәт табып булмый, ә *аптырап утырдык* ирекле сүз тезмәсендә ачыктан-ачык синтаксик мөнәсәбәт (хәл белән хәбәр мөнәсәбәте) чагыла.

*Алтынчыдан,* тезмә фигыльләрнең компонентлары мәгънәләре үзара керешәләр, аларның икенче компоненты төп фигыльнең мәгънәсенә өстәмә мәгънә кертә, алар, җөмләнең бөтенлеген бозмыйча, берсе икенчесеннән башка яши алмыйлар. Мәсәлән, *Мин бу китапны укып чыктым* җөмләсендә *чыктым* мөстәкыйль кулланыла алмый: *Мин бу китапны чыктым* дип, җөмләне бозмыйча, мәгънәгә зыян китермичә, әйтеп булмый.

Ирекле сүз тезмәләрендә затланышлы фигыль (конструкциянең икенче компоненты) җөмлә кисәге булып тора, ул хәл фигыльгә генә түгел, ә бөтен җөмләгә бәйләнгән. Шуңа күрә ул мөстәкыйль рәвештә кулланыла ала: *Бу хатны ничек башларга белмичә бик озак аптырап утырдык* җөмләсендә хәл фигыльне төшереп калдырырга мөмкин, әмма җөмләнең бөтенлеге бозылмый.

*Җиденчедән,* тезмә фигыльләрнең бердәм басымы була, алар бердәм басым нигезендә ныгып берләшәләр: *укы›п чыгу, кауша'п төшү* һ.б.

Югарыда күрсәтелгән үзенчәлекләр тезмә фигыльләрнең мөстәкыйль сүз, лексик берәмлек булуларын кире каккысыз исбатлый.

Кагыйдә буларак, тезмә фигыльләрнең төп мәгънәсе аларның беренче компоненты белән бирелә, икенче компоненты — модификацияләүче фигыль өстәмә лексик мәгънә алып килә, беренче компонентның мәгънәсен аныклый төшә, конкретлаштыра [Ганиев, 1963; Ганиев, 1971].

Шулай ук неологизмны тәшкил иткән барлык фигыльләр дә тезмә фигыльләр ясый ала: *авто-*

*матлаштырып бетерү, абстракцияли төшү* һ.б.

Шулай итеп, татар тел белемендә, беркадәр тюркологиядә дә, тезмә фигыльләрнең лексик берәмлек булуы исбатлануга карамастан, аларга һаман да игътибар җитеп бетми.

Минемчә, моның сәбәбен төрки телләрне, шул исәптән татар телен, агглютинатив (кушымчалы) тел дип санаудан эзләргә кирәк. Югыйсә төрки телләрдә грамматик чараларның да, сүзьясалыш чараларының да яртысын, аерым очракта яртысыннан күбрәген, **аналитизм** тәшкил итә.

Икенче яктан, консерватив караш тиз генә үзенең урынын яңалыкка бирәсе килми күрәсең.

Шулай да татар тел белемендә, аның академик грамматикасында тезмә фигыльләргә лексик берәмлек буларак тиешле урын бирелде.

Иң куанычлысы шунда: «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә (2005 ел) төп фигыльләрдән соң, еш кулланылган актуаль тезмә фигыльләр бирелде. Бу үрнәк С.И.Ожеговның бертомлык сүзлегеннән алынды. Анда нисби сыйфатлар ясалган төп сүздән соң, аңлатма бирелмичә генә, аларның исемлеге теркәлгән.

Тезмә фигыльләрнең татар теленең бертомлык аңлатмалы сүзлегендә системалы рәвештә исемлеге бирелүе төрки телләр сүзлегендә беренче карлыгач булып тора. Моны Мәскәү галимнәре хупладылар.

Киләчәккә планлаштырылган татар теленең 5 томлык аңлатмалы сүзлегендә, тезмә фигыльләрнең исемлеге белән генә канәгатьләнмичә, аларны аңлатмалары белән бөтен система буларак бирү күз алдында тотыла.

Татар телендә тезмә фигыльләр ясауда түбәндәге модификацияләүче фигыльләр катнаша: *алу, ату, бару, башлау, бетерү, бетү, бирү, җибәрү, җиткерү, җитү, йөрү, калу, карау, керү, килү, китү, кую, салу, тору, төшү, узу, утыру, чыгару, чыгу, язу, яту, җибәрү, җиткерү, җитү* (бу фигыльләрнең барысы да «Инструкция»дә каралган).

Алар аерым кулланганда мөстәкыйль фигыль, лексик берәмлек булып торалар, тезмә фигыльләр ясауда катнашканда модификацияләүче («ярдәмче») фигыльгә әйләнәләр.

Бу мәкаләдә, нигездә, киң җәмәгатьчелекне татар теле лексикасының зур байлыгын тәшкил иткән тезмә фигыльләр белән таныштыру бурычы куелды.

Татар телендә, барлык чыганаклардан җыйганда тезмә фигыльләрнең саны берничә дистә меңгә якын, дип фаразлана.

## Әдәбият

*Алекперов А.Г.* Сложные глаголы в современном азербайджанском языке: АКД. Баку, 1961.

*Алпаров Г.* Сайланма хезмәтләр. Казан, 1945.

*Архангельский А.* Грамматика народно-татарского языка. Оренбург, 1894.

*Байлиев Х.* Сложные глаголы в туркменском языке// Проблемы туркменской филологии. Т. I. Ашхабад, 1944.

*Баранников А.П.* Хиндустани (грамматика). Л., 1934.

*Баскаков Н.А.* Грамматика каракалпакского языка. Т. II. М., 1952.

*Вәлиди Җ.* Татар теле грамматикасы. Казан, 1919.

*Газизов Р.С.* Сопоставительная грамматика татарского и русского языков. Казан, 1959.

*Ганиев Ф.А.* Видовая характеристика глаголов татарского языка. Казань: Таткнигоиздат. 1963.

*Ганиев Ф.А.* К вопросу о сложном глаголообразовании в тюркских и монгольских языках// Проблемы общности алтайских языков. Л.: Наука, 1971.

*Гиганов И.* Грамматика татарского языка. СПб., 1801.

*Гордлевский В.А.* Грамматика турецкого языка. М., 1928.

Грамматика алтайского языка. Казань, 1869.

*Дыренкова Н.П.* Грамматика шорского языка. М.-Л., 1941.

*Ибраһимов Г.* Татар сарфы. 5 нче басма. Казан, 1918.

*Иванов М.* Татарская грамматика. Казань, 1842.

*Исенгалиева В.А.* Тюркские глаголы с основами, заимствованными из русского языка. Алма-Ата, 1966.

*Искаков А.И.* Морфологическая структура слова и именные части речи в современном казахском языке: АДД. Алма-Ата, 1964.

*Казембек А.* Общая грамматика турецко-татарского языка. Казань, 1839.

*Казембек А.* Грамматика турецко-татарского языка. 2-е изд. Казань, 1846.

*Кононов А.Н.* Грамматика современного турецкого литературного языка. М.-Л., 1941.

*Кононов А.Н.* Грамматика современного узбекского литературного языка. М.-Л.,1960.

*Корбан-Гали М., Бәдигый Х.* Ана теле сарфы. Казан, 1918.

*Максудый Ә.* Төрки сарыф. Казан, 1910.

*Мусаев К.М.* Грамматика караимского языка. М., 1962.

*Наджип Э.Н.* Современный уйгурский язык. М., 1960.

*Насилов В.М.* К вопросу о грамматической категории вида // Труды Московского института востоковедения. 1947. № 4.

*Насыйри К.* Әнмүзәҗ. Казан, 1898.

*Нугайбәк Г.* Төрлек. Казан, 1911.

*Оралбаева Нуржамал.* Қазіргі казак тiliңгeгi etistikten аналитикалык форманттары. Алма-Ата, 1975.

*Сәгъди Г.* Яңы һәм йеңел тәртиптә телебезнең сарфы. Казан, 1913.

*Текуев М.М.* Сложные глаголы в карачаево-балкарском языке в сравнительном плане. АКД. М., 1973.

*Терентьев М.* Грамматика турецкая, персидская, киргизская и узбекская. СПб., 1875

*Троянский А.* Татарская грамматика. Казань, 1814.

*Троянский А.* Краткая татарская грамматика. Казань, 1869.

*Тумашева Д.Г.* Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. Казан, 1964.

*Тыбыкова А.Т.* Сложные и составные глаголы в алтайском языке: АКД. М., 1963.

*Хангилдин В.Н.* Татар теле грамматикасы. Казан, 1959.

*Юлдашев А.А.* Система словообразования и спряжения глагола в башкирском языке. М., 1958.

Японский лингвистический сборник. М., 1959.

***Ганиев Фуат Әшраф улы,***
*профессор, филология фәннәре докторы,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*гомуми лингвистика бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145›373

***М.М. Шәкүрова***

# ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕ ҺӘМ БӘЕТЛӘРЕНЕҢ ЛЕКСИК-СЕМАНТИК ҺӘМ СТИЛИСТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Исследование лексико-семантических, стилистических особенностей сказок и баитов, целостная их оценка позволяет по-новому взглянуть на время создания данных произведений, выявить особенности национальной культуры того периода, а также обнаружить разнообразные смысловые оттенки глаголов в контексте словарного богатства татарского языка. Статья посвящена исследованию теории и методики лингвистического анализа художественного текста на материале татарской народной сказки и баитов. Задача определения языковых особенностей фольклорных текстов обусловливает необходимость лингвистического анализа литературных произведений этого типа.

**Ключевые слова:** фольклорный текст, сказка, баит, глаголы, филологический анализ, лексика татарского устного народного творчества.

Әдәби әсәрләргә, фольклор текстларына бәйле мәсьәләләр, стилистика өлкәсе, стилистика һәм синоним арасындагы нисбәт рус тел белеме галимнәре А.А.Потебня, А.М.Пешковский, Л.В.Щерба, В.В.Виноградов, А.Н.Гвоздев, А.И.Ефимов, В.П.Сухотин, Г.Я.Солганик, Ю.М.Лотман, А.И. Горшков, Н.А.Николина, Л.Г.Бабенко һәм татар тел белгечләре В.Н.Хангилдин, Х.Р.Курбатов, М.З.Зәкиев, В.Х.Хаков, Ш.С.Ханбикова, С.М.Ибраһимов, М.Х.Бакиров, Ф.С.Сафиуллина, Г.Ф.Саттаров, И.Б.Бәширова, Ф.И.Урманчеев, Р.С.Абдуллина, Ф.Х.Җәүһәрова һ.б.ларның хезмәтләренә таянып өйрәнелә.

Әдәби әсәрләрдән алган өзекләр, XX гасыр башы татар әдәбиятын тирәнрәк өйрәнү белән бергә, әсәрләрнең лексик үзенчәлекләрен дә тикшереп-карап үтүнең мөһимлеген, тарихи-мәдәни белешмә бирүнең, гомумән, комплекслы өйрәнү зарурилыгын ассызыклау өчен тикшерелә. Биредә абзацара бәйләнешләр җентекләп карала, текстның сүзлек составы ачыклана, морфологик, синтаксик һәм пунктуацион үзенчәлекләре күрсәтелә. Болар ярдәмендә герой-персонажларның эчке кичерешләрен, психологик моментларын, рухи дөньяларын тирәнрәк итеп ачып була.

Гомумән, тел үзенчәлекләрен ачыклау әдәби әсәргә лингвистик анализ ясауга ихтыяҗ тудырды. Беренчедән, әсәрләрнең лексик-семантик, стилистик үзенчәлекләрен тикшерү, бөтенлектә бәя бирү кызыклы күзәтүләр ясарга, әсәр язылган чорга, ул елларда татар мәдәниятенә хас сыйфатларны барларга, тарихи үзенчәлекләрне билгеләргә мөмкинлек бирер иде [Шакурова, с. 278]. Икенчедән, филологик анализ исә сүзләрнең этимологиясенә, беренчел һәм икенчел мәгънәләренә, синонимик, антонимик, омонимик, фразеологик мөнәсәбәтләргә керү үзенчәлекләренә, сүз төркемнәренә дә туктала. Болардан тыш, текст белән эш итү башка киңлекләр дә ача: текстның семантик һәм хисси-эмоциональ кырын билгеләү, абзацара бәйләнешне ачыклау, морфологик, синтаксик һәм пунктуацион үзенчәлекләрне барлау, стилистик ялгышларга күзәтү ясау, сүз төркемнәренең стилистик кулланы-

лыш үзенчәлекләрен билгеләү һ.б. Өченчедән, әдәби әсәрләрнең теле өстендә эшләгәндә, татар теленең бәйләүче чараларга бик бай тел булуын тоясың. Шул чаралар системасын, алар белдергән мәгънәләрне нәтиҗәлерәк үзләштерү максатыннан, стиль мөмкинлекләрен дә исәпкә алып, сүзтезмәләр һәм аларның синонимлыгына да мөрәҗәгать итәргә туры килә. Сөйләмдә сүзтезмәләрне куллану һәм аңа бәйле күренешләрне өйрәнү стилистиканың бик тә әһәмиятле мәсьәләләреннән санала. Дүртенчедән, әдәби әсәргә анализ ясаганда туган төбәкнең ономастикасын җентекләп тикшерергә дә тулы мөмкинлекләр ачыла. Соңгы елларда укучы кеше исемнәре һәм фамилияләре, кушаматлар, нәсел шәҗәрәләрен өйрәнү белән чын-чынлап кызыксына, сүз төркемнәренең (бигрәк тә фигыльләрнең) стилистик үзенчәлекләренә киңрәк туктала башлады. Аннары татар теле һәм әдәбияты дәресләренә (аерым алганда, дәрестән тыш уку дәресенә, татар теленнән факультатив дәресләргә һ.б.) филологик анализ элементлары кертү, тарихи экскурс ясау һәм билгеле бер чор татар әдәбиятына, фольклорына, мәдәниятенә һәм тарихына хас үзенчәлекләргә тукталу — укучының акыл куәсен арттыра гына.

Татар халык әкиятләренең үзләренә генә хас үзенчәлекләре бар, ул хайваннар турындагы әкиятме, әллә тормыш-көнкүрешне яктырткан яки тылсымлы әкиятләрме, укучыны бүген дә уйландыра, дулкынландыра, әдәпле һәм намуслы булырга өнди. Әкиятләрдә сүз уйнату, сүз җилеме, сүз көрәштерү, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, геройларның үз-үзен тотышы, кыланышы, сөйләме, сүзлек составы — һәрберсе аерым урын алып тора. Аларда халыкның якты уйлары, хыяллары чынга аша, гаделлек өчен көрәше гәүдәләнә. Әкиятләргә анализ ясаганда, татар халык иҗатына хас булган милли жанр — бәеткә дә махсус игътибар ителде. Кеше күңелендә туган хис-кичерешләрне тасвирлаганда, текстның сүзлек составы, тел-сурәтләү чаралары ачыклана, морфологик, синтаксик һәм пунктуацион үзенчәлекләр күрсәтелә, чагыштырулы төзелмәләр тикшерелә.

Бәет — гарәп сүзе, ике юллык шигырь дигәнне аңлата, аның нигезендә кайгылы яисә көлкеле вакыйга ята [Татар ..., 1983, б.5]. Бәетләрнең сүзлек составын тикшергәндә, аларның тарихи вакыйгалар һәм шәхесләргә багышланганнары, шулай ук хатын-кызларның михнәтле язмышларын чагылдырган, шәхси фаҗигаләрне бәян иткәннәре аеруча күз уңында тотыла. Фольклор текстлы белән эшләгәндә халыкның нинди сүзләр сайлавына — ул сүзләр туры яки күчерелмә мәгънәдәме, күпмәгънәле сүзме икәнлегенә — бәйләүче чараларның, чагыштырулы төзелмәләрнең кайсысын күбрәк кулллануына игътибар ителә.

Фольклор әсәрләренең теле, бер яктан, халыкның язма әдәби теленә, икенче яктан, халыкның җанлы сөйләм теленә якын тора. *Кичә бардым ие, өченче кич кайткан ием* [Татар ..., 2007, б. 181]; — *Әтәй, — ди малай, — сез бер дә кайгырмагыз, мин кайтып җитәрмен әле, — ди* [шунда ук, б. 249]; *Шул заманда булган икән, ди, патша. Аның булган алма бакчасы* [шунда ук, б. 86].

Әкиятләр башка жанрлар арасында мөһим урын алып тора: теле, төзелеше гади, күбрәк кыска-кыска,

гади җөмләләр кулланыла. *Борын заманда булган икән бер патша. Бу патшаның ике улы булган* [шунда ук, б. 33]; *Ярар. Инде бу баланы тәрбияләп асрап үстерәләр. Бала үсә, алты-җиде яшьләренә җитә. Малайны бик яхшылап тәрбиялиләр болар* [шунда ук, б. 73].

Әкиятләр, бәетләр фигыльләрнең кулланылышы ягыннан бик үзенчәлекле. Фигыль — төрки телләрдә гаять катлаулы сүз төркеме. Әлеге сүз төркеменең барлыкка килү, грамматик категорияләренең формалашу тарихы да кызыклы:

Хәзерге татар телендә борынгы төрки телдә кулланылган фигыль формалары үзгәрешсез саклана: *-а, -ә, -ды, -де, -ган, -гән.*

Мәгънә үзгәреше кичергән фигыль формалары да бар.

Кайбер фигыль формалары диалектларда гына сакланып калган.

Яңа фигыль формалары барлыкка килгән.

Фигыльләрне семантик (тематик) төркемләүгә төрки-татар тел белемендә Н.К.Дмитриев, Э.Р.Тенишев, Д.Г.Тумашева, Ф.Ә.Ганиев, Ф.М.Хисамова, Ә.Ә.Юлдашев, Н.З.Гаджиева, Т.Н.Васильева һ.б. хезмәтләрендә зур урын бирә. Н.К.Дмитриев төрек, татар, башкорт һәм кайбер башка төрки телләрдәге сөйләү, фикерләү, эш һәм хәрәкәт фигыльләренең төп лексик берәмлекләрен тикшереп чыкты [Дмитриев, с. 570—598].

Татар телендә фигыльләрне мәгънәләре буенча төркемнәргә аеру мәсьәләсендә беренче тәҗрибә Ф.Ә.Ганиев тарафыннан ясалды. Ул «Татар телендә фигыльләрнең семантик төркемнәре» мәкаләсендә фигыльләрне 11 зур төркемгә бүлә: хәрәкәт, эш, процесс, хәл, мөнәсәбәт, үз-үзеңне тоту, яңгыраш, сөйләм, фикерләү, сиземләү һәм образ ияртемнәренә нигезләнеп ясалган фигыльләр [Ганиев, 2009, б. 101].

А.Г.Шәйхуллов исә телнең сүзлек составын дүрт төп тематик төркемгә бүлеп өйрәнә: 1) табигать 2) кеше, 3) җәмгыять, 4) танып-белү [Шайхулов, с. 20]. Автор тәкъдим иткән төркемнәр арасында тере һәм тере булмаган табигать аеруча игътибарга лаек: туганлык мөнәсәбәтләрен, кешеләрнең төрле һөнәр-шөгыльләрен, хайваннар, кошлар, үсемлекләр дөньясын, урын, вакыт төшенчәсен, кешенең йорт-җирен, киемсалымын һәм тукымаларны, бизәнү әйберләрен һ.б.ны белдергән лексика. С.М.Арсланова, телдәге барлык сүзләрне дә семантик яктан, ягъни мәгънәләренең якынлыгы яки охшашлыгы буенча төркемләргә мөмкин, дип саный [Арсланова, с. 18]. Дөрестән дә, фольклор текстында сүзләрне семантик яктан берләштереп төркемләргә мөмкин. Татар халык әкиятләре, бәетләрнең (шулай ук мөнәҗәтләрнең) лексикасы фигыльләрнең лексик-семантик төркемнәре күп булу белән характерлана. Аларның берничәсенә тукталып үтү урынлы булыр.

1. Хәрәкәт фигыльләре: *бару, йөгерү, йөрү, чыгу, йөзү, очу.* Мәсәлән: *Егет хатыннан сорый: — Бу елганы ничек* ***чыгарга****? — ди* [Татар ..., 2007, б. 122]; ***Бара, бара*** *бу,* ***бара*** *торгач, бик зур бер урманга* ***барып*** *кerә* [шунда ук, б. 226].

2. Эш фигыльләре:

1) анык эшне белдергән фигыльләр: *кисү, кыйнау, вату, агызу, турау, тарау, тезләнү, юу, кисү* һ.б. Мисаллар: *Карчык, бик оялып, бәлешне* ***кисте*** [Татар ..., 2007 б. 116]; *Бардым урманга,* ***кистем*** *пар каен; Газиз әнкәмне сагынам көн саен* [шунда ук, б. 226];

2) анык булмаган эшне белдергән фигыльләр: *ябырылу, саклау, яулау,*

*тар-мар иту, тар-мар кылу* һ.б.: *Теге япанчы абышка биргән кылычын чайкап җибәргән икән, күз ачып йомганчы җиде патша яуларын* ***тар-мар иткән****, ди* [Татар ..., 2007, б. 84]; *Хәбир мулла — ил мулласы, капка төбен* ***саклыйдыр****; Хәбир мулла кыз утергән, куяр җирен тапмыйдыр* [Татар ..., 1983 б. 166]; *Әллә дошман җирләрендә тоткын булып ятамсың? Әллә яуны* ***тар-мар кыйлгач****, илебезгә кайтамсың?* [Шунда ук, б. 244];

3) табигать күренешләрен белдергән фигыльләр: *агу (су), ату (таң), чыгу (кояш, җил-давыл), ялт-йолт иту (яшен), исү (җил), пешү (җиләк), яву (кар, яңгыр), шаулау (агач)* һ.б. *Язгы көннең җилләре кыйбла яктан* ***искәндер****; Сәхибәнең зифа буе хәсрәт өчен үскәндер* [Татар ..., 1983, б. 134]; *Шыбыр-шыбыр* ***явадыр****, ягмур микән, кар микән? Туксан түрә җыелды, тагы да түрә бар микән?* [Шунда ук, б. 114]; Табигать күренешләрен белдергән фигыльләрне һәр бәеттән диярлек табып була, чөнки кеше язмышларын, аның сагыш, кайгы, борчуларын җил дә сиздерә, аккан сулар да кайгыра, яңгыр да хисләрне арттыра кебек: *Биек тауның башында* ***шаулый агач*** *башлары; Ят җирләрдә тилмереп, түгелә солдат яшьләре* [шунда ук, б. 44]; ***Җил-давыл күтәрелгәч****, аерылдык ике якка; Каргышның сөременнән әйләндек Сакка-Сокка* [шунда ук, б. 210].

3. Хәл-торыш фигыльләре:

1) яшәеш фигыльләре: *туу, йоклау, черем иту, ял иту, үлү, һәлак булу* һ.б. *Шул вакытны бу кешеләрнең унберенче малайлары* ***туа*** [Татар ..., 2007, б. 60]; *Бер көнне биш йөз* ***үлде****, бер көнне меңләп* ***үлде****; Мескен ата баласының газиз җаны ни күрде!* [Татар ... , 1983, б. 80];

2) эмоциональ халәтне белдергән фигыльләр: *шатлану, сөенү, борчылу, кызыгу, юану, кайгыру, шомлану* һ.б. *Моны күреп, вәзирләр «Бәхетле кешене таптык» дип, бик* ***шатланганнар****, ди* [Татар ..., 2007, б. 86]; Ораторлар килделәр: «Долой сугыш!» — диделәр; ***Сөенешеп*** *солдатлар, өйгә кайтабыз, диделәр* [Татар ..., 1983, б. 76].

4. Мөнәсәбәт фигыльләре: *кадерләү, сөю, сагыну, гашыйк булу, соклану, ошау, хыянәт иту, якын күрү, үз иту. Кияүне күргәч, апасы, адәм заты да мондый матур булыр икән, дип* ***сокланды****, кияүгә ул да* ***гашыйк булды*** [Татар ..., 2007, б. 23]; *Бәндин калган киемемне ябынырсыз, әнкәем; Җәйге ямьле атналарда* ***сагынырсыз****, әнкәем* [Татар..., 1983, б. 196].

5. Тавыш фигыльләре: *пошкыру, тавышлану, әтәчләнү, мыраулау, җырлау, сайрау, гөрләү, иңрәү, мөгрәү. Сандугач* ***сайрый*** *саз саен, сазда үскән тал саен; Сәхибә матур җавап бирә түрәләргә көн саен* [Татар ..., 1983, б. 135]; *Күгәрченем, син* ***гөрлисең****, хәлләремне белмисең; Моңлы итеп син* ***гөрлисең****, мин елыймын, күрмисең* [шунда ук, б. 270].

6. Сөйләм эшчәнлеген белдергән фигыльләр: *сөйләү, сөйләп бирү, әйтү, белү. Төлкене каршыларына утыртып* ***сөйләп бирделәр****, ди, болар нинди-нинди хәлләр булганын* [Татар ..., 2007, б. 33]; *Урып учка салалар, җефәк илә бәйлиләр; «Энҗе кебек орлыгы», — дип, бары мактап* ***сөйлиләр*** [Татар ..., 1983, б. 166].

7. Сизү, тою, ишетү, күрү органнары белән бәйле булган фигыльләр: *күрү, карау, тыңлау, ишетү, сизү* һ.б. *— Башта коткарып кара, аннан күз* ***күрер****, — ди Алпамша* [Татар ..., 2007, б. 58]; *Балкан тавын мендек без, төрекләрне* ***күрдек*** *без; Алты кадак сохари белән унике көн йөрдек без* [Татар ..., 1983, б. 42].

Тере һәм тере булмаган табигатьне белдергән сүзләргә дә тукталып үтик:

1. Туганлык мөнәсәбәтләрен белдергән сүзләр: *ата, әтәй, әткәй, ана, әнәй, әнкәй, атасы-анасы, бала, балакай, балакаем, бәбекәем, әби, әбкәй, бабай, бабкай, угыл, улым, улыкаем, кызым, кияү, килен, килендәш, кайнага* һ.б. Мисаллар: *— Мин, **бабай**, алтын су эзләп барам* [Татар ..., 2007, б. 18]; ***Балакаем, бәбекәем**, өзелә лә үзәккәем; Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран, үтәлмәде теләккәем* [Татар ..., 1983, б. 278]; *Еллар үтсә дә бетмәде, **әткәй**, синең эзләрең; Мәңгелеккә калды безгә, **әткәй**, синең сүзләрең* [шунда ук, б. 247].

2. Кешеләрнең төрле һөнәр-шөгыльләрен белдергән лексика: *урман каравылчысы, аучы, гармунчы, сыер сатучы, сәүдәгәр, тегермәнче, сакчы, солдат, хан, патша, вәзир, генерал, шахтер, шофер* һ.б. Мәсәлән: *Бервакытны **урман каравылчысы** йокысыннан уянып китә, ни күзе белән күрсен, пристаньдагы пароход икенче свистокны бирә* [Татар ..., 2007, б. 152]; *Гаскәрне сугышка куалар, палатканы ваталар; **Солдат** сугышка бармагач, мылтык белән аталар* [Татар ..., 1983, б. 73].

3. Хайваннар, кошлар, үсемлекләр дөньясын белдергән сүзләр: *ат, тай, аю, бүре, дөя, арыслан, төлке, куян, әтәч, песи, эт, сандугач, күгәрчен* һ.б. *Бервакытны **Аю, Бүре, Төлке** үзара сөйләшеп бер фикергә килгәннәр, ди, «Без, диләр икән, хаҗга барып кайтыйк, моннан соң беркемгә дә тимик, үз көчебез белән көн итеп карыйк», дигәннәр* [Татар ..., 2007, б. 42]; ***Сандугач** тавышын, балам, тыңларсың; Әнкәм рухы дип, сагынып еларсың* [Татар ..., 1983, б. 199].

4. Урын һәм вакыт төшенчәсен белдергән сүзләр: *кыр, болын, урман, дала, басу, базар, туган ил, сахралар, язын, яз башы, көзен, көз көне, җәй, җәен, кыш, иртә-көндез, иртәниртүк, иртә-кич, төне-көне, көнетөне* һ.б. *Бу Юмарт бара торгач бер **урманга** барып кергән* [Татар ..., 2007, б. 24]; *Мескен солдат-запасныйлар, бар да кырык яшендә; **Көне-төне** атышканда утлар яна башында; **Төне-көне** туплар аттык Германия гурытына; Бер Ходаем салды безне бу дөньяның утына* [Татар ..., 1983, б. 80].

5. Кешеләрнең йорт-җирләрен белдергән сүзләр: *өй, ызба, квартир, бүлмә, абзар, сарай* һ.б.: *Шул **сарайдан** минем **сараема** хәтле су өстенә алтын күпер салдырган булсын, — ди* [Татар ..., 2007, б. 122]; *Әткәй калдыргач, **өйдә** калдык без; Әнкәй каргагач, Сак-Сок булдык без* [Татар ..., 1983, б. 206].

6. Кием-салым һәм тукымаларны, бизәнү әйберләрен белдергән лексика: *яулык, күлмәк, калфак, штан, чапан, алтын, алмаз, җәүһәр, бриллиант, энҗе; алка, йөзек, мәрҗән, муенса, беләзек* һ.б. *Кулымдагы көмеш **йөзек** көнгә каршы эридер; Тал чыбыктай зифа буем су төбендә черидер* [Татар..., 1983, б. 188]; *Кыз урамга чыга да француз **яулыгын**, кесәсеннән чыгарып, селкеп җибәрә, аксагы да калмаган, туксагы да калмаган, бөтен пәриләр килеп җиткән* [Татар ..., 2007, б. 251].

Әкиятләр, бәетләр тел ягыннан, аерым алганда фигыльләрнең кулланылышы ягыннан, шактый кызыклы һәм үзенчәлекле.

*-а, -ә, -ый, -и* кушымчалы хәзерге заман хикәя фигыльләр бик күп. *Әтәч, өй эченә кереп, Кәҗә мөгезләре арасына барып кунуы була, чукый башлый Кәҗәнең күзләрен* [Татар ..., 2007, б. 102]; *Карыйм авырулар, ясыйм дарулар; Мәхәлләм бик зур, кайный сарулар* [Татар ..., 1983,

б. 170]. Бәетләрдә хәзерге заманның *-ай/-әй* кушымчалы формалары да очрый: *егла-й ~ елый, сөйлә-й ~ сөйли, кара-й ~ карый*. Мәсәлән: *Сугышның хале шулдыр кем, тынычлык һич кемә ирмәз; Ки дилмереп* ***карай*** *мескен, кемнең күзе аны күрмәз* [шунда ук, б. 67].

Сирәк булса да әкиятләрдә, күбрәк бәетләрдә очраган хикәя фигыльләрдә III зат берлек санда *-дыр, -дер, -тыр, -тер* кушымчалары кулланыла. Тарихи яктан карaганда бу кушымчалар — борынгы аналитик форманың, кыскарып, синтетик формага әйләнгән варианты: *бара торыр — барадыр — бара, ыргыта торыр — ыргытадыр — ыргыта*. Мәсәлән: *Кулымдагы көмеш йөзек көнгә каршы* ***эридер****; Тал чыбыктай зифа буем су төбендә* ***черидер*** [Татар ..., 1983, б. 188]; *Алтынлаган яфрак алка елтыр-елтыр* ***калкадыр****; Артындагы чулпысы авыр, су төбенә* ***тартадыр*** [шунда ук, б. 188]; *Төкерим инде чәегезгә,* ***дигәндер****; Теле пешкәч, һушы китеп* ***торгандыр*** [шунда ук, б. 44]; *И, әби, утым сүнде, ут эзләп* ***чыккандыр****, ди* [Татар ..., 2007, б. 195]; *Германия өй башларын балчык белән* ***чапкандыр****; Сагынуга чыдап булмый, әнкәй, башыма* ***капкандыр*** [Татар ..., 1983, б. 100]. Әдәби тел нормаларының ныгуы барышында *-дыр, -дер* кушымчалары кулланыштан төшеп калалар [Ханбикова, б. 70].

2. Әкиятләр һәм бәетләрдә тәмамланмаган үткән заман хикәя фигыльләрнең беренче төре аеруча актив кулланыла. Тәмамланмаган үткән заман *-а, -ә, -ый, -и* кушымчалы хәл фигыль һәм *иде* ярдәмче фигыленнән ясала: *бара иде, килә идек, ашый идегез* һ.б. *Әткәбезнең йортында бик рәхәт* ***яши идек****; Әнкәйнең әзерләгән яхшы ашын* ***ашый идек*** [Татар ..., 1983, б. 209]; *Кыз сандугачны кулына ала да: «Харап иттем бит мин сине, әле генә нинди матур итеп* ***сайрый идең****, хәзер сайрамассың инде, мин үзем гаепле», — ди* [Татар ..., 2007, б. 205].

3. Тәмамланмаган үткән заман хикәя фигыльләрне белдерүдә, сирәк булса да, икенче форма — *-ар, -әр, -яр, -ыр, -ер, -р + иде* аналитик конструкциясе дә кулланыла. *Икәүләп* ***уйнар идек****, суларга* ***чумар идек****; Күп вакыт өйгә кайтмый, бакчада* ***кунар идек*** [Татар ..., 1983, б. 208]; *«Минем, — ди, — бервакытларны 100 сум акча алган дустым бар иде, аңа әйтәсең, ул* ***килер иде****...* [Татар ..., 2007, б. 47].

4. Әкиятләрдә, бәетләрдә *-ды, -де, -ты, -те* кушымчалы билгеле үткән заман хикәя фигыльләр күп. *Бүген* ***бардым****, кичә* ***кайттым*** [Татар ..., 2007, б. 232]; *Җомга көнне кич берлән без сугыша* ***башладык****; Германлылар чолгап алгач, мылтыкларны* ***ташладык*** [Татар ..., 1983, б. 96].

5. Әкиятләрдә, бәетләрдә шулай ук *-ган, -гән, -кан, -кән* кушымчалы билгесез үткән заман хикәя фигыльләр дә еш очрый. *Егет әлеге төлкене азат итеп* ***җибәргән****. Төлке чабып, качып* ***киткән*** [Татар ..., 2007, б. 36]; *Якшәмбе көн кич белән дүрт багана* ***утырткан****; Хәмидулла, йөзе кара, өч авылны* ***котырткан*** [Татар ..., 1983, б. 114].

Әкиятләрдә, бәетләрдә күптән үткән заманны белдерү өчен *-ган, -гән, -кан, -кән + иде* конструкциясе еш кулланыла. *Алар кайтканда, инде җен белән сугышып* ***арыган идек*** [Татар ..., 2007, б. 266]; *Дию авызын* ***ачкан иде****, ярты адәм гәүдәсе серәеп тора икән* [шунда ук, б. 122]; *Анадин туган идек, илдә дә* ***торган идек****; Кеше дә булырбыз, дип фараз да* ***корган идек*** [Татар ..., 1983, б. 208].

Бәетләрдә күптән үткән заманның *-мыш/-меш* кушымчасы белән ясал-

ган угыз формасы да урын алган. ***Чолгамыш ирде*** *әтрафын зур бакчалар; Килтерер инде илгә ничә мең акчалар* [Татар ..., 1983, б. 29].

6. Татар халык әкиятләрендә, бәетләрендә шулай ук билгесез киләчәк заманның *-ар, -әр, -яр, -ыр, -ер, -р* формалары да кулланыла. *Безнең мәчет эчендә шәмнәр фонарь булганда; Солдат хәлен сорамагыз, шинель **кияр** салкында* [Татар ..., 1983, б. 58]; *Әнкәй, ашың пешеп җиткәч, балаларың **җыелыр**; Алар булып, мин булмагач, кайнар яшең **коелыр*** [шунда ук, б. 222]; *Әхмәт әйтә: — Мин сезгә ул патша кызларын алу юлын **табармын**, — ди, — сез миңа ирек бирегез, — ди* [Татар ..., 2007, б. 63].

Татар халык әкиятләрендә, бәетләрендә билгеле киләчәк заман һәм киләчәк үткән заман хикәя фигыльләре очрамады. Күрәмсең, алар соңрак барлыкка килгәндер. Татар халык әкиятләрендә фигыльләрнең сөйләмдә тоткан урыны аеруча зур. Алар әкият геройларының фикерләрен гадиләштерүдә, кыска, җыйнак итеп бирүдә мөһим роль уйныйлар.

Калган фигыль формаларыннан әкиятләрдә, бәетләрдә шарт, теләк, боерык наклонениеләре урын алган. *Әгәр дә мин кушканны **эшләмәсәң**, мәйданга чыгып башыңны чаптырырмын, — ди* [Татар ..., 2007, б. 94]; *Күрмәс идем боларны мин, атам-анам тере **булса**; Укып кеше булыр идем, миңа бәхет кошы **кунса*** [Татар ..., 1983, б. 167]; *Туганнарым, дусларым, ничек **ташлыйм** сезләрне; Күрергә бу эшләрне Ходай кушты безләрне* [шунда ук, б. 53]; *Барып җитү белән, Алпамша солдатларга әйтә: — **Туктагыз**, бу мылтыкны алай **атмагыз**, мин моны үзем атып карыйм әле, — ди* [Татар ..., 2007, б. 53]; *Әткәй, әнкәй, **еламагыз**, үлде, диеп мин балагыз; Илем өчен җаным бирдем, герой, диеп сез **санагыз*** [Татар..., 1983, б. 248]; *Мөмкин кадәр сезә бу сугышны бәян идәм; Ки Волчи таудагы сугыш, **ишетеңез** аны, яран* [шунда ук, б. 67]. Соңгы мисалда II зат күплектәге боерык фигыльдә *(ишетеңез — ишетегез) г ~ ң* күчеше барлыкка килгән: ***тотыңыз, утермәңез*** [шунда ук, б. 48]; ***алыңыз, алыңыз да укыңыз*** [шунда ук, б. 53].

Әкиятләрдә, бигрәк тә бәетләрдә, сыйфат фигыльнең *-ган/-гән, дык/-дек, -мыш/-меш, -ыр/-ер, -асы/-әсе,-ачак/-әчәк, -а, -ә, -ый, -и* кушымчалы яки шуларга *торган* ярдәмче фигыле өстәлгән формалары да теркәлгән. *Кисәм өскә — бер бишмәтем, кырык төрле ямау салган; **Ашый торган** бәнем ашым уракчы, эшчедән калган* [Татар ..., 1983, б. 167]; *Агаларым **кушмаган** эшне эшләдем, утсыз калдым, ут бир, — диде кыз* [Татар ..., 2007, б. 38]; *Быел **чәчкән** бодайны җил коядыр булганын; И хәләлем, балаларым, һич тә күреп туймадым* [шунда ук, б. 150]; *Газиз **улмыш** күршеләрем, бәндин бәхил булыңыз; Исләрегезгә төшереп, хәер-дога кылыңыз!* [Шунда ук, б. 144]; *Ки бер һөҗүм **итдекендә** ничә меңләп япон үлде; Артур аръягында улан чокырлар җөмләсе тулды* [шунда ук, б. 222]; *Без **чыгасы** кичләрдә бигрәк яңа ай туган; Газиз балаңны сатасың, әткәй, сиңа ни булган?* [Шунда ук, б. 160]; *Без **чыгачак** кичләрдә бигрәк яңа ай туган; Бу китүем авыр булды, өмет өздем кайтудан* [шунда ук, б. 53].

Хәл фигыльнең *-ып/-еп, -гач/-гәч, -ганчы/-гәнче* формалары да күзәтелә. *Егетләр, үзләренең ризалыкларын **биреп**, патша кызларына өйләнәләр* [Татар ..., 2007, б. 90]. ***Ашап-эчкәч***, *егет сораша сакчыдан: — Хуҗаң кайчан кайта, кая таба китте? — ди* [шунда ук, б.

188]. *Булды мәрхүм шагыйрь Тукай, **чәчә-чәчә** нурларын; Китте Тукай бу дөньядан безгә биреп җырларын* [Татар..., 1983, б. 38]; *Гомәр эчемә **чәнечкәч**, чыкты кайнар каннарым; Кукмара больницасында чыкты минем җаннарым* [шунда ук, б. 122].

Бәетләрдә *-гач/-гәч, -кач/-кәч* кушымчалы хәл фигыльләргә *-тын, -тен* кушымчалары ялганган очраклар да бар. *Балкан тавын **менгәчтен** килә ислам казагы; Дунай суын **чыккачтын** барып кердек бер өйгә; Пуля килеп **тигәчтен**, түзеп булмый, сызлыйдыр; Приемга **кергәчтен** чәчләремне кырдылар* [Татар ..., 1983, б. 42].

Исем фигыльнең *-у/-ү, -мак/-мәк* формалары да теркәлгән. *Дөньядан **китү** сәбәбен сөйлим; Сак-Сок көенә мөнәҗәт көйлим* [Татар..., 1983 б. 196]. *Килеп диңгездән иң әүвәл, гаваньга илә миңа атты; **Ярылмак** илә ул миннар ике йөз судноны ватты* [шунда ук, б. 65].

Татар халык әкиятләрендә, бәетләрдә инфинитив *-ырга/-ергә, -арга/-әргә, -рга/-ргә* формаларында килә. *Көн дә эзли безне әнкәй **уйнарга** чыккан җирдән; Чыктык басуга урак **урырга**; Ходай язгандыр шулай **булырга*** [Татар ..., 1983, б. 204]; *Хәзер зур җыелыш җыеп, солдатны **«үтерергә»** дип хөкем чыгаралар* [Татар ..., 2007, б. 120]. Әкиятләрдә *-мак/-мәк* кушымчалы инфинитив та еш очрый. *Иптәше икмәкне, суны, скрипканы тапшыра да инде **кайтмак** була* [шунда ук, б. 48].

Бәетләрдә инфинитивның *-мага/-мәгә* кушымчалы формасы да еш очрый. Әлеге форма *-мак/-мәк* кушымчалы фигыльләргә *-га, -гә, -ка, -кә* юнәлеш кушымчалары ялганып ясалган. *Шулай итеп солдат берлә чыгып киттем төрмәгә; Ахры, безгә тәкъдир шулай, кайгы-хәсрәт **күрмәгә*** [Татар ..., 1983, б. 139]; *Балаларын пулун алганда Шамил мәсҗеддә иде; Команда кәлде һәм анда Шамилне **тотмага**, валлаһ!* [Шунда ук, б. 47]; *Мөхаль булгач ки **тотмага** безем гаскәр рөҗуг итте* [шунда ук, б. 167]. Хәзерге әдәби телдә *-мага/-мәгә* кушымчалы форма диалекталь күренеш буларак карала.

Шулай итеп, татар халык әкиятләрендә, бәетләрендә кулланылган фигыльләрдә, хәзерге татар теленә хас формалар белән бергә, диалекталь элементларның һәм архаиклашкан тел күренешләренең саклануын күрәбез. Алар фигыльләрнең кулланылышы ягыннан да, лексик-семантик төркемнәрнең күп булуы белән дә бик үзенчәлекле.

**Әдәбият**

*Арсланова С. М.* Җәлилнең «Алтынчәч» һәм «Илдар» либреттоларының лексик-семантик, стилистик үзенчәлекләре һәм поэтик ономастикасы (текст) / С.М.Арсланова: Филол. фән. канд...дис. Казан, 2004.

*Ганиев Ф. А.* Образование сложных слов в татарском языке. М.: Наука, 1982.

*Ганиев Ф.Ә.* Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы. Төзәт. 3 нче басма. Казан: Мәгариф, 2009. 271 б.

*Дмитриев Н.К.* Глаголы речи в языках тюркской группы. В кн.: «Строй тюркских языков» // Москва, 1962.

Татар халык иҗаты. Бәетләр. Казан: Татар кит. нәшр., 1983. 351 б.

Татар халык иҗаты. Әкиятләр. Казан: «Хәтер» нәшр., 2007. 287 б.

*Ханбикова Ш.* Татар телендә синонимнар. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1963.

*Хисамова Ф.* Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары студентлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2006. 324 б.

*Шайхулов А.Г.* О принципах тематической и семантической классификации апелятивной лексики // Исследования по семантике. Уфа, 1998.

*Шакурова М.М.* Лингвистический анализ художественного текста // Язык — культура — этнос: Сборник научных трудов, посвященный 10-летию со дня основания кафедры общей лингвистики и лингвокультурологии КФУ / под ред. доктора филол. наук, проф. Р.Р. Замалетдинова. Казань: Отечество, 2013. С.277 — 279.

*Мәкалә № 13-14-16010 РГНФ гранты кысаларында эшләнде*

***Шәкүрова Мөслимә Мәгъсум кызы***,
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты доценты*
*E-mail: mshakurova@inbox.ru*

УДК 821.512.145

***Д.Ф. Заһидуллина***

# РОБЕРТ ӘХМӘТҖАНОВ ИҖАТЫ: абстракт образлылык

В статье устанавливается теоретический потенциал категории «психологический абстракционизм» относительно татарской литературы 1960-х гг. На примере творчества Роберта Ахметзянова анализируются произведения, отвечающие требованиям авангардной эстетики; исследуются разные формы синтеза принципов романтической и модернистской поэтики, прекрасного и трагического. Определяются приемы, при помощи которых создаются абстрактные образы: параллелизмы и повторы, гиперболизация. Доказывается, что именно абстрактные образы способствуют воссозданию условной модели мира, которая отдалена от действительности. В его произведениях представлены неестественно прекрасные моменты бытия, лирический герой живет в подобном вымышленном мире. Психологизм, мифологизм и философичность придают особое звучание стихотворениям.

**Ключевые слова:** татарская поэзия, модернизм, психологический абстракционизм, абстрактные образы, параллелизм, повторы, гиперболизация

1960—1980 еллар татар яңа, экспериментал әдәбияты фонында Роберт Әхмәтҗанов иҗаты аерым урын били: бер яктан, бу шигъриятнең классик әдәбият чикләреннән узганлыгы күзгә ташланып тора; икенче яктан, авангард эзләнүләр белән чагыштырганда, әсәрләр бик таныш, кайчандыр яңгыраган нәфис, эстетик яктан камиллеккә омтылган моңның кабат мәйданга чыгуы кебек тәэсир уяталар. Чөнки шагыйрь татар әдәбияты өчен ят булмаган модернизм алымнарына күпләп мөрәҗәгать итә, шул ук вакытта әдәби әсәрләрдә чынбарлыктан бөтенләй үзгә, ераклашкан шартлы дөнья тудыру омтылышы ясый. Модернизмдагыча, тормыш-чынбарлыкны факт буларак түгел, ә проблема төсендә тәкъдим итә. Аның төсләр, табигать бизәкләре, ел фасыллары, тавышлар, шуларның күчеш-үзгәреше бергә килеп, тоташып ясала торган катлаулы, еш кына абстракт образлары гаҗәпләндерә, шул образлар тудыруга сәләтле кеше күңеленең байлыгы турында сөйли. Бу сыйфатка шагыйрь әле иҗатка кереп кенә килгән бер вакытта ук Сибгат Хәким игътибар итә: «Шигырьне ул вакламый, образлары аның ачык һәм күзгә ерактан бәрелеп тора, фикерне ул бер тирәгә туплый белә» [Хәким, 1973].

Бу максаттан Роберт Әхмәтҗанов күптөрле алымнарны файдалана, беренче әсәрләрендә үзгә дөнья тудыруның төп алымы булып янәшәлек урнаша. Менә шагыйрьнең «Гомер китабы» (1964) шигыре. Китап һәм гомер янәшәлеге әкиятләрдәгечә романтик гомер сурәтен, моделен төзергә мөмкинлек бирә:

...Тик әлегә ачкан битләрендә
Ал таң иде офык читләрендә.
Ара-тирә, сөт парлары булып,
Офыклардан карап куйды болыт.
Җылы җилләр исте талгын гына...

Тибрәлдерде җылы агым гына.
[Әхмәтҗанов, 1980, б.3].

Шундый ук кеше — туган җир («Җир әҗәте», 1963; «Иртән әле син йоклаган чакта», 1965) янәшәлеге кеше тормышының кыйммәте һәм кадере хакында сөйли. Аерым бер очракларда шагыйрь парлы образлардан янәшәлек кора: әйтик, энҗе бөртегенә омтылган әтәч (энҗе-әтәч) һәм яшәүгә гашыйк кеше (яшәү-кеше) («Тормыш! Сиңа иртә ымсындым мин....») шундыйлардан. Янәшәлекләр белән бергә кабатлаулар, беренчесе кебек үк еш кулланылмасалар да — бу иҗатта образлылык төзүнең төп ысулына әйләнә. Шигырьнең үз эчендә кабатлаулар, табигатьтәге кабатлануларны бер әсәр эчендә уйнату, образларның шигырьдән шигырьгә кабатлануы бу иҗатта табигый. Фәлсәфи яктан, шагыйрь иҗатында кабатлануның яшәешне саклаучы булуы хакындагы фикер яки турыдан-туры («Кабатлануларга мәдхия»), яки киная белән әйтелеп килә. Янәшәлекләр һәм кабатлаулар шагыйрьгә бер образ эчендә янәшә торырга мөмкин булмаган якларны, шул исәптән тышкы дөнья сурәтен һәм психик, психологик халәтне тоташтырырга, кушарга мөмкинлек бирә: абстракт образ хасил була. С.М.Шалютин фикеренчә, абстракт образ — сурәтләүнең тормышны чагылдыру процессында барлыкка килә торган иң югары төре. Шуңа күрә аның сыйфатлары, турыдан-туры яки кинаяләп, теләсә нинди чагылышны, шул исәптән психик рәсемне дә үз эченә ала [Эл. ресурс].

Беренче шигырьләреннән үк Роберт Әхмәтҗанов тормышны гаять якты, матур итеп күрә белүче лирик герой иҗат итә, сүзләр кулланылышы һәм яңгыраш ягыннан гармониягә, матурлыкка, камиллеккә омтыла. Бу герой карашында көн — күгәрчен очып туймаслык («Күгәрчен очып туймас көн», 1961), өйләр йөзләрен кояшка борган («Язга таба», 1957), җилләр яфрак алкышларын уята («Өй түрендә яфрак алкышлары», 1962). Бу образлар француз модернистларының элитар шигырьләрен хәтерләтәләр. Шагыйрь үзе дә, яшьлеген искә төшереп, болай дип яза: «Миңа дөнья поэзиясе вәкилләреннән Поль Верлен, Артюр Рембо, Федерико Гарсия Лорка, Уолт Уитмен, Юлиан Тувим, Пабло Нерудалар поэзиясе якын (...) Бу шагыйрьләрдәге хис, форма һәм фикернең гүзәл гармониясе әсир итә мине!» [Әхмәтҗанов, 2006, б.38]. Модернизмны дөнья әдәбияты мәйданына чыгарган һәм милли әдәбиятларын үзгәрткән-яңарткан шагыйрьләр болар.

Модернизмдагыча тормышның күңел хәрәкәтен, тәэсир көзгесендә чагылышын күрсәтү исә җансыз образларны җанландыру максатыннан кулланылган янәшәлекләр ярдәмендә башкарыла. Аерым бер очракларда бу янәшәлекләр соң чиккә җиткереп зурайтыла, абстракт образ дәрәҗәсенә куела. Әйтик, Роберт Әхмәтҗанов иҗатында иң еш кулланыла торган образларның берсе «Көн» — һәр мизгелнең гүзәллеген җырлауга хезмәт итә. Шагыйрь иң матур романтик шигырьләренең берсе — «Күгәрчен очып туймас көн»дә (1961) болай дип белдерә:

Күгәрчен очып туймас көн,
Һич сулап туймас һава!
Мәйданнар буйлап килә Көн —
Беркем чик куймас аңа.
(...) Мәйданнар буйлап килә Көн,
Максатын яхшы беләм:

Күгәрчен очып туймас көн
Расланды Кояш белән!
[Әхмәтҗанов, 1990, б.9].

«Өй түрендә яфрак алкышлары» (1962), «Кояшка, кояшка!» (1960) кебек күпсанлы романтик шигырьләрдә Көн — яшәеш, Көн — заман, Көн — тормыштагы матурлык рәвешен ала.

«Югалган бер көн» (1963) авангард шигырендә шагыйрь әрәмгә үткән көнне — кешене таптап киткән көн буларак бәяли. Әрәмгә үткән көн — капкага кермәгән туп, «сөткә» киткән пуля янәшәлекләре шушы тәэсирне тагын да арттыра:

Бүген мине таптап узды көнем,
Тик үземнән эзлим сәбәпләр.
Көн югалды! Планеталар юлын
Билгеләгән чакта — сәгатьләр!..

Төбәгәндә заман капкасына,
Ул туп булып читкә сикерде:
Кагылмыйча үтте йөрәгемә,
«сөткә» киткән пуля шикелле!
[Әхмәтҗанов, 1980, б.35].

Асылда, бу шигырь дә һәр көннең, һәр мизгелнең кеше өчен генә түгел, бәлки галәм күләмендә, яшәеш өчен гаять кадерле, кыйммәтле булуын раслый, ләкин моның өчен, күнегелгән янәшәлекләрдән, чиктән тыш арттырудан тыш, кешене таптап киткән көн абстракт образы кулланыла, әлеге образ хаотик дөнья сурәтенең бер элементына әверелә. Әйтик, романтик табигатьле «Таң шигырьләре»ндәге (1961) «Шагыйрьләрдән көчле итеп,/ үзенең сүзен әйтә Көн» [Әхмәтҗанов, 1980, б.33] кебек арттыруга корылган образдан аермалы буларак, абстракт образларда чынбарлыктан аерылган яңа бер дөнья моделе хасил ителә.

Мәхәббәт турындагы «Көндәлектән (Өзелеп калган көн)» (1963) шигырендәге исемгә чыгарылган, өзелеп калган көн абстракт образы тулаем абстракт сурәтнең бер кисәген генә хасил итә. Шигырьнең беренче өлешендә сөйгәненнән аерылган лирик геройның мәхәббәт шаһите — фонтан янында утыруы билгеләнә, юксыну, сагыну хисе өченче строфада әйтеп үтелә:

Фонтандагы
Таш балыклар күзеннән
Саркып-саркып
Су тама...
(Сине юксыналар бугай алар!)
[Әхмәтҗанов, 1988, б.7].

Ә инде шигырьнең икенче яртысы төсләр, күрмә образлар һәм янәшәлек ярдәмендә абстракт дөнья — өзелеп калган көн сурәте ясый:

Таш юлларда яфрак бөтерелә —
әйтерсең лә кызыл кошлар
талпыналар язлар каршына.
Урам себерүче карт
Ялкын-яфракларны

Туфрак белән күмә:
«Ярсыма!»
Күмә, күмә
Тере кошларны...
Безнең җәйне!
[Әхмәтҗанов, 1988, б.7].

Бу сурәттә кызыл кошлар — мәхәббәт; мәхәббәт турындагы истәлек янәшәлеге дә, яшел-кызыл-кара төсләр көчеше дә, урам себерүче карт, көзге яфраклар-кызыл кошлар детальләре дә әһәмиятле һәм аларның бергә килеп урнашуы катлаулы бизәк хасил итә.

Шагыйрьнең мондый әсәрләре шунда ук тәнкыйть күзенә эләгә.

Бу хакта Роберт Әхмәтҗанов үзе дә язып үтә: «Уйна, улым!», «Таш аргамак» поэмаларында, Ленинга багышланган «Сәгать суга» шигырендә мине татар традицион шигырен ватуда, «абстракционизмда» гаепләп, «шигъри стиляга» дигән атамалар да биргәннәре булды» [Әхмәтҗанов, 2006, б.64]. Ләкин бу гаҗәеп шигырь дөньясы, шагыйрьнең бай рухи җанын чагылдырган дөнья берәүне дә битараф калдырмый. Шуңа күрә дә, башка авангард шагыйрьләр белән чагыштырганда, традицион шигырьдән иң нык читләшкән булсалар да, бу шигырьләргә карата усал, җимергеч, тискәре фикер белдерелми. Чөнки шагыйрь асылда милли, традицион кыйммәтләр хакында сөйли, ләкин шуларны раслау максатыннан татар шигърияте өчен чит-ят образларга мөрәҗәгать итә. Аннары шунысын да истә тотарга кирәк: Роберт Әхмәтҗанов иҗатында авангард эзләнүләр 1960—1970 еллар аралыгында гына актив була. Соңрак ул традицион шигырьгә әйләнеп кайта, хәтта абстракционизм агымында язылган шигырьләрен җыентыкларына да бик аз күләмдә урнаштыра башлый.

Менә шагыйрьнең абстракт сәнгать үрнәге булган «Ак поэма»сы. Жанры «озын шигырь» дип билгеләнә алган бу әсәр аналарга мәдхия кебек язылган һәм яшәешне бар итүче, саклаучы — ана дигән фикерне ныгыта. Абстракт образлылык янәшәлеккә корылган: ананың йомгак сүтеп бәйләве — тормыш агышы. Шигырьдә башта янәшәлекнең беренче канаты тергезелә:

Тәрәзә каршында
әни бәйли
сүтә-сүтә
кояш йомгагын!
Аннан керешә
Айның көмеш йомгагына,
Җепләрнең ул сайлый иң агын...

Инәләре — нурлар!
Ак өлгедән күзләп урамны,
Бәйли —
Бураннарда — кушып буранны!
[Әхмәтҗанов, 1980, б. 50].

Бу гаҗәеп сурәт — әнинең бәйләм бәйләве ел фасыллары белән тәңгәлләштерелә: җәй, көз, кыш. Бу йомгакта ананың сабырлыгы, өметләре уралганлык күрсәтелә. Һәм шигырьнең соңгы юлларында шагыйрь көтелмәгән борылыш ясый — янәшәлекнең икенче канатын иҗат итә:

Шулай
Бәйли әни
Айлар, еллар...
Сүтә-сүтә
Гомере йомгагын!...
[Әхмәтҗанов, 1980, б. 51].

Ягъни тормышның агышын үз гомере хисабына «бәйләүче» ана сурәте пәйда була. Ул юнан мифологиясендәге Бөек тукучылар образларын хәтерләтә. Шул ук вакытта шәл бәйләүче, бөтен тирәсендәгеләрне җылытып яшәүче татар карчыгы — милли әдәбияттагы ана архетибы төсен ала. Ул образ шагыйрьнең күп кенә шигырьләрендә кабатлана: «Әни язы» (1972), «Кырларымда, әни, иминлекме...» (1971) һ.б.

Ана белән бәйле үзенчәлекле абстракт образ тудырган шигырь — «Сез дә картаясыз, таллар» (1977) — шулай ук янәшәлеккә корыла: кояш баюы — ана картаюы. Лирик герой күңелендәге моң-сагышның сәбәбе шул:

Күз алдында әнкәм утырып байый
(төшә кояш)

(...) Хатын-кызның баешыннан да
моңсу
Бер җыр юктыр дөньяда
[Әхмәтҗанов, 1990, б. 95].

Ана образы кебек үк милли төсмерле тагын бер үзәк образ — Идел-йорт: «Идел-йортка килә яңгыр...» (1971), «Идел-йортның тәрәзәләре — күк...» (1966), «Җил белән килә ерактан..» һ.б. — бу иҗатны үтәли озата бара. Идел-йорт дигәндә, шагыйрь аның туган җир булуын ассызыклый һәм «туган җир» дигән образ түгәрәге эченә табигать матурлыгын, иген кырларының байлыгын, мәхәббәт һәм ана изгелеген урнаштыра. Шигырьләрдә кабатлана килгән әлеге дүрт кыйммәт «Болгар фрагментлары» (Археологик эскизлар) (1969) авангард поэмасында бер урынга туплап, төп идеяне хасил итә. Шунысы кызык, әлеге поэма күптөрле фикер-идеяләрне укырга ачкыч калдырып язылган, аның 8 бүлегендә тарихи, фәлсәфи, шәхси мотивлар формалаштырыла башлый һәм ул өзелеп кала.

Поэма лирик геройның — археологларга ияреп Бөек Болгар хәрабәләрен казырга килгән кешенең — риторик эндәше белән белән башланып китә:

Синең йөзне күрдем
Идел көзгесендә.
Син
Кайчандыр
Шушы биеклектән караган.
Көмеш әремнәрне ера-ера,
Нигезеңә барам,
Аякларга сугылып чыкрый ташлар,
Балакларга сарыла сырлан,
Ябыша тарих
[Әхмәтҗанов, 2005, б. 218].

Эпиграф белән интертекстуаль бәйләнешкә кереп («Туфрак катлам-катлам биредә — / Тарихның маңгай сырлары./ Бу ташлар, бу өлгеләр бары / гомер фрагментлары...»), башта «Идел көзгесендә» күренгән йөз — борынгы кеше, лирик геройның нәсел чишмәсеннән бер зат булып аңлашыла. Шагыйрь дүртенче бүлектә бу эчтәлекне көчәйтә, ләкин Ак Пулат образы белән бергә Болгар ханы мәгънәсе пәйда була:

Туганым,
ыруым,
кандашым,
тыңлачы!
Көннең нәкъ кыл уртасында,
Нәкъ түбәдә торганда кояш,
Безнең көрәкләр,
Синең капкаңны үтеп,
Килеп төртелде
Ак Пулатың бусагасына.
Рөхсәтме?
Рөхсәтме
Кагылырга акрын гына
Ташларыңа,
Кузгатырга урыныннан
Мәңгелекне?
[Әхмәтҗанов, 2005, б. 221].

Алга таба шушы нигез лирик геройга борынгы заманның төп кыйммәтләрен аерып чыгарырга мөмкинлек бирә. Әкренләп образның борынгы заман, узган чор дигән мәгънәсе күренә. Мөстәкыйль образлардан аның сурәте җыйнала. Бер пар шәмәхә гөл — мәхәббәт яки туган җирне саклап тамган изге кан символы; кырлар тутырып үскән алтын бодай; анага хөрмәт — менә шушы дүрт кыйммәт, автор фикеренчә, борынгы заманның сурәте дә, бүгенге көнгә килеп җиткән истәлеге дә.

Шигырьләрендә дә шагыйрь мифологик образларга, мотивларга иркен мөрәҗәгать итә, шулар

ярдәмендә бүгенге белән янәшә тарихи вакытны тергезә. Әйтик, «Лирик әкият» (1967) шигырендә халык әкиятеннән китерелгән сурәт: «Тарак ташлады — карурман үсте, Көзге ташлады — күл булды» — мәхәббәт, сөйгәне белән кавыша алмаучы, аны эзләүче лирик геройның үкенеч хисләрен көчәйтүгә хезмәт итә:

Җитеп булмый сиңа. Толымыңнан
Ыргытуга алып тарагың,
Эзләреңдә шаулап урман калка,
Карурманнар каплый араны!..
Кызыл тарак төсле, юл өстендә
Янып торса көзге урманнар.
Көзгә керсәм — инде
көзне уздың:
Арада — кыш.
Аера бураннар!
[Әхмәтҗанов, 1990, б.100].

Абстракт образларга мөрәҗәгать итүне галимнәр шәхеснең гадәти чынбарлыктан качу омтылышы белән бәйләп карыйлар [Теория ..., 2001. Б. 281]. Бу качу — кешенең эчке дөньясына китү, чынбарлыктан читләшү кебек кузаллана. Мондый омтылыш Роберт Әхмәтҗанов шигъриятендә гаять үзенчәлекле төс ала. Әйтик, «Җавап» (1971) шигырендә шагыйрь «ил белән» яшәвен идея итеп күтәрә. Ләкин «ил»не төгәлләштергән сурәтләр төрлечә укылырга мөмкин:

Күрәсезме, дуслар, кыр өстендә
Асылынып тора ак болыт? — дим, —
Ак болытның кыл бер уртасында
Минем йортым күренә ак булып,
Тургай оя корган җирдә,
Сандугачлар торган җирдә,
Идел-елга аккан җирдә,
Моңын ярга каккан җирдә,—
Минем оям!
Шунда — сыям...
[Әхмәтҗанов, 1990, б.15].

Беренче укылыш ил-Иделне гаять идеаллаштырып сурәтләү булса, икенче укылыш — уйлап табылган, идеаллаштырылган дөньяга ишарә ясый. Лирик герой — үз дөньясында, җир белән күк уртасындагы ак болытта яшәүче кебек тәэсир туа.

Тагын бер мисал — шагыйрьнең «Июнь иле» (1971) озын шигыре. Шунысын да искәртергә кирәк: Роберт Әхмәтҗанов шигырьләрендә кеше гомере — ел фасыллары янәшәлеге лейтмотив төсен ала: гомернең җәен сагыну, көз сагышы бик күп әсәрләрнең үзәген хасил итә. Бу шигырьдә дә идеаль матурлык дөньясы тәкъдим ителә, ул — июнь иле:

Шау чәчәктә юкә,
Алкалары — сары.
«Очам!» диеп тора
Тузганаклар шары.

Ул су өсте! Тып-тын,
Шома көзге генә.
Шуып-шуып үтә
Су чебене генә.

Су дөньясы тонык —
Күренә чабаклары,
Арлы-бирле үтә
Кызылканатлары...
[Әхмәтҗанов, 1990, б.57].

Әлеге гүзәл дөньяны лирик герой «гашыйк балачагым» калган җир дип билгели:

Мин үзем дә шуннан,
Июнь иле ямьле...
Гашыйк балачагым
Шунда калды мәңге
[Әхмәтҗанов, 1990, б. 57], — әлеге юлларда лирик геройның һаман да шул балачак илендә, уйлап табылган гүзәллек дөньясында яшәве ассызыклана. Бу фикер Сент-Экзюперидан эпиграф итеп алынган

юллар белән кисешә: «Мин кайданмы? — / Үземнең бала чагымнан».

Ләкин көчле позициядә — соңгы юллар итеп — урнаштырылган строфа фикерне үзгәртә, сагыш төсмере китереп кертә:

Июнь җиле исә
Үләннәрне тарап...
Ята балачагым
Кошлар юлын карап,

Гаҗәпләнгән күккә,
Алмый гүя тын да...
Чакырма да — кайтмас,
Ул бәхетле — шунда!
[Әхмәтҗанов, 1990, б. 59].

Шул рәвешле, шигырь лирик геройның чынбарлыктан качу урынын ачыкларга ярдәм итә: тормышка балачак күзләре белән караучы кеше шул күзләр күргән яңа дөнья төзи, шуны үз әсәрләрендә бөтен ваклыкларында тергезә икән ләбаса.

Ләкин бу гүзәллек дөньясының абстракционизм белән нинди уртаклыгы бар соң? Галимнәр фикеренчә, абстракционизмда ике агым формалаша: «Беренче агым — лирик-эмоциональ, психологик абстрационизм — төсләр симфониясе, тәртипсез буяуларның гармониясе. Бу агым тормышның чуарлыгы хакындагы Анри Матисс күрсәткән импрессионистик тәэсирдән туа» [Теория ..., 2001, б.281-282]. Бу агымның рәсем сәнгатендәге патриархы Кандинский кебек үк, Роберт Әхмәтҗанов та милли әдәбиятта чынбарлык урынына — табигый булмаган матур мизгелләрне яктыртучы шигырьләр иҗат итә. Аның лирик герое, чынбарлыкны кире кагып, үзе «сурәтләгән» дөньяда яши һәм шуның матурлыгына дан җырлый. Кояшлар, җилләр, үләннәр дөньясы, шуларга соклану һәм хозурлану башка барлык мөнәсәбәт-кичерешләрдән өстен чыга. Роберт Әхмәтҗанов шигъриятендә лирик герой — табигать-тормыш белән бергә-бер калып сөйләшүче; ахыр чиктә, һәр кеше яшәештә бергә-бер калып гомер кичерүче.

Дөрес, бу «мин-дөнья» түгәрәгенә мәхәббәт килеп кергәндә, анда әни яки сөйгән яр образлары пәйда була. Ләкин алар лирик герой яшәгән дөньяга «килеп тоташучы» башка дөньялар кебек күзаллана («Лирик әкият», 1967; «Сез дә картаясыз, таллар...», 1977; «Каеннарны үт тә сугыл миңа», 1966; һ.б.). Әйтик, «Син — бер океан» шигырендә шагыйрь бу модельне үзе үк билгели:

Син — бер океан, бөтен
күңел тармакларым
Сиңа коя!
Синең дөнья...
Анда тик мин генә тойган,
Минем йөрәк кенә сизгән
Тектоник тетрәүләр, яшеренеп
ята бусагалар, рифлар —
Челпәрәмә килер күңел көймәң...
Тик бар аның сәгадәтле бер чагы! —
Нинди ул фасылы булсын: көздәме
Йә зәмһәрир кыштамы —
Ике зәңгәр яз карый сиңа балкып:
шартлый бөре,
Ачыла шигырь яфрагы!
Китә бозлар ерак зәңгәрлеккә!
[Әхмәтҗанов, 1980, б.72].

Шигырь лирик геройның мәхәббәт аңлатуы, сөйгәненең шагыйрь өчен илһам чыганагы булуын раславы төсендә язылган. Ләкин лирик герой һәм ул гашыйк кыз — мәхәббәт шигырьләрендә кабул ителгәнчә — бер дөньяның ике кисәге түгел. Биредә сүз бер «дөньяга» булган хисләрнең икенчесен үзгәртүе ту-

рында бара. Чагыштырулар һәм янәшәлекләр ярдәмендә шагыйрь шушы кичерешләрне күзәтеп уза: «ике зәңгәр яз карый (...) — ачылыр шигырь яфрагы», «шул караштан хәтта туң мамонт аягына басар» һәм гомумиләштерү ясый:

Гел пакьлеккә җәеп кочакны,
Дөнья гизеп йөрим куанып!..
[Әхмәтҗанов, 1980, б.72].

Лирик-эмоциональ, психологик абстракционизм импрессионизм алымнарына иркен мөрәҗәгать итә. Бу рәсем сәнгатендә генә түгел, әдәбиятта да шулай. Роберт Әхмәтҗановның шушы агымдагы әсәрләренең ирекле формада иҗат ителү сәбәбе дә шунда. Ирекле шигырь формасының өзек-өзек сурәтләр белән уйнау мөмкинлеге әйләнә-тирә дөньяны үзгәрештә, шуннан алган кәеф-халәт бирелеше кебек сурәтләргә җай тудыра.

Шагыйрь иҗатында шушы агымда язылган, беренче карашка пейзаж лирикасы булып тоелучы шигырьләр дә шактый зур урын алып тора. Мондый шигырьләрдә автор табигать күренешен кешеләштерүче гадәти булмаган образ урнаштыра, шуның ярдәмендә мәгънә чикләрен киңәйтә. Мисалга «Инде кич. Тирәкләр җил көтә» шигырен алыйк:

Инде кич. Тирәкләр җил көтә,
коймага сөялеп.
Җыена болытлар дөньядан —
көймәгә төялеп
[Әхмәтҗанов, 1980, б.73], —

дигән беренче юлларда ук сынландыру алымы пәйда була: тирәкләрнең коймага сөялүе, болытларның көймәгә төялүе игътибарны җәлеп итә. Алдагы строфа бу тойгыны тагын да көчәйтә һәм кич тудырган үкенеч хисен лирик геройның үзенә күчерә:

Эшлисе эшләнгән, инде тын күкләр гарнизоны:
Бетте ут! Инде буш куыкны атып карыйсыңмы? [Әхмәтҗанов, 1980, б.73].

Шул рәвешле, шигырьне кеше фәлсәфәсе, кеше үкенечләре хакындагы әсәр кебек укуга юл күрсәтелә, ләкин ачкыч бирелми.

Шагыйрьнең мондый (шактый күпсанлы) шигырьләрендә табигать халәте — лирик геройга ишарә ясый: табигать лирик герой исеменнән сөйләгән кебек тәэсир туа. «Ярларда — җил-су эзе...» шигырендә ут һәм җил мөнәсәбәтләре тергезелә:

Яна учак: «Җил генәм,
Кит теләгән җиреңә, —
Пышылдама-пышылда,
Минем көлем — шушында...»
[Әхмәтҗанов, 1980, б.77].

Шушы строфа ут образын туган җирдән аерылырга теләмәгән кеше кебек укуга юл күрсәтә. Бер үк вакытта соңгы юллар:

Яна учак, ага су —
Ялгыз җилгә ямансу..., —

лирик геройның — сөйгәнен үзе белән алып китә алмаган кешенең — сагышы төсен ала. Шагыйрь кечкенә генә шигырьдә тулы бер тормыш тарихын, аның драматик мизгелләрен тергезә.

Табигать белән бәйле янәшәлекләр ярдәмендә шагыйрь тәҗрибәләр ясый: аның иҗатында япон фәлсәфи шигърияте мотивлары ише-

телеп китә. Ләкин шунысы кызык: табигать — кеше күңеле янәшәлеген шагыйрь зур гомумиләштерү, яшәеш закончалыгы белән йомгаклап куя беләә. Менә «Элегия» (1974) шигыре. Оядан кош очу — туган нигез таралу янәшәлеген шагыйрь кешенең фани дөньядан китүе белән йомгаклый:

Мәңгелек тә өмет итмим,
туган туфрак,
Шуны гына сорыйм бары
бу җырда:
Соңгы йортым, моңлы
йортым түбәсенә
Җылы яңгыр булып кына
шыбырда!
[Әхмәтҗанов, 1990, б.146].

Шул ук вакытта табигатьтәге күчеш-үзгәрешләр кеше күңеленең байлыгын, матурлыгын күрсәтүгә хезмәт итә. «Синең озын җәең күгендә...» (1975) шигырендә бу кешенең — сурәтләнүче геройның — кем икәнен төгәл генә билгеләү дә кыен. Бәлки, ул сөйгән яр яки кадерле баладыр, сеңелдер, бәлки, гомумән кеше хакында сүз барадыр. Кем генә булса да, ул туган җир табигатенең кеше күңелендәге истәлекләрдә яшәүче иң матур мизгелләре белән янәшә куелган:

Синең озын җәең күгендә
очар әле өмет карлыгачлары,
Зәңгәр күккә учарланып менә
Уйчан хыял агачлары!..

Көнеңә яфраклар шавы,
сабыйлар авазы,
Күбәләкләр лепелдәве тулган!
Көнең — мөлдерәмә!

Бала кошлар утыра җирдә,
Мамык кына — канатларда...
[Әхмәтҗанов, 1990, б.104].

Шигырьдә көчле позициядә, башта һәм йомгаклап кабатланучы кыска күләгәләр абстракт образы («Синең озын җәеңдә кыска әле күләгәләр») ачкыч ролен үти һәм лирик герой халәтенә бәя бирә: табигатьнең матур мизгелләрен искә төшереп, шулар аша героеның күңел байлыгына сокланучы лирик герой — гомер үтеп баруга үкенү мизгелендә, аның озын җәендә «күләгәләр озайган», кояш батуга юнәлгән. Ләкин бу халәт якты сагыш төсен ала. Башка берәүнең күңел матурлыгын күрә алган, аңа тышкы сурәтләр, кыяфәтләр, тавышлар гармониясе ярдәмендә бәя биргән лирик геройның үз зәвыгы, эчке дөньясы байлыгын раслый. Шулай кайбер шигырьләрдә бер гаҗәеп «дөнья» гына түгел, бәлки бер-берсенә керешеп киткән кешеләр «дөньялары» тергезелә. Ләкин шагыйрь алар арасындагы чикне һәрчак бик төгәл билгели. Әйтик, «Улым, көзнең бу китабын...» (1974) дигән кечкенә шигырьдә улына:

Улым,
Минем ерак җәемдә
Күбәләкләр очып йөри,
Сикерә агач атлар!..
[Әхмәтҗанов, 1980, б. 85] —

дип эндәшүче лирик геройны һәм аның улын җәй һәм көз арасындагы чик аера.

Мондый әсәрләрдә табигать яки аның белән янәшәлектә ясалган абстракт образ кешенең халәтен, кәефен, мөнәсәбәтен ача, шушы кәеф гомумән кеше гомеренә, яшәешкә күчерелә, теләсә кем тормышында тап була торган закончалык төсен ала. Шагыйрь искиткеч зәвык

белән тасвирлый торган якты, матур бүгенге артында һәрчак кеше тормышында урап узу мөмкин булмаган фаҗига тоемлана. Ахыр чиктә, шигырьләр Роб. Әхмәтҗановны кеше тормышын матурлык һәм фаҗига бердәмлеге кебек караучы шагыйрь итеп раслый.

Шагыйрьнең ирекле шигырь формасын куллануы тышкы дөнья сурәтен аерым фрагментларга бүленә торган «рәсем» итеп оештырырга ярдәм итә. Ләкин нәкъ менә төрлечә укыла торган абстракт образ барлык кисәкләрне тоташтыра һәм чиктән тыш гомумиләштерә, үз тирәсенә автор әйтергә теләгән фикерләрне туплый һәм, хәтта, укучыга уйлап бетерү өчен юнәлеш тә күрсәтә.

Бу фикерне дәлилләү өчен берничә шигырьне анализлап үтү урынлы булыр. «Май тууга җирдә...» (1980) шигыре сабый-мин янәшәлеге тудыра: яз көне сары тузганаклар белән уйнап утырган бала янында лирик герой үзенең балачагын һәм тормышын искә төшерә. «Яшеллек арасында очкан сары күбәләк» образы тормышка аяк баскан һәр кешенең өметләрен белдерә, бу өметләрнең шатлыкка гына түгел, сагышка да әйләнүен яшәеш закончалыгы кебек тәкъдим итә:

Иң беренче булып
Сары күбәләк күрдем мин ул язда.
Сагышларым күп булыр, дип
юрамадым,
Юрамадым
Көнем аязга!
Яшел чәчәк атты таллар,
Кояш менеп китте биек...
Җилфердәп очты сары күбәләк,
Җилфердәп очты,
Кояшка тиеп-тиеп
[Әхмәтҗанов, 1980, б.129].

Күбәләкнең кояшка очуы кеше омтылышларының траекториясен һәм тормышның хәрәкәттә булуын күрсәтә, ләкин әлеге югарыга омтылышларның — сагышлар белән тәмамлануын, яз артыннан — көз килүен искә төшерә. Биеккә омтылышның — шатлык, моның тормышка ашмаслыгын аңлауның (кояшка куну) — шул шатлыкны сагышка әйләндерүе табигый яшәеш хәрәкәтенең асылы дигән фәлсәфә белдерелә.

«Җәяүле күбәләк» (1974) шигырендә сары күбәләк образы бөтенләй башка яктан күренеп китә. «Җәяүле», ягъни оча алмый торган күбәләк — картайган, өметләре өзелгән кеше — матурлыкның, мәңгелек кыйммәтләрнең сакчысы дигән фикер укыла:

Җәйге болыннарның җаны —
Җәяүле күбәләк
[Әхмәтҗанов, 1980, б.130].

Бу фикерне дәвам итәсе килә башлый: балачагында һәр кеше матурлыкка омтыла, аннан идеал ясый, шуны биектән эзли. Картайгач аның үз аяк астында икәненә төшенә, шул матурлыкны саклаучыга әйләнә.

Роберт Әхмәтҗанов иҗатында абстракт образлар күбесенчә төсләр белән билгеләнә, алар рәссам полотносы кебек күз алдына килеп баса. «Тагын да көз» шигырендә ул яшел киңлектән зәңгәр дулкыннарга очкан кызыл кошлар турында болай ди:

Тагын да көз. Кызыл кошлар оча
Зәңгәр дулкыннарга.
Җәйге хыял өзелә куаклардан,
Ята җир тыңларга
[Әхмәтҗанов, 1980, б.178].

Яки зәңгәр күктә көмеш чылбыр — китеп баручы торналар тавышыннан сары яфрак коелу сурәте («Торналар оча»), ап-ак кар өстендә зәңгәр эзләр — яшьлек («Син — тик рәсем...) һ.б.

Гадәттә, шагыйрь абстракт образның нигезенә салынган беренче янәшәлекне үзе үк билгели, әсәр эчендә әйтә. Мәсәлән, «Кичке кошлар» (1973) шигырендә кичке кошлар һәм җавап табылмаган сораулар ул. Шигырь мондый юллар белән башлана:

Эңгер төшкәндә
Кичке шәфәкъ фонында
Күмәкләшеп, тезелеп,
Кайта башлый кичке кошлар
төркеме;
Кайталар, кайталар...
[Әхмәтҗанов, 1990, б. 202].

Шигырь уртасында аларга янәшә образ табыла, мондый юллар китерелә:

Шулай йөри минем җир өстендә,
Чит күк асларында, гизеп җирне,
Ерак таулар артында, шәфәкъ
батканда
Җавап табылмаган сорауларым —
әйләнәләр дөньяларны!
[Әхмәтҗанов, 1990, б.202].

Детальләр ярдәмендә автор янәшәлекне төгәлләштерүгә юллар күрсәтә: кошлар кичен кайта — туктар урын, үз оясын эзли (монда архетипик «мәңгелек әйләнеп кайту» мотивы укыла), кешеләрнең җавапсыз сораулары исә үз асылларын, кем булуларын аңлауга юнәлгән. Шул рәвешле, шигырь яшәешне танып бетерү мөмкин түгеллек турында. Кошлар кайту күренешенең кабатлануы моны үкенеч, сагыш ноктасыннан бәяләргә ярдәм итә. Кешедәге һәм яшәештәге матурлыкның — җавап табылмаган сораулар кайту белән бәйле булуына ишарә ясый. Кешелек, кешеләрнең һәр буыны үз асылын аңларга омтыла, бу омтылыш туктаусыз хәрәкәт хасил итә.

Роберт Әхмәтҗановның сугыш темасына язылган классик әсәрләре дә мәйданнарда яңгыраган маршларга әйләнә («Солдатлар», 1965). Шул ук вакытта шагыйрь традиционлык иң көчле сакланган сугыш темасында да тәҗрибәләр ясый. «Әбием экиятләре» (1965) шигырендә халык экияте белән янәшәлек авангардлык билгесенә әйләнә.

— Төлке, төлке, Төлиман,
Төнлә кая барасың?
— Актүтине Бүре тоткан,
Шуны куа барамын...
— Актүти синә ни бирә?
— Җылы, йомшак өй бирә...
...Ак инештә — ак мамык, —
Актүтине тапмадык...
Күрсәтте безгә еллар
экиятнең яңасын:
кочаклады ир-егет
сөйгән ярын, анасын...
— Улым, улым, ул кеше,
Таңнан кая барасың?
— Идел-йортка яу кергән,
Шуны куа барамын!
Кан дәрьясын кичәсе бар,
Оясына җитәсе бар
Дошман — йөзе караның...
[Әхмәтҗанов, 1990, б. 312].

Әлеге алым — татар мифологиясенә мөрәҗәгать итү — сугышны туган җир, милли оя өчен көрәш дәрәҗәсенә күтәрә. Идел-йорт, милли кыйммәтләр, ана һәм сөйгән яр

өчен сугышка бару идеясе шулай ук 1960 еллар поэзиясендә өр-яңа сүз булып яңгырый.

Роберт Әхмәтҗановның «Уйна, улым!» (1964) поэмасы сугыш темасына яңача якын килгән беренче авангард әсәрләрдән була. Поэма тулысынча модернизм таләпләренә җавап бирә: ул өч буын язмышын колачлаган хаотик тормыш моделен төзи. Аның үзәгендә исә күпмәгънәле, әсәрдәге берничә эчтәлеккә юл күрсәткән уен образы тора.

Уен, беренче чиратта, өч буынны берләштерә һәм, гомумән, кеше тормышына хас үзенчәлек кебек тәкъдим ителә. Поэма лирик геройның кечкенә малае уенын күзәтүе белән башлана:

Идәнеңдә ята солдатларың,
Калай әтәч,
Агач космонавт...
Солдатларың кулсыз
(син бик усал!)
Бер почмакка китеп поскан ат.
Синең, гүя биредә — автопарк!
«Пожарный»лар килеп туктаган;
«самосвал»лар тора әмер көтеп,
Тик песиең генә йоклаган...
Шулай, улым,
Син уйныйсың, әйдә,
Уйна, уйна —
Уйнар чакларың.
Гомер буе уйнамассың әле —
Килеп җитәр уйлар чакларың!..

[Әхмәтҗанов, 1990, б. 373].

Аннары уен әтиләр һәм «мин» буынына карата да кулланыла:

Уйнадылар еллар безнең белән,
Уйнадылар —
Исең китәрлек!
Агач мылтык белән күзенә төбәп,
Ул елларның исен китәрдек.
Ә этиләр, чын мылтыклар белән,
Шундый «уйнадылар» сугышны,
Шундый уйнадылар —
Ике арада
Үлем төяп чуен туп очты!..

[Әхмәтҗанов, 1990, б. 376].

Шул рәвешле, образ башта бер нәселгә караган өч буынны бәйли. Малае уйнап йөргәнне күзәтүче лирик герой үзенең «очты-очты» уйнаганнарын һәм бу вакытта этиләрнең сугышта булганлыгын искә төшерә. Һәр кеше гомере — уен, дигән нәтиҗәгә килнә. Язучының кабат-кабат «очты-очты» уенына мөрәҗәгать итүе уенны милли җирлеккә куя, әлеге геройларның, буыннарның милли йөзен билгели.

Поэма барышында уен образының мәгънәсе киңәя бара. «Ватан белән уйнау» төшенчәсе пәйда була:

Ә магнатлар акча чөеш уйный:
Ватанын да сала уртага...
Барыннан да әйбәт уйный заман —
Алышына төсләр картада!

[Әхмәтҗанов, 1990, б. 377].

Кешеләр һәм илләр генә түгел, гасыр белән гасыр («Башын иеп иске дәвер китә — / Үз уенын инде уйнаган...»), табигать һәм Җир шары арасында уен бара: димәк ул — яшәеш законы:

Төннәр буена болай, «уйнап кына»
Ураганнар Җирне дөмбәсли!
Уйнап кына атылып китә йолдыз —
Метеор бәрә кораб бортына...

[Әхмәтҗанов, 1990, б. 375].

Әсәргә эпиграф итеп китерелгән юллар әлеге түгәрәккә кояшны урнаштыра һәм яшәештәге һәр нәрсәнең уен булуын тагын бер кат ассызыклый:

...Уйный кояш,
Әйе, ул да уйный,
Уйный язны, Җирдә җәй ясый,
Уйный Кояш, сөю җырын уйный...
[Әхмәтҗанов, 1990, б. 373].

Эпиграф әлеге хаосны җиңү мөмкин түгел икәнне дә күрсәтә. Яшәешне гармониягә китерү юлын исә шагыйрь поэманың ахырында билгели: теләсә кайсы уен кешелеккә җылы китерерлек булырга тиеш! Бу фикер эпиграфтагы кояш образы белән ассоциатив бәйләнешкә керә һәм шагыйрь кешене галәмнең, яшәешнең кояшы дип игълан итә:

Хуҗа булыр өчен бу тормышка,
әнә шулай
елап-көлеп үсә кешеләр!..
Нәни кешеләр! Җирдә баштанаяк
Манам, диеп, сезне бәхеткә,
Тавыш-тынсыз,
Сүзсез җыр шикелле
Яна Кояш алтын Тәхеттә!
Җылы булсын өчен кешелеккә,
Кояш түгел, без дә янабыз...
Баш очында
Сүзсез җыр шикелле
Яна Кояш —
Алтын полонез!
[Әхмәтҗанов, 1990, б. 380].

Кешене зурлау, аны тормышның, күкләрнең хуҗасы итеп күрергә теләү мотивы бер ел алдарак иҗат ителгән «Таш аргамак» (1963) авангард поэмасында да шактый көчле белдерелә. Хаос үзәгендәге таш образы хәтерне дә, үлемне дә, мәңгелекне дә, кешенең яшәеш, галәм өчен җаваплылыгын да, көчен һәм хөрлеген дә өр-яңа формаларда, үзгә алымнар ярдәмендә раслый.

Шулай итеп, 1960 еллар авангард күтәрелеше дулкынында татар шигърияатенә килеп кергән, бигрәк тә 1960—70 нче еллар аралыгында үзенең уникаль әсәрләре белән танылу алган Роберт Әхмәтҗановны без шушы күтәрелешнең элитар иҗат вәкиле, «сәнгать өчен» иҗат итү шигарен кабат мәйданга менгерүчеләрнең берсе буларак бәялибез. Янәшәлекләр һәм кабатлаулар ярдәмендә абстракт образлылыкка килү юлын тапкан, шуны татар поэзиясендә милли иҗат формасы буларак раслаган шагыйрь үз язу рәвешен булдыра — психологик абстракционизм агымына караган әсәрләр яза. Аның авангард иҗаты (кызганычка каршы, 1970 еллардан соң шагыйрь бу юнәлештәге эзләнүләрен нык киметә, романтик шигърияткә өстенлек бирә) үзен югары зәвыклы, төсләр, тавышлар, тышкы дөнья рәсемнәре һәм кешенең эчке кичерешләр байлыгын бергә тоташтырып гармония тудыра алган матурлык җырчысы, татар әдәбияты өчен ят булмаган модернизм алымнарына күпләп мөрәҗәгать итеп, чынбарлыктан бөтенләй үзгә, ераклашкан шартлы дөнья тудыручы итеп таныта. Лирик герой үзе дә — җир белән күк арасында, ак болытта, яки тормышка балачак күзләре белән караучы, кеше иҗат иткән балачак дөньясында яшәүче яки чынбарлыктан шунда качучы булып тәгәлләшә.

Ул һәр кешенең — табигать, яшәеш белән бергә-бер көн итүче, мөнәсәбәтләр коручы аерым мөстәкыйль дөнья икәнлеген фәлсәфә дәрәҗәсенә күтәрә, шуның белән татар фәлсәфи фикеренә өр-яңа сулыш өрә. Ана, сөйгән яр, туган җир — Идел-йорт образлары милли төсмерле яңгыраш ала. Мифологик материаллардан, мотивлардан иркен файдалану, әкияти детальләштерү бу иҗат өчен гаять мөһим.

Кешенең индивидуальлеге — тормышка караш индивидуальлеге белән бәйләнә. Импрессионистик, гүзәл һәм хәрәкәттәге, җете төсләр бер-берсе белән очрашкан тышкы дөнья сурәте гаҗәеп формалар ала. Тормышны нечкә тоемлаучы, матурлыкны аңлый һәм бәһали белүче кеше күзләре аша тасвирлау сурәтләнгән дөньяның да, сурәтләүче кеше күңеленең дә байлыгын, күпкырлылыгын, кабатланмаслыгын раслау юлына әйләнә. Яңгыраш, сүзләрнең сайланышы ярдәмендә көй-халәт тудыру, серлелек, уен, әйтеп бетерелмәгәнлек бу иҗатта табылып бетмәгән мәгънәләр булуына ишарә ясый. Шагыйрьнең ирекле шигырь формасын куллануы тышкы дөнья сурәтен аерым фрагментларга бүленә торган «рәсем» итеп оештырырга ярдәм итә. Ләкин нәкъ менә төрлечә укыла торган абстракт образ барлык кисәкләрне тоташтыра һәм чиктән тыш гомумиләштерә, үз тирәсенә автор әйтергә теләгән фикерләрне туплый һәм, хәтта, укучыга уйлап бетерү өчен юнәлеш тә күрсәтә. Матурлыкка соклану, яктылык һәм гүзәллекнең бары тик вакыт узуга бәйле югалтулар сагышы белән кушылуы бу иҗатны, ахыр чиктә, якты иҗат буларак бәяләргә юл ача.

**Әдәбият**

*Әхмәтҗанов Р.В.* Каләм җиле. Казан: Мәгариф, 2006. 207 б.

*Әхмәтҗанов Роб.* Җәяүле күбәләк: шигырьләр, балладалар, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 415 б.

*Әхмәтҗанов Р.В.* Орчык җыры: шигырьләр, балладалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 144 б.

*Әхмәтҗанов Роб.* Таш аргамак: шигырьләр, балладалар, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 304 б.

*Әхмәтҗанов Роб.* Хәтер елгасы: шигырьләр, балладалар, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 320 б.

Теория литературы. Том IV. Литературный процесс. М.: ИМЛИ РАН, «Наследие», 2001. 624 с.

*Хәким С.* Кайдадыр зур мәйданнар // Социалистик Татарстан. 1973. 10 июнь.

Электрон ресурс // rudocs.exdat.com/docs/index — мөрәҗәгать итү вакыты: 3.06.2014.

Мәкалә № 14-14-16002 РГНФ гранты кысаларында эшләнде

***Заһидуллина Дания Фатыйх кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең баш гыйльми сәркатибе*
*E-mail: zagik63@mail.ru*

УДК 821.512.145

*Ф.Ф. Хәсәнова*

# ЗИННУР МАНСУРОВ ИҖАТЫНДА ТУКАЙ ТЕМАСЫ

В статье рассматривается творчество З. Мансурова по отношению к Тукаю. Поэт очень своеобразно подходит к освещению образа поэта. Его стихи предельно насыщены самобытной философией и даже некоторой научностью.

**Ключевые слова:** здоровье Тукая, вечная мерзлота, пожизненный объект купли-продажи, афоризм.

Зиннур Мансуров иҗатында Тукай темасы берничә төрле юнәлештә чагылыш таба. Беренчедән, аның үзенең Тукайга багышланган шигырьләре бар, әмма алар сан ягыннан күп түгел; икенчедән, шагыйрьнең Тукай иҗатына багышлап язылган әдәби-публицистик хезмәтләре аерым фәнни тикшерү объекты булырга дәгъвалый; өченчедән, Тукай әсәрләреннән эпиграфлар куеп язылган шигырьләр З. Мансуровка Тукай фәлсәфәсен заман проблемаларына бәйләргә ярдәм итә.

Тукай, үпкә авырулы булу сәбәпле, гомере буе җылы җитми тилмергән. Аның әсәрләрендә, хезмәтләрендә салкынны авыр кичерүе турында еш искә алына, хәтта бер шигыренә «Туңучы» дигән имза куюы да билгеле. З. Мансуровтагы 6 строфалык «Туңу. Тукай» шигыренең бер аспекты — «туңу» сүзенең номиналь мәгънәсе — шуның белән аңлатыла. Тукайның солдатка каралыр алдыннан Өчиле авылына кайтуы мәгълүм. Ул анда, җиңгәсе сөйләве буенча, үзе теләп ике-өч атна тирәсе нарат бүрәнәләреннән салынган, көнгә ике тапкыр ягыла торган, мунча кебек җылы кечкенә өйдә яши. Кайтканда аны арбадан күтәреп төшергән булсалар, киткәндә ул үз аягы белән йөрерлек хәлгә килә. Җиңгәсе истәлекләре буенча, Тукай көн саен бер касә тирәсе тавык шулпасы эчкән, урамга чыгып, йөреп кергән, шул рәвешле яшәп, ахырдан китаплар укырлык хәлгә җиткән.

Тукайчы Ф. Зыятов язганча, Өчиле авылы Габдулланы дүрт тапкыр ач үлем тырнагыннан алып кала. Беренчесе: 1886 елның 29 августында, ире Гариф мулла вафат булгач, Мәмдүдә, улы белән, этисе Зиннәтулла өенә, кире туган авылы Өчилегә кайтырга мәҗбүр була. Икенче тапкыр, 1892 елда Казанның Яңа бистәдәге Мөхәммәтвәли белән Газизә исемле «эти-әнисе» икесе берьюлы авырый башлагач, Габдулланы яңадан Өчилегә кайтаралар. 1893 елда Габдулланың яраткан Саҗидә апасын кияүгә бирәләр. Никах һәм туй мәҗлесенә Кырлайдан Габдулланы да өченче тапкыр Өчилегә алып кайталар.

1911 елның кышында Тукайның сәламәтлеге бик нык какшый. Аны Клячкин хастаханәсенә салалар. Докторлар аңа авыл һавасында булырга киңәш итә. Тукай, алдан хат язып, рөхсәт сорап, 1911 елның декабрендә Кәбир мулла белән (Зиннәтулла улы) Рабига абыстай гаиләсенә кайта. Бу кайтуыннан Тукай бик канәгать кала. Аның Г. Шәрәфкә язган хаты шуны күрсәтә. Өчиледә ул үзенең 13—14 шигырен дә яза. Монда ул 1912 елның март аена кадәр яши.

З. Мансуровның «Туңу. Тукай» шигырендә тирәнгә яшерелгән фәлсәфи катлам да бар. Ул Тукайны

«бөек Туңучы» дип атый. Тукайга бөтен дөнья мосафирханәдәге үз номеры кебек салкын булып тоела. Шагыйрь З. Мансур салкынлыкның сәбәпләрен эзли. «Салкын йөзләр, боз күңелләр, туң йөрәкләр салкынлык китерәдер» дип фаразлый. Боларга салкын сугышларны да өстәп җибәрә. Тукай Өчилегә көз ахыры — кыш башында кайта. Шигырьдә төп өч туңучыны шәйләргә була. Аларга Тукай үзе, сабый бала һәм каз тәне чыгып туңган һәр кеше керә.

З. Мансуров иҗатындагы тагын бер шигырь «XX гасырның унөч елы» дип исемләнә. Шигырьнең көчле позициясенә Тукайның «Мин сыялмыйм… фани дөнья вакътына…» дигән шигырь юллары куелган. Шигырьдә ике баштан янып килә торган «гомер шәме» метафорасы кулланылган. Гомер шәме дерелдәп янган вакытта, күктә, ятим улы өчен түр эзләп, Ана җаны очып йөри. Шагыйрь, тиздән гомере өзеләчәген сизеп, иҗат итеп калырга омтыла. З. Мансуров әлеге фикерне «Өлгерергә кирәк, Аллаһының вәхиләрен акка күчереп» рәвешендә бирә.

З. Мансуровның «Ике яклап янган шәм» исемле ике басма табак күләмендәге публицистик хезмәте дә бар. Әлеге хезмәт «Һәммә татарның да үз Тукае бардыр» сүзләре белән башланып китә. Биредә Тукайның биографиясе белән бәйле мәгълүматларга шагыйрь үз мөнәсәбәтен белдереп бара. Тукай тормышындагы кечкенә генә булган деталь дә З. Мансуровның очлы күзеннән качып кала алмый, анализлана, һәрберсенә фәлсәфи мәгънә салына. Тукай сигез яшендә Кушлавычның могтәбәр кешесе Ситдыйкка кул суззмаган, Яңа Бистә бае урыс йортында аны кайнатманың күбеге белән сыйлаган, Степан байның йодрыгыннан тамган бер тиенлек акчаны Тукай кызыл билле прәннеккә тоткан һ.б. Китерелгән фактлар «өченче яшен тутырганда ук бер кибән арыш хакына асрамага бирелгән Апушка гомере буена алып сату корбаны булып калырга язган» дигән нәтиҗәгә тоташа. Гомумән алганда, әлеге хезмәттә Тукайның ачы язмыш белән дә, үпкә чире белән дә көрәшүе турында языла.

З. Мансуровның тагын бер шигыре «Шагыйрь янәшәсендәге урын» дип исемләнгән. Биредә апрель аенда шагыйрьләрнең, җыелып, Кырлайга Тукай музеена кайту вакыйгасы сурәтләнә. Күп шагыйрьләр арасыннан Д. Көгелтинов, С. Баттал, И. Машбаш исемнәре атала. Бу көннең исеме: «шагыйрь туе». Тәхеттә Тукай утыра. Пәйгамбәрдәй халык хадимнәре бары тик Тукай туган көндә генә бергә җыела ала. Җыр-моң, шигырь уку китә. Шунда «Тукай кырыенда… урын бар…» дигән хәбәр кинәт кенә барысын да сискәндереп җибәрә. Шигырьдән аңлашылган фикер шундый: бер шагыйрь дә буш урынны алып калырга ашыкмый. Шагыйрь үзе анда Зәйтүнәдәй басып торган бер кызны тәкъдим итә. Шигырьдә тәкъсир, хадим, шаһ, көрси кебек гарәп-фарсы алынмаларының күпләп кулланылуы күзәтелә.

«Бурыч» шигыре «Тукай үлгән хастаханәдә дөньяга килгән сабыема» дигән эпиграф-багышлау белән язылган. Гадәти багышламадан аермасы тирән фәлсәфи һәм гомумиләштерелгән характерда булуыннан килә. Шагыйрь үз баласына зур өметләр баглый, язучы булып үсәр, дип хыяллана. «Күңел кошы» исемле метафора биредә ачкыч сүз ролен үти. Күңел кошы ул — чын

шагыйрьлек сыйфаты. Бу метафора тагын «Тукай бакчасына кереп шигырь язам» формасында «Карга» шигыренә дә килеп керә. Әлеге шигырь мөтәшагыйрьләргә каршы юнәлдерелгән булуы белән истә кала.

З. Мансуровның зур күләмле «Балкыш, яки Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш язмаларыннан юллар» исемле поэма-руладасы бар. Бу әсәрдә «төштәй кыска гомеренә гасырларны сыйдыралган Тукайҗанның чанасы» детале күзәтелә. Шигырьдән аңлашылган төп мотив *«Ватан исән калсын өчен, кемнәргәдер атыласы, кемнәргәдер асыласы, кемнәргәдер янасы»* дигән символик сүзләрдә чагылыш таба. Биредә заманча табигать-сәясәт белән милли әдәбият проблемалары да күзәтелә. Ул *«тургайлар белән Тукайлар килүе сирәгәя»* дигән афористик фикер эченә сыйдырыла.

«Татарлык» шигыре халыктагы тискәре сыйфатларны тәнкыйтьләүгә юнәлтелә. *«Тырнак астыннан кер эзләү»* шуларның берсе, дип билгеләп үтелә. «Ретро» шигырендә Тукай шигыреннән эпиграф алынганлыгы күренә. Биредә тәртипсез тормыш алып баручы хатын-кыз тәнкыйтьләнә. *«Мәңгелек бусагасы»* шигыре тирән фәлсәфи эчтәлеккә ия. Ике строфалык бу шигырьдә 4 афоризм урын алган. Шигырь шагыйрьлек осталыгы турында. «Шагыйрьлекләр белән шөгыльләнмик, Тукай яшен узып барганда; тормышыңда, баксаң, тормыйсыңдыр Тукай күзендәге акка да» кебек афористик фикерләр әйтелә. Шагыйрь чын шигырь өчен көрәшә, дигән фикер кала. Шунысын да искәртеп үтү урынлы булыр, З. Мансуровның афоризмнары фикер тыгызлыгын гына түгел, үткен образлылыкның ирония белән кушылмасын да тәшкил итә. Искә төшерик: Тукай үзе дә шулай язган, бу шулай ук Тукай сатирасының бер үзенчәлеге булып тора.

Соңгы елларда З. Мансуров «Ачы тәҗрибә авазы» исемле күләмле хезмәтен бастырды. Биредә ул Тукай иҗатындагы образлы фикер, канатлы сүзләр, кыйммәтле хикмәтләрне сыйдырган афоризмнарны туплады. Дөрес, шагыйрь үзе аларны афоризмнар дип санамый, бәлки *«берәмтекләп җыелган фикри сөземтәләр»* дип исемли. Бу хезмәт тематик әңгәмәләр рәвешендә. Алар — бишәү. Шагыйрь аларны шигъри резюме буларак тәкъдим итә. Резюмеләр арасында *«зирәкләрчә әйтелгән гыйбарәләр дә, хөкемгә охшаш тәгъбирләр дә, үгет-нәсыйхәтле сентенцияләр дә,* шигарьдәй яңгырый торган өндәмәләр дә бар». Сайлап алынган әлеге гыйбарәләр татар халкының ачы тәҗрибә авазы буларак тәкъдим ителә.

«Тукайча «юл картасы» хезмәтендә З. Мансуров ислам дине белән татар әдәбиятының бергәлеге проблемаларына игътибар итә, уртак тамырларны барлый. Дин ул нәсыйхәттән гыйбарәт, вәгазьнең төбендә шулай ук сүз ята. Әдипнең дә төп коралы — сүз, дигән фикер җиткерелә. Биредә З. Мансуров танылган 12 дин әһеле исемен атый. Әлеге шәхесләрнең күбесе шагыйрьләр икәнен билгеләп үтә. Хезмәттә Тукайның «Дин кешеләрдән аерым түгел» дигән сүзләре ачкыч сүз вазифасын үти. «Дин әһелен дә, язучыны да тәрбияви сүз, изгегә тарткан каләм бер сафка куя» дигән фикер үткәрелә.

Йомгаклап әйткәндә, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе З. Мансуров иҗаты Тукай темасыннан аерылгысыз рәвештә бара. Үзе дә фи-

кер поэзиясе тарафдары булган шагыйрь, Тукайның һәр сүзенә, һәр гыйбарәсенә гаять игътибарлы булып, бөек шагыйрьлек вазифасын намус белән үти. Шунысы куанычлы, аның бу хезмәтен халык та, хөкүмәт тә күрә һәм бәяли. Шагыйрьгә күптән түгел генә «Татарстанның халык шагыйре» исеме бирелү шул хакта сөйли.

**Әдәбият**

*Зыятов Ф.* Тукай Өчиледә // Казан утлары. 2011. №4. Б. 120—123.

*Мансуров З.М.* Ачы тәҗрибә авазы // Мәдәни җомга, 2014. 4, 11, 18, 25, 30 апрель, 8, 16 май.

*Мансуров З.М.* Бездә әдәбият бар һәм дә бай әдәбият // Мәдәни җомга, 2013. 8, 15 февраль.

*Мансуров З.М.* Җәрәхәтле йөрәк җылырак: шигырьләр, поэмалар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. 448 б.

*Мансуров З.М.* Күңелдә фидаи яшәсә: сәнгать һәм яшәеш турында уйланулар. — Казан: Мәгариф, 2006. 495 б.

*Мансуров З.М.* Тукайча «юл картасы» // Мәдәни җомга, 2014. 27 июнь.

***Хәсәнова Фәридә Фирдәвес кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге җитәкчесе*
*E-mail: hasfar@mail.ru*

УДК 821.512.145:398

*Ә.Н. Нәҗипова*

# ӘДӘБИ ӘСӘР ҺӘМ ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ

Статья рассматривает функции народных песен в некоторых произведениях классиков татарской литературы. Автор делает вывод о том, что песни часто используются писателями и тем самым повышают ценность художественных произведений.

**Ключевые слова:** татарский фольклор, народные песни, художественное произведение.

Халык җырлары әдәби әсәрләрдә төрле максаттан кулланыла. Кайбер хезмәтләрдә авторлар җырлар аша идеяне турыдан-туры укучыга аңлатуны максат итеп куя. Мәсәлән, Нурихан Фәттахның «Итил суы ака торур» романында, Миргазиян Юнысның «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» повестендагыча, әсәрләрне халык җырларыннан алынган юллар белән атау төп идеяне укучыга алдан ук төшенергә ярдәм итә. Гомәр Бәшировның «Сиваш» повестенда исә җыр, әлегә кадәр ата-ана йортыннан ерак китмәгән, ихлас, саф күңелле яшь егет Шәмсинең эчке кичерешләрен тәэсирлерәк тасвирларга ярдәм итә, ул, үз чиратында, төрле сәнгать чаралары белән куертып бирелгән герой кичерешләренең, әсәрдәге вакыйгаларның кискенлеген, фаҗигале булуын ассызыклый. Үзенең кем яки нәрсә өчен сугышуын да аңламаган бу егет, үзе кебекләр белән «Сиваш» сазлыгына кереп, үлем белән капма-каршы очрашырга тиеш. Янәшәсендә генә үлем йөргән егетне бары бер нәрсә — тизрәк туган авылын, аның кешеләрен, этиәнисен күрү теләге кызыксындыра. Үзе өчен авыр, сагышлы минутларда ул «Көзге ачы җилләрдә» дигән җырны көйләп җибәрә:

Йөгереп китәрдәй булам,
Кайтып җитәрдәй булам,
Кичке салкын җилләрдә,
Туган-үскән илләргә шул,
Туган-үскән илләргә
[Бәширов, б. 90].

Чит-ят җирләрдә мәгънәсез сугышта катнашып йөрергә мәҗбүр булган гади авыл малае Шәмси өчен Туган ил ул — аның үз авылы, ул — авылының таулары, елгалары, сулары... Бу хисләрнең тирәнлеге, укучы күңеленә үтемлелеге җыр аша тагын да тирәнрәк, тәэсирлерәк тоела.

Гариф Ахуновның «Идел кызы» романында әсәр герое Габбас мулланың моңлы җыры, шулай ук, аның кайгы-хәсрәт белән тулган эчке дөньясын тагын да тирәнрәк күрергә ярдәм итә.

Базарларга барсаң, һай, ак тула ал,
Бәяләрен, абзый, үзем түләрмен.
Әҗәлләрең җитсә,
һай, әйт үземә-ә-ә,
Синең өчен үзем үләрмен
[Ахунов, б. 30].

Габбас мулланың матур, моңлы күкрәк тавышы белән, җаннарны айкап алырдай моңлы итеп җырлау сәләте үзләрен аннан өстен санап йөргән көндәшләрен дә уйланырга мәҗбүр итә. Халыкта «моңлы тавышлы кеше бәхетсез була» дигән гыйбәрә йөри һәм әйтерсең лә гомерен халыкка хезмәт итүгә багышлаган аңлы-белемле Габбас мулланың аянычлы язмышы бу сүзләрнең дө-

реслеген раслый. Г.Ахуновның романында исә җыр-көй кураен йөрәк турысына тыгып, башка милләт вәкилләренә күрәсәтергә оялып йөргән Атнабай образы аша бирелә. Ә Арслан, Лотфулла Дияров кебек геройларның матди байлыкларга гына кызыгып, шуннан файда гына күреп яшәргә һәм «бәхетле булырга» омтылулары ачыклана. Димәк, әдәбият галимнәре фикеренчә, социалистик реализм методы белән иҗат иткән язучылар да, үз әсәрләренә халыкның җырын, моңын, көен кертеп җибәрү аша, шул чорның шактый кискен проблемаларын күтәрә алганнар.

Мөхәммәт Мәһдиевнең киң колачлы вакыйгаларны үз эченә алган, кызыклы образларга бай булган әсәрләрендә дә җырлар халык үткән юлны, аның рухын, олы хисен чагылдыралар. «Кеше китә — җыры кала» повестенда җыр, моң катлаулы вакыйгаларны куертып, геройларның язмышы белән үрелеп бирелә. Әсәрдәге һәр геройның үз җыры, үз көе бар. Шуннан чыгып, алар бу тормышта үз бәяләрен алалар. Әдипнең башка әсәрләрендә дә (мәсәлән, «Торналар төшкән җирдә» повестенда) табигать байлыклары, мәхәббәт маҗаралары, татар халкының төрле бәйрәмнәре, кешеләрнең бер-берләренә мөнәсәбәтләре төрле җырлар аша аңлатыла.

Ф.Бәйрәмова матур әдәбият өлкәсендәге беренче күләмле әсәре — «Болын» повестенда җырга, үз гомерендә беренче тапкыр һәм гомерлеккә гашыйк булган саф күңелле Алсуның эчке хисләренең тирәнлеген бирү өчен мөрәҗәгать итә. Алсу авыл кызлары янына «кичке уен»га чыга һәм ул элеккеге татар кызларына хас кыюсызлык, оялчанлык белән үз йөрәгенә үтеп кергән егетне күзәтә башлый, героиняның уй-хисләре җыенга җыелган кызларның, егетләрнең җырларында чагыла:

Бишмәтеңдә биш төймә,
Нигә төймәләмисең?
Аралар да ерак түгел,
Нигә килгәләмисең?

*****

Исемнәре Нәфисә,
Шул яклардан җил иссә,
Бәгырьләремне кисә

[Бәйрәмова, б. 272].

Әсәрдә әби-бабаларыбызның яшь чакларында уйнаган уеннарын, моңлап көйләгән җырларын кечкенәдән тыңлап, өйрәнеп үскән Алсудагы һәм аның замандашларындагы ихласлык, моң торгынлык чорындагы гаделсезлек күренешләренә каршы куела.

Бишектән үк, ана сөте белән бергә, үз халкының авыз иҗатын аңына сеңдереп үскән, табигый таланты өстенә, тормышны белеп һәм кешеләрне, аңлап нәтиҗәләр чыгарырга сәләтле язучы гына чын әдәби әсәрләр тудыра ала. Аерым язучыларның иҗат портретларына күз салсак, аларның бик яшьтән халык авыз иҗаты белән авызланганлыкларын күрербез. Мәсәлән, үткән гасырның күренекле әдибе, үзенең тарихи романнары белән татар укучысын узган юлына борылып карарга мәҗбүр иткән, шуның белән чын-чыннан милли тойгылар, патриотизм тудырган Нурихан Фәттах үзенең истәлекләрендә «Халкымның телен, гореф-гадәтләрен аңлауда, үзләштерүдә моның (*сүз Л.Җәләй киңәшләре турында*) файдасы әйтеп бетергесез зур булды» — дип яза [Фәттах, 2014, б. 85].

Н.Фәттахның әсәрләрендә, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән бергә, җырлар да әһәмиятле роль уйный.

Мәсәлән, аның «Итил суы ака торур» (1969) тарихи романының исеме үк М.Кашгариның Идел — Чулман төркиләре, болгарлар җырлаган борынгы мәшһүр җырдан алынган, җырда Идел-йортта яшәүче бабаларыбызның үз туган җирләренә мәхәббәте, аның бай һәм гүзәл табигате белән горурлануы яңгырый, Идел буйларында яшәгән борынгы болгарларның бу җирләрне үзләренең туган туфрагы дип санаулары чагыла.

Н.Фәттах исә, романын «Итил суы ака торур» дип атап, Бөек Болгар җирләренең байлыгын гына күрсәтеп калмый, ә аның халкының батырлыгын, уңганлыгын, эшчәнлеген, акыллылыгын чагылдыра һәм әсәр исеме, башта ук, укучыга идеяне ачыкларга ярдәм итә. Мәгърур, зур елганың ургылып-ургылып агуын тасвирлау да бу җирләрдәге зур тарихи вакыйгаларга ишарә. Чөнки романда вакыйга моннан бер мең еллар элек (920 нче еллар тирәсендә), ягъни Болгарда рәсми рәвештә ислам дине кабул ителгән чорда бара. X гасыр һәм «Кол Гали» трагедиясендә гәүдәләндерелгән XIII гасыр — болар һәр икесе Урта Идел буе халыклары тарихында героик чор. Беренче һәм Икенче каганлык заманнары инде үткән, Хәзәр каганатлыгы да X йөздә сүнүгә, таркалуга таба бара. Ул чорлардан, нигездә, тарихи риваятьләр, легендалар, сөйләмнәр генә сакланып калган. Ләкин тормыш тукталмый. Игенчелек һәм һөнәрчелек үсә. Идел буенда мәктәп-мәдрәсәләр салынып, китап гыйлеме, укымышлылык тарала башлый. Утрак тормышта яшәүче ыруглар саны арттаннан-арта бара, яңа шәһәрләр калка, аларда төрле кабилә, ыруг кешеләре туплана. Шул нигездә яңа бердәмлек — болгар халкы оеша. Ләкин, боларның барысы да эзлекле рәвештә тормышка аша барсын өчен, бер үзәккә тупланган тотрыклы дәүләт булуы кирәк. Нәтиҗәдә, болгарларның феодаль катлавы Идел, Чулман, Агыйдел буйларында яшәүче күпсанлы кабиләләрне берәм-берәм үзләренә буйсындырып, аларны бер үзәккә туплап, шактый көчле дәүләт төзүгә ирешә. «Итил суы ака торур» романында Болгар иле тормышындагы әнә шул киеренке, катлаулы чор тасвирлана.

Чорыбызның күренекле әдибе Миргазиян Юнысның «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» повесте да (1979) җырдан алынган юллар белән исемләнгән. Анда Бөек Ватан сугышы вакыйгалары һәм сугышчыларның хәлләре югары сәнгать чаралары ярдәмендә, фәлсәфи уйлануларга нигезләп гәүдәләндерелә.

Әсәрдә яшәешнең табигый агышына зарар китергән иң зур золым — сугыш икәнлеге исбатлана, табигать тарафыннан адәм баласына бирелгән зур бәхет — яшәү бәхетенең шушы сугышны тудыручы явызлар тарафыннан вакытсыз өзелүе күрсәтелә. Гомумән алганда, әдип үзенең бу әсәрен яшәү, үлем, аның кануннары, мәгънәсе турында тирән фикерләп иҗат итә.

Повестьтагы төп геройлар — татар егете Сәйрин Сәләхов, кырым татары Марсель, якут егете Максим үзләрендәге гүзәл сыйфатлар белән укучыны сокландыралар. Әсәрдә егетләрнең һәрберсенең үз халкына гына хас күркәм милли сыйфатларны хөрмәт итүе, аңа табынып, аны зурлап фикер йөртүләре, сугыш кырларында зур батырлыклар эшләргә сәләтле булулары исбатлана.Үз милләтенең иң матур сыйфатларын туплаган бу батырларны ил, ватан, җәмгыять алдындагы гражданлык бурычы берләштерә. Туган илгә мәхәббәт,

патриотизм хисләре, гаделлек, намуслылык ата-ана нигезеннән башлана. Канлы сугышның алгы сызыгына барып җиткән бу очучы егетләр яшәү мәгънәсе, кешенең тормыштагы роле, халык, милләт язмышы, һәр милләтнең үзенә генә кагыла торган төрле катлаулы һәм гади мәсьәләләре турында уйланалар, киләчәккә матур планнар коралар. Ләкин соңгы очудан алар әйләнеп кайта алмыйлар. Сугыш бетәргә берничә көн генә кала егерме яшьләре дә тулып өлгермәгән өч батырның, өч төрки баласының газиз җаннары күктә өзелеп, гәүдәләре телем-телем булып, чит-ят җирләргә сибелә.

1945 елның 9 мае көнне Сәйрин Сәләховның әнисе Миңлезифа апа карчыклар җыя. Бу — сугыш беткәннән соң авылда үткәрелгән беренче мәҗлес. Бу — ананың газиз улы Сәйрин Сәләховның зур җиңү белән исән-сау туган йортына әйләнеп кайтуын тизләтү мәҗлесе.

Ә еракта, бик еракта искән җилләргә бәрелә-бәрелә егетләрнең рухы булып моң гына, тын гына ялгыз татар җыры яңгырый:

Шәмдәлләрдә генә утлар яна,
Гөлҗамал,
Җиткән кызлар киндер җеп
эрлиләр...
[Юныс, б. 264].

Әйтерсең лә егетләрләрнең сугыш тынып торган арада башкарган бу җырлары, ят җирләр, кырлар, урманнар аша үтеп, туган йортларына кайта да, Миңлезифа апа җыйган карчыкларның мөнәҗәтенә килеп кушыла һәм сугышта шәһит киткән егетләр рухына дога булып ирешә.

Вакыйганда да шулай бит:
Рәхәт көтсәк тә һәрвакыт,
Рәхәт көткән вакытларда
Коча да ала тар ләхет.

Һәм бары тик мөнәҗәтләрдә, халык җырларында гына сакланып калган бу моң, сафлык, пакьлек, хаклык утлы сугыш елларында Җир шарының төрле почмакларында төрле сәбәпләр белән корбан булган калган күп меңләгән җаннар — Марсельләр, Максимнар, Сәйриннәрнең рухларына кушыла да, яңа гасыр үрләрендә яшәүчеләрне алдагы сугышлардан, гаделсезлекләрдән саклану кирәклеген искәртү кайтавазы булып яңгырый [Нәҗипова, б.13—14].

Гомумән алганда, төрле чорларда язылган ил, халык өчен катлаулы һәм гадәти булган тормышны, вакыйгаларны чагылдырган әсәрләрдә язучылар җырларны, сәнгать чарасы буларак, киң күләмдә кулланып, әдәбиятыбызның кыйммәтен тагын да күтәрәләр.

**Әдәбият**

*Ахунов Г.* Идел кызы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 400 б.
*Бәширов Г.* Сайланма әсәрләр Казан: Хәтер, 2006. Б. 86 119.
*Бәйрәмова Ф.* Күңел карлыгачларым. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 272 б.
*Мәһдиев М.* Сайланма әсәрләр: 5 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. т. 3. 479 б.
*Нәҗипова Ә.* Сугыш еллары кайтавазы. Казан: Хәтер, 2010. Б. 13—14.
*Фаттах Н.* Избранное . Казань: Хэтер, 2011. С. 123 — 318.
*Юныс М.* Шәмдәлләрдә генә утлар яна. Казан: Хәтер, 2010. Б. 212 — 349.

***Нәҗипова Әлфинур Нурмөхәммәт кызы**, филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты доценты*
*E-mail: Nazfin@mail.ru*

УДК УДК 821.512.145

***Ф.Х. Миңнуллина***

# XX ГАСЫР АХЫРЫ — XXI ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ФАҖИГАЛЕЛЕК
## (А. Гыйләҗев һәм М. Гыйләҗев пьесалары мисалында)

Статья посвящена изучению категории трагического как формы образного мышления и ее отражения в татарской драматургии на примере пьес А. Гилязова «Три аршина земли», М. Гилязова «Рана», где показана трагедия человека, на долю которого выпали суровые жизненные испытания. Проблема противостояния героев трагическим обстоятельствам в безвыходной ситуации в каждой из рассматриваемых пьес является основополагающей и решается по-разному.

**Ключевые слова:** татарская драматургия, категория трагического, драма, герой, коллизия.

XX гасырның икенче яртысында башланып киткән үзгәрешләр XXI йөз башы татар драматургиясенә дә йогынты ясый: эчтәлек һәм форма ягыннан үзгәрешләр бара, заман белән бергә атлау омтылышы сизелә. Драматурглар моңа кадәр яктыртырга ярамаган темаларга һәм проблемаларга мөрәҗәгать итә башлыйлар. Болар барысы да ил күләмендә барган вазгыять, халык тормышында көтелмәгән вакыйгалар, борылышлар белән дә бәйле. Каләм ияләре тарафыннан гомумкешелек кыйммәтләре, кеше гомере, аның яшәеше, шәхес иреге мәсьәләләре алга куела. И. Юзеевның «Ак калфагым төшердем кулдан», Т. Миңнуллинның «Бажа мал түгел, кәҗә туган түгел», «Эзләдем, бәгърем сине», Р. Хәмиднең «Олы юлның тузаны», З. Хәкимнең «Телсез күке», «Легионер» кебек әсәрләрендә сүз тоталитар система гына түгел, ә безнең яшәешебездә чәчәк аткан мәрхәмәтсезлек, фаҗигалелек, кеше шәхесен изгән бюрократик идарәчеләр хакында да бара. Гомумән, татар драматургиясе иҗади процесс буларак, туктаусыз үсеш-үзгәреш кичерә. Әдәбиятта яңа әсәрләр иҗат ителә, яңа геройлар барлыкка килә. Даими рәвештә сәхнә әсәрләрендә иҗтимагый-сәяси һәм тарихи вакыйгалар, әхлакый мәсьәләләр, заман үзгәрешләре, буыннар бәйләнеше, милли традицияләр кебек мөһим проблемалар бөтен җитдилеге белән күтәрелә. Чорга хас үзенчәлекләр эволюцион үсештә сурәтләнә. Тема һәм күтәрелгән мәсьәләләрнең күплеге әдипләрне төрле жанр формаларына мөрәҗәгать итүгә, аларның мөмкинлекләрен иҗади файдалануга китерә. Драматурглар да чынбарлыкны чагылдыруда төрле алым-чаралар эзлиләр, яңа тормыш моделен төзиләр. Фаҗигалелек категориясе дә соңгы еллар татар драматургиясендә сурәтләү объекты рәвешендә үзгәреш кичерә. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрдән чыгып, аерым бер драматурглар, тарихның каршылыклы якларын, шәхеснең фаҗигале язмышын сурәтләү объекты итеп алалар. Билгеле булганча, Аристотель, беренчеләрдән булып диярлек, фаҗигалелек категориясенең асылын аңлата. Аннан соң ул Шеллинг, Гегель, Ю. Борев һ.б.ның хезмәтләрендә яктыртыла. Татар әдәбиятында әлеге мәсьәлә

Й. Нигъмәтуллина, Х. Мәхмутов, И. Еникеев, Ә. Закирҗанов хезмәтләрендә трагедия жанрына нисбәттә яктыртыла. Эстетик категория буларак, фаҗигалелек исә геройның ирекле эш гамәлен, кешелек идеаллары өчен көрәштә кайгы-хәсрәт, тирән борчылу, газаплану кичерүен чагылдыра [Шеллинг, с. 199]. Әлеге категориягә нигезләнгән пьесаларда кеше яшәешендәге хәл ителә алмаслык каршылык ята. Ю. Борев билгеләгәнчә, трагик герой әсәрләрдә көчле шәхес буларак ачыла, ул тормышта шундый катлаулы шартларга куела ки, бер яктан, авырлыкларга баш имәү, икенче яктан, каршылыкларны җиңеп чыгарга көче җитмәү аны зур газаплануларга, үлемгә китерә [Борев, с. 261]. Фаҗигалелек категориясенең шәхес ялгызлыгында, чынбарлык белән трагик каршылыкта чагылуын А. Гыйләҗевның «Өч аршин җир» трагедиясендә күрергә мөмкин. Гомумән, язучының повестьларында, драма әсәрләрендә тарихи каршылыклар арасында калган ялгыз кеше язмышы ята.

Трагедиянең сюжеты шәхес фаҗигасе алга куелу белән үзенчәлекле. «Өч аршин җир»дә тоталитар система корбаннарының җәмгыять тарафыннан кабул ителмәве, сәясәт һәм гаилә каршылыгы, сәяси вакыйгаларның кеше күңелен тупасландыруы, вәхшиләндерүе, кеше язмышын җимерүе кебек бер төркем проблемалар күтәрелә. Повестьта да һәм сәхнә әсәре өчен иҗат ителгән әсәрдә дә бай гаиләдә бердәнбер бала булып үскән Мирвәлине, иң ярлы кеше кызына өйләнүен белгәч, этисе йортыннан куып чыгара. Әти-әнисе вафат булганнан соң егет байлыкка хуҗа була, шул малны ишәйтү өчен күп көч сарыф итә. Әмма ил күләмендә башланып киткән колхозлаштыру геройлар язмышына фаҗигале рәвештә тәэсир итә. Бу үзгәрешләр авыл халкын капма-каршы якларга аера. Трагедиянең төп герое Мирвәли шул вакытта трагик хата ясый: йортына ут төртеп, малларын агулап, авылдан чыгып кача. Үз гаебенең ни дәрәҗәдә булуын ул соңрак, кырык ел үткәч, үлем түшәгендә яткан хатыны Шәмсегаян белән туган авылы Карачурага кайтканда аңлый. Шул юл вакыйгасында Шәмсегаянга китергән җан газапларының ни дәрәҗәдә фаҗигале булуына төшенә. Күңелендәге каршылыклы уйлар көрәше Мирвәлидә үткән һәм бүгенгенең эчке бәйләнешен ассызыклый. Фаҗигале язмышка дучар булган Шәмсегаян исә гомеренең соңгы көненә кадәр туган нигезен сагынып яши, ахыр чиктә туган ягына кайтканда юлда вафат була. Аның рухи газаплары аша милләт трагедиясе ачыла. Биредә автор яңа урнашкан тәртипләрне, системаны шәхес фаҗигасе аша ача. Шул рәвешле драматург: «Мирвәлинең күңел халәтен, үсеш-үзгәрешен тасвирлаучы чылбыр — аның авылдашларын гаепләвеннән алып, үз хатасын тану аша гафу үтенү баскычына кадәрге аралыгын тасвирлый. Мирвәли күңелендә барган эчке каршылык хис һәм акыл, совет җәмгыятендәге яшәү кагыйдәләре һәм үзеңчә яшәргә омтылу арасында төгәлләшә, шушы катлаулы, каршылыклы конфликт әсәрнең буеннан-буена сузыла» [XX гасыр..., б. 89]. Автор тудырган трагик дөньяда ирекле шәхес хәрәкәт итә. Ләкин ул шәхес ирегеи тормышка ашыра алмау белән каршылыкка керә. Драматургның төп максаты исә — үз җиреннән аерылган кешенең газап чигүен, туган илне

ярату хисен раслауны, авылдашларына хыянәт иткән геройның фаҗигасен күрсәтү. Аның усаллыгы, кылган гамәлләре дә авылдашларына карата түгел, ә урнашкан, халыкны коллык дәрәҗәсенә төшергән системага каршы юнәлдерелгән. Үз геройларының психологик халәтләре аша драматург совет хакимиятенә, аның сәясәтенә бәя бирә. Кешенең, шәхес буларак, үз милкенә хуҗа булу хисен юкка чыгаруга, битарафлыкка басым ясала. Тоталитар режим шартларында ирекле эш итәргә теләгән шәхеснең фаҗигасен күрсәтә.

Әсәр белән таныша башлауга ук аның характерлар бәрелешенә генә корылмавы, ә җәмгыятьтәге иң актуаль проблеманы калку итеп күрсәтү максаты белән иҗат ителүе аңлашыла. Заман алып килгән үзгәрешләр алдында кешенең еш кына көчсез булуы, җан тынычлыгы таба алмыйча, үз-үзе һәм әйләнә-тирәсендәгеләр белән каршылыкка керүе дә драматург игътибарыннан читтә калмый. Трагедиядә дәвернең трагик каршылыкларын чагылдырган геройлар язмышы алгы планга чыга.

Фаҗигалелекнең трагедия жанрында гына түгел, ә, элемент буларак, драманың башка жанр формаларына да үтеп керүе күзәтелә. Чөнки бүгенге көн драматургиясендә чиста формадагы трагедияләр «традицион» рәвештә бик аз очрый. Бу хакта рус драматургиясен өйрәнгән М.И. Громова да үз хезмәтләрендә билгеләп үтә [Громова, с. 96]. Бу исә жанрларның үсеш-үзгәреше, трансформация кичерүе белән дә бәйле. Рухи кыйммәтләрнең югала баруы, тормыш кыенлыкларын хәл итә алмау, хыял-омтылышларның тормышка ашмавы, шәхес фаҗигасен, шәхес һәм җәмгыять каршылыгын аңлатучы пафос буларак урын ала. Билгеле булганча, дра́маның максаты — шәхесне аның башка кешеләр, мохит белән катлаулы мөнәсәбәтләре аша күрсәтү. Геройлар әхлакый эзләнүләр һәм рухи үсеш процессында тасвирланалар. Ләкин аларга асылда, трагик геройлардан аермалы буларак, гадәттән тыш сыйфатлар хас түгел. Драма кискен каршылыклар, коллизияләр тудырырга омтыла, ләкин андагы конфликтлар, трагедиядәге кебек үк, киеренке була алмый, һәм алар, ахыр чиктә, уңай хәл ителергә дә мөмкин. М. Гыйләҗевның «Яра» драмасы шундыйларның берсе. Заман концепциясе ягыннан карасак, А. Гыйләҗевның «Яра» әсәренә нигезләнеп иҗат ителгән сәхнә әсәре XX гасырның 50 нче елларында — XXI йөз башында илдә барган үзгәрешләрне тарихи бәйләнешләрдә чагылдыра. Драматург пьесада тасвирланган геройлар аша, үткән чорның социаль күренешләрен, халык язмышын, аның яшәешен, уй-фикерләрен, катлаулы тормышларын сурәтләп, чынбарлыкта хөкем сөргән идеологик тәртипләр турында сүз алып бара.

М. Гыйләҗевның «Яра» драмасында кискен конфликтларга, шәхеснең эчке дөньясындагы каршылыкларга, халыкның рухи, милли тормышы мәсьәләләренә игътибар ителә. Тоталитар режимның кешене шәхес буларак юкка чыгара баруын, герой фаҗигасенең көчле халәтендә ачылуын, шул дәвер сәяси кануннарының дөрес булмавын күрсәтә. Драмада, повестьтагы кебек үк, Бөек Ватан сугышыннан соңгы авыл тормышы тергезелә. Шуларга бәйле рәвештә өлкән буын вәкилләре Сөләйман, Шәкүр, Зөләйха, яшьләрдән Габ-

дулла, Зәйтүнә, Хәлил тормышы мисалында тоталитар системаның, совет идеологиясенең асылы ачыла. Сөләйман белән Зөләйханың сугышка киткән уллары Габдулладан өч елдан артык хәбәр юк. Шуңа күрә дә әлеге билгесезлек алар йөрәгендә яра — җан сызлавы буларак бирелә. Габдулланың сөйгәне Зәйтүнәнең яңарак сугыштан кайткан Кәримҗанга кияүгә чыгуы, Сөйләйман карттан фатиха алуы шулай ук аларда төзәлмәслек җан ярасы тудыра. Зәйтүнәнең моңа кадәр яучыларны кире кагуы аларга улларының исәнлегенә өмет биреп торучы терәк булса, соңыннан исә бу ышаныч какшый бара. Әсәрдә даими рәвештә кабатланган авып баручы капка баганалары да шуны күрсәтүче символ буларак кабул ителә. Күңелендә тормышка яраксызлыгын аңлаган, яралардан танымаслык дәрәҗәгә килгән Габдулла әти-әнисен, сөйгәнен сагынып туган нигезенә әйләнеп кайта. Якыннарына тиешле дәрәҗәдә ярдәм итә алмаслыгын аңлаган егет туган нигезен ташлап китәргә була. Әмма аны бу адымнан Зәйтүнә туктата: баласын алып Сөләйман карт йортына күчә. Бирелә татар хатын-кызларына хас булган кыюлык, олы җанлылык чагылыш таба. Ә.Закирҗанов язганча: «...өмет һәм өметсезлек каршылыгы барлык вакыйга-күренешләрне иңләп үтә. Вакыты белән чарасызлык, көчсезлек, яшәүнең мәгънәсезлеге кебек мотивлар да яңгырап китә» [Закирҗанов, б. 110].

Вакыйгалар үсешендә халыкның идеологик кануннардан шүрләп яшәве, аларның бәлага юлыкканнарга ярдәм итәргә куркып торулары ачыклана. Драмада тоталитар режим шартлары халык өчен дәһшәтле вакыт буларак билгеләнә: кешеләрнең, халык дошманы дип, бер гаепсезгә кулга алынуы, ата-ананың сугыш кырында балаларын югалтуы һ.б. Пьесада улларының сугыштан кайтуын көтеп яшәүчеләр арасында Шәкүр карт та бар. Аның улы Хәлилне чит ил шпионы булуда гаеплиләр. Булмаган хәлләрне ачу өчен төрле җәзалауларга тарталар. Геройны кыйналу түгел, ә хаксызга рәнҗетелү ярасы күбрәк газаплый, әрнетә. Нәтиҗәдә, геройны кара машинага утыртып, билгесез тарафка алып китәләр. М. Гыйләҗев геройлары фаҗигале ситуацияләргә үз гамәлләре белән түгел, ә җәмгыяттә туган, урнаштырылган тәртипләргә бәйле рәвештә килеп керәләр. Халык фаҗигасе аерым бер шәхесләрнең психологик халәтләрендә ачыла. Шулай итеп, пьесада Шәкүрт карт язмышы аша ил, халык язмышындагы тагын бер фаҗигале яра ачыла. Сәнгать белгече Г. Зәйнуллина хаклы рәвештә язганча: «Иң куркыныч яра, җанның бетмәс авыртуы — бергәлекнең өзелүе» [Зайнуллина, 2004]. Пьесада Сөләйман карт йорты да символик мәгънәгә ия. Язучы төп игътибарын йортны әйләндереп алган ишегалдына юнәлтә, башка объектлар ярдәмендә аның чиген билгели. Ул бушлык, ялгызлык, җимерелгән хыяллар билгесе генә түгел, ә киләчәккә ышаныч буларак та төсмерләнә. Шул рәвешле йорт-нигез яссылыгында җәмгыяткә, совет идеологиясенә тәнкыйди караш ташлана. Туган йорт, туган ил, дәүләт совет режимын гәүдәләндерә. «Яра» психологик характердагы конфликтка корылган; персонажларның күңел дөньясы ачыла барган саен ул конфликтның система тарафыннан рәхимсез имгәтелгән шәхесләр фаҗигасе нәтиҗәсе икәнлеге күренә.

Әсәрләрдә моңа кадәр күпертелеп, идеаллаштырып сурәтләнгән социалистик җәмгыятьнең чын асылы ачыла. Яшәешнең озак еллар күләгәдә калып килгән ямьсез якларына игътибар арта, кеше һәм система каршылыгы әдәби чаралар ярдәмендә тасвирлана. Әйтергә кирәк, әлеге әсәрдәге Язмыш төшенчәсен Киләчәк, Тарих белән янәшә карарга мөмкин. Бу очракта шәхес язмышы — милләт язмышы, гаилә, ил, Ватан язмышы белән тыгыз бәйләнештә булуын күрәбез.

Бу ике әсәр татар халкы тормышында булган кискен борылышларны чагылдыруның ачык мисалы. Аларда аерым шәхесләргә, хәзерге җәмгыятькә әхлакый бәя бирүгә, социаль-психологик анализ ясауга зур игътибар юнәлтелә. Хокуксызлык турында сүз алып барып, Сталин режимына карата кырыс хөкем чыгарыла. Болар татар авыллары һәм кешеләре фаҗигасе генә түгел, бу — халык фаҗигасе. Биредә заман алып килгән үзгәрешләр алдында кешенең, еш кына, көчсез булуы, җан тынычлыгы таба алмыйча, үз-үзе һәм әйләнә-тирәсендәгеләр белән каршылыкка керүе дә драматурглар игътибарыннан читтә калмый.

**Әдәбият**

*Борев Ю.* Эстетика. М.: Высш. шк., 2002. 511с.

*Гилязов М.* Словарь любви. Казань: Татар.кн. изд-во, 2005. 399 с.

*Громова М.И.* Русская драматургия конца XX — начала XXI века. М.: Флинта: Наука, 2006. 368 с.

*Зайнуллина Г.* Здесь и везде! // Звезда Поволжья. 2004. 28 январь.

*Закирҗанов Ә.* Заман белән бергә. Казан, Татар. кит.нәшр., 2004. 126 б.

XX гасыр татар әдәбияты тарихы / фәнни редактор Д.Ф. Заһидуллина. Казан: Казан универ. нәшр. 2011. Т. 2. 198 б.

*Шеллинг Фридрих*. Философия искусства. М., 1966. 622 с.

***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*
*E-mail: minnullina77@mail.ru*

УДК 398

***И.Г. Закирова***

# В.В. РАДЛОВ ХЕЗМӘТЕНДӘГЕ БЕР ӘКИЯТ ТУРЫНДА

Статья посвящена исследованию отдельных мотивов сказки «Украденный кирпич», опубликованной в 4 томе «Образцы народной литературы тюркских племен» В.В. Радлова. При анализе сказки автор обнаруживает скрытые мотивы, которые до сих пор не выступали объектом исследования.

**Ключевые слова:** В.В. Радлов, сказка «Украденный кирпич», информация, мифология, скрытая информация, образ.

Татар халык әкиятләрен өйрәнелмәгән өлкә дип булмый. Аларны җыю-туплау эше XIX йөздә башланып китә. Беренче басмалар шул ук гасырның беренче яртысында күренә башлый. Мәсәлән, Мартиниан Ивановның 1842 елда Казан университеты типографиясендә басылган «Татарская хрестоматия» дигән җыентыгында сигез әкият бирелгән. Шулай да, халык иҗаты әсәрләрен, шул исәптән әкиятләрне дә, фәнни нигездә, төгәл һәм дөрес итеп язып алу эше В.В. Радлов исеме белән XIX йөзнең икенче яртысында башлана.

Атаклы тюрколог, этнограф, археолог, 150 дән артык фәнни хезмәтләр авторы **Вильгельм Фридрих Радлов** Берлин университетының философия факультетында укыганда шәрык телләре белән кызыксына башлый. Философия буенча диссертация яклаганнан соң, урал һәм алтай телләрен өйрәнү өчен 1958 елда Россиягә килә. Бераздан Барнаул тау училищесына немец һәм латин телләре укытучысы итеп билгеләнә. 1959 елда Россиягә тугрылык турында ант бирә һәм Россия гражданлыгын кабул итә. Галим шул көннән *Василий Васильевич Радлов исемен ала.* Барнаулда эшләү дәверендә җирле төрки халыкларның телләрен һәм халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнә башлый. Галим, 1960 елның җәеннән башлап, һәр ел төрки халыкларның тел үзенчәлекләрен һәм фольклорын өйрәнү максаты белән халык арасына чыга башлый. Ягъни, хәзерге тел белән әйткәндә, экспедицияләрдә була. Алтайда булган дәверендә барлыгы 10 төбәктә булып, алтай, телеут, шор, куманлы, тыва, казакъ, кыргыз, абакан татарлары (хакаслар), себер татарлары һәм кытайларның фольклорын һәм тел үзенчәлекләрен чагылдырган материал туплый. Үзенең халыктан язып алган материалларыннан 1866 елда «Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи» дигән унтомлыкның беренче, 1868 һәм 1870 елларда икенче һәм өченче томнарын бастырып чыгара. 1872 елда татар фольклоры өчен хәзерге көнгә кадәр иң әһәмиятле чыганакларның берсе булган дүртенче том — «Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. Часть IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменьских татар» дөнья күрә. Бу күптомлык

материалларның күләме белән дә, әһәмияте белән дә тиңдәшсез хезмәт була. Дүртенче томда себер татарларыннан 19 авылда җыелган йөз унбер әсәр урнаштырылган. Алар арасында дастаннар, әкиятләр, җырлар, риваятьләр бар. Аларның күбесе нәкъ шушы томга кергән булу аркасында гына безнең көнгә кадәр сакланып калганнар. Бу хезмәт татар халык авыз иҗатын тикшерүчеләр өчен дә, укучылар өчен дә кыйммәтле хәзинә булып тора. В.В. Радлов тарафыннан 50 гә якын әкият язып алынган. Алар арасында тылсымлы әкиятләр дә, тормыш-көнкүреш әкиятләре дә бар. Күбесе эчтәлеге һәм төзелеше ягыннан камил, укыр өчен кызыклы әсәрләр.

Бу әкиятләрнең берничәсе «Татар халык иҗаты» күптомлыгында басылган булса да, күбесе тикшеренүчеләр игътибарыннан читтә калып килә. Шулар арасыннан «Урланган кирпеч» әкияте дә (1872 елда басылган) хәзерге вакытта сирәк китапханәләрдә генә сакланып калган иде. Ниһаять, профессор Фәрит Йосыпов әлеге хезмәтне В.В. Радловның эшчәнлеген яктырткан кереш мәкаләләр белән бастырып чыгарды. Хезмәт яңадан татар укучысына әйләнеп кайтты.

Фольклористика фәнендә әкиятләрне В.Я. Проппка ияреп анализлау кабул ителгән. Беренче чиратта әкиятләрнең мифологик нигезләре, образлар системасы, сюжет линиясе тикшерелә. Борынгылыкны, мифологик нигезләрен яхшырак саклап калган әкиятләрне анализлау күп кенә яшерен кодларны ачыкларга ярдәм итә.

Хәзерге вакытта әкиятләрне яңача, аларда сакланган мәгълүматны ачыклау ягыннан анализлау да фәндә акрынлап урнаша бара.

Әкиятләр халыкның гасырлар буена тупланган тәҗрибәсен, белемен, акылын саклый. Әмма бу белемнәр күбесенчә яшерен, берничә катлы информация арасыннан аларны күреп, тотып алу да кыен була. Гадәттә беренче игътибар эчтәлеккә юнәлә.

В.В. Радлов томында урын алган «Урланган кирпеч» әкиятенә аерым тукталып үтик. Бу әкиятнең дә эчтәлегендә халыкның дөньяга карашы, белеме, тәҗрибәсе яшеренгән. Әкият шактый маҗаралы булып, беренче өлеше Шерлок Холмс турындагы сюжетны хәтерләтә. Өч бертуган егет, үзләренең күзәтүчәнлекләренә таянып, логик яктан фикер йөртеп, күрмәгән нәрсәләре турында да күргән кебек сөйләп бирә алалар. Хан аларның җавапларында чичәнлек күрә. Бу кешеләр турында яхшырак белү максаты белән аларны үзендә калдыра, егетләрне сыйлар һәм сынар өчен берничә төрле ризык җибәрә.

Әсәрдәге беренче яшерелгән катлам — ризык, аның сихри көче, аңа сеңдерелгән яшерен мәгълүмат турында. Әкияттә ашаган ризыкның кешенең аңына тәэсир итә алуы турында сүз бара.

Хәзерге вакытта суның информация саклавы турында белмәгән кеше аздыр. Ризык та шундый ук сәләткә ия, аның аша кешегә билгеле бер информация, һәм шуңа бәйле рәвештә билгеле бер халәт тә күчә ала. Әкияттә геройларга тәкъдим ителгән ризыклар да егетләрне аерым бер халәткә кертергә сәләтле булып чыга. Егетләр каберлек өстендә үскән җиләкне ашаганнан соң кайгылы халәткә керәләр, үлем кайгысын тоялар:

«Бу кешеләр җиләктән алып бербер күстән [күс — бөртек] алып

йиделәр. Аларның бере әйтте: «Әй, йимәгез, бу җиләк кайгылы җиргә чыккан җиләк икән».

Җиләк үзе үскән җирдәге — каберлектәге кайгыны үзенә сеңдергән һәм саклый булып чыга. Герой: «Бер күс алып ашаган идек, эчебезгә кайгы төште», — дип аңлата.

Хан җибәргән икенче ризык — куй ите. Геройлар куй итенең дә гаебен табалар. «Кунаклар бер-бер чәйнәп йиде. Аннан соң әйттеләр: «Ашамагыз! Бу куй ите түгел, этнең ите икән», — диде».

Хан, хәләл иттән гаеп тапканнар, дип, кунакларына үпкәли. Геройлар бу иттән нинди гаеп табуларын аңлаталар.

«Болар әйттеләр: «Безләр бу иттән бер бер йигән идек, күңлебездә берберебезне дошман тоттык, эт берберен сөймәде, аның өчен эт токымы кушылганын белдек» — диде».

Көтүче анасы үлгән сарык бәрәненең эт имеп үсүен сөйли. Аны ашаганнан соң кардәшләрнең күңелендә бер-берсенә карата усаллык хисе туа. Итнең усаллык турында мәгълүмат саклавы, һәм бу хиснең ит аша геройларга да күчә алуы күрсәтелә.

Татар халкы гомер-гомергә ризык әзерләгәндә эшне дога, Аллаһ исеме белән башлауны, чиста күңел, яхшы уйлар белән әзерләү мөһим булуны таләп иткән. Мәсәлән, икмәк пешерүгә гади эш итеп карамыйча, аны ритуал дәрәҗәсенә күтәрү, киемнең генә түгел, уй-фикерләрнең дә пакьлеге шуны раслап тора.

Хәзерге вакытта да ашаганда телевизор карау, кирәкмәгән сүз тыңлау ризыкка тискәре энергия күчүгә китерә ала. Әби-бабайларның ашаганда сөйләшүдән тыюлары, ашар алдыннан дога укырга кушулары шуның белән аңлатыла да.

Әлеге әкияттә сакланган икенче яшерен катлам — кеше формалашуда билгеле бер факторларның роле, тәрбия, геннар һәм кан аша күчә торган сыйфатлар турында. Совет чорында кеше бары җәмгыять һәм тәрбия җимеше буларак каралды. «Урланган кирпеч» әкиятендә кешенең формалашуын тәэмин итүче тәрбиядә, мөһим фактор буларак, геннар аша килә торган хәтер һәм кан күрсәтелә. Бу татар халык мәкалендә дә сакланган. «Җан тартмаса да, кан тарта» дигән мәкаль канның кеше формалашудагы роле турында.

Кешенең характеры формалашуда өч фактор мөһим булуы хәзерге вакытта галимнәр тарафыннан инкарь ителми. Бу — геннар яки кан аша тапшырылган хәтер, икенчесе — тәрбия һәм өченчесе — кеше тәрбияләнгән җәмгыять, аның әйләнә-тирәсе. Кешенең һәр эшгамәлендә шушы өч факторның берсе чагылыш таба.

Геннар аша күчә торган хәтер ханның эш-гамәлләре аша күрсәтелә. Ул һәр ризык алдыннан геройларга икмәк җибәрә, икмәкне һәрвакыт алга куя. Ханның бер ризыкка булган игътибарын әкият геройлары болай аңлата: «Аннан соң хан өенә килде, кунакларга аш җибәрде, ашының алдында һәр даим нан җибәрер иде. Хезмәткәрләр нанны алып килеп, нанны биреп, тышкары чыгып тыңладылар. Болар әйтте: «Бу хан хан баласы түгел икән, нан сатучының баласы икән», — диде».

Алга таба ханның турыдан эш итмичә, яшерен рәвештә сүз тыңлавыннан да нәтиҗә ясала, геройлар хан турында: «Үзе никахсыз туган икән», — диләр. Шулай да ханның эш-гамәлләрендә тәрбия, аны тәрбияләп үстергән ананың да йогынтысы бар. Ул кешеләргә карата

миһербанлы, гадел эш итәргә омтыла. Үзен үстергән ананың киңәшенә дә таяна.

Геройларның да эш-гамәлләре аша, аларның тәрбиясе генә түгел, нинди шартларда, ни рәвешле үсүләре күрсәтелә.

Йомгак ясап әйткәндә, әкиятләрнең мифологик нигезләреннән һәм сюжетыннан тыш та тикшерү өчен җирлек бар. Киләчәктә әкиятләр бу күзлектән дә тикшерелә башларлар.

Әкият В.В. Радловның «Образцы народной литературы тюркских племен живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи» [СПб., 1972. Ч. IV. С. 95—100] китабыннан алынды.

## Урланган кирпеч

Бер бай бар икән. Бик бай икән, ашкан, хисапсыз малы бар икән. Бер көннәрдә байның казасы җитеп үлде. Өч улы бар иде. Шул өч улы атасының ни малы бар иде, барын да җыеп һәм хисабыны алып, атасына садака кылды, калган малын тәрикә [үлгән кешедән калган мал, мирас] кылып бүлешеп алды.

Бер алтын кирпеч бар иде. Аны, таңла [таң белән] бүләрбез, дип, алып куйдылар. Иртә, бүлик, дип килделәр, бу алтын кирпеч куйган җирендә юк. Кайда икәнен белмәделәр. Бу өчәүнең үзгә кеше күргән юк иде. Һич беренең күререн белмәде, бер-береннән гаеп табып, табылмасмы икән дип, шул вәдәмин [ният белән] өчәү дә сәфәр чыкты.

Юлда килә ятса, бер дөянең юлын күрделәр, шул дөянең утлаган җирен күрделәр. Бер-бере белән әйтештеләр:

— Бу дөянең ал теше сынык икән, — диде.

Тагы килә ятса, дөя юлдан чыгып йөргән җирен күрде.

— Йөгенең уң ягында серкә су икән, сул ягында балы бар икән, — дип әйтештеләр.

Юлда тагы килә ятса, дөянең чүккән җирен күрде. Дөянең өстеннән бер кеше төшеп, җиргә сигән җирен күрде. Өчәү әйтештеләр бер-беренә:

— Бу хатын кеше икән, эчендә бер өч айлык бала бар икән.

Тагы юлда килә ятсалар, бер кеше ялан баш, ялан аяк йөгереп килә ятыр. Шул кеше болардан сорады:

— Әй дуслар! Бер дөя күрдегезме?

Болар әйтте:

— Юк, күргәнебез юк! — диде.

Карындашларыннан бере әйтте:

— Дөянең ал теше ерыкмы иде?

Шул кеше әйтте:

— Ерык иде.

Икенче карындаш әйтте:

— Дөянең йөкләгән йөге эчендә уң ягында серкә су бармы иде?

Шул кеше:

— Бар, — диде.

Бу әйтте:

— Сул ягында балы бармы иде?

Шул кеше әйтте

— Бар иде, — диде.

Өченче карындаш әйтте:

— Өстендә бер хатын бармы иде? Бу хатынның эчендә бер өч айлык бала бармы икән?

Шул кеше әйтте:

— Һай синләр угры икәнсез. Минем урлаган дөямдә ни билгесе бар, барын да әйтәсез. Әйтсәгез дә, дөямне күргәнебез юк, дисез. Мин сезне бушатмыймын [җибәрү, азат итү, китәргә рөхсәт бирү], ханга алып барамын, — дип, ханга алып килде өчәвен.

Ханга әйтте:

— Йә, тәксир [тәкъсыйр, руханиларга хөрмәт белән, олылап мөрәҗәгать итү сүзе] хан дат [зар, дәгъва], — диде: — Бу өч кеше минем дөямне күргәнебез юк, диде. Шулай әйтсә дә, үзләре дөямдә ни төрле билгесе барын, өстендә хатын барын, хатынның эчендә өч айлык бала барын әйттеләр. Бу кешеләр дөямне урлаган угрылардыр. Миңа хөкем кылып бирегез!

Хан болардан сорады:

— Бу кешенең дөясен алдыгызмы? Бирегез! — диде.

Болар әйтте:

— Юк, безләр алганыбыз юк, — диде.

Хан әйтте:

— Алмасагыз, дөянең ал тешенең ерыгын кайдан белдегез?

Болар әйтте:

— Безләр тешенең ерыгын үз аклыбыз белән белдек.

Хан әйтте:

— Йә, ничек белдең?

Болар әйттеләр:

— Безләр юлда килә ятып комда бер дөянең юлын күрдек. Дөя юлдан чыгып утлый иде. Үләнне чалып утлаганда, бер үлән тере кала иде. Шуннан белдек ал тешенең ерыгын.

Хан әйтте:

— Дөянең йөкләгән йөгенең уң ягында серкә су, сул ягында бал булганын кайдан белдегез?

Болар әйттеләр:

— Дөя юлдан чыгып утлаганда үләннең озын җирендә йөге үләнгә сыелса [эләксә], уң ягына кымырска үләнгә үрә [менә] иде, сул ягына чәркәй [чебен] үрә иде. Аннан йөгендә серкә су белән бал булганын белдек.

Хан болардан сорады:

— Дөянең өстендә хатын булганын, бу хатын эчендә өч айлык бала булганын кайдан белдегез?

Болар әйтте:

— Тагы юлда килә ятып, дөянең чүккән җирендә бер кеше төшеп сиде, сигән дә, хатынның сигән җирен күрдек. Бу хатын торганда өч бармагы белән таянып торды, эчендә өч айлык бала барын аннан белдек.

Хан әйтте:

— Ай, сезләр, чичәнлек белән җавап бирәсез, мин сезне каравылга бирим.

Шулай итеп каравылга бирде, боларны алып барып бер өйгә куйды.

Бер хезмәткәре җиләк алып килгән иде, шул кунакларга җиләк биреп җибәрде, бер кәнизәккә әйтте:

— Җиләкне алып барып бир, үзең тышкары чыгып тыңла! Ни сөйләшерләр, монда кайтып килеп әйтсен, — диде.

Кәнизәге җиләкне алып барып биреп, тышкары чыгып тыңлады. Бу кешеләр җиләктән алып бербер күстән [бөртек] алып йиделәр. Аларның бере әйтте:

— Әй, йимәгез, бу җиләк кайгылы җиргә чыккан җиләк икән.

Бу сүзне ишетеп кәнизәк килеп ханга әйтте:

— Әй, хан, килгән кунак бу җиләктән йимәде, кайгылы җиргә чыккан җиләк, диде.

Хан килеп болардан сорады:

— Моны кайгылы җиргә чыкканын кайдан белдегез?

Болар әйттеләр:

— Моны бездән сорамагыз! Ул җиләкне алып килгән кешедән сорагыз! Аннан соң без җавап бирербез!

Хан хезмәткәрдән сорады, хезмәткәр әйтте:

— Бу җиләкне кабернең өстеннән алган идем.

Бу өч карындаш әйтте:

— Сорасагыз, аннан белдек, бер

күс алып ашаган идек, эчебезгә кайгы төште.

Кич булганда хан бер куй суеп, пешереп кунакларга җибәрде. Бер кәнизәккә әйтте:

— Бу итне алып барып кунакларга биреп, тышкары чыгып тыңла, ни сөйләшсә, әйткән сүзләрен миңа килеп әйт!

Кәнизәк бу куйның итен алып, кунакларга алып биреп, тышкары тыңлады. Кунаклар бер-бер чәйнәп йиде. Аннан соң әйттеләр:

— Ашамагыз! Бу куй ите түгел, этнең ите икән, — диде.

Кәнизәк йөгереп ханга килде, әйтте.

— Кунаклар ашамады, бу куй ите түгел, эт ите икән, — диде.

Хан, ачуы килеп, боларга килде.

— Ай, наинсафлар [ниинсаф, инсафсыз], — диде, — минем хәләл ашымны хәрам дипсез, куй итен эт ите дипсез, — дип орышты.

Болар әйттеләр:

— Безне орышмагыз, безләр акыл белән беләбез. Сез куй пастыкны [пастух, көтүче] сорагыз, безнең әйткән сүз рас булмаса, безне үлтерсәгез, ризабыз, — диде.

Хан куй пастыкны чакырып алды, сорады:

— Бүгенге суйган куй кайсы куйның баласы иде?

Пастык әйтте:

— Шул куйның әнисе үлгән икән, баласы ятим калды, имезергә куй юк булган өчен, бер канчык туган иде, ул канчыкка [ана эт] имезеп үстергән идек, — диде.

Аннан соң хан килеп, кунаклары белән ризалашып:

— Моны ничек белдегез? — диде.

Болар әйттеләр:

— Безләр бу иттән бер-бер йигән идек, күңлебездә бер-беребезне дошман тоттык, эт бер-берен сөймәде, анның өчен эт токымы кушылганын белдек, — диде.

Аннан соң хан өенә килде, кунакларга аш җибәрде, ашының алдында һәр даим нан җибәрер иде. Хезмәткәрләр нанны алып килеп, нанны биреп, тышкары чыгып тыңладылар. Болар әйтте:

— Бу хан хан баласы түгел икән, нан сатучының баласы икән, — диде.

— Үзе никахсыз туган икән, — диде.

Хезмәткәр ханга килеп әйтте.

Хан ачуланып кунакларга йөгереп килде.

— Сез мине зинадан булган икән, дип әйтепсез! — дип сүкте.

Болар әйтте:

— Сез безләрне сүкмәгез! Сезнең инәгез бармы? — диде.

Хан әйтте:

— Бар, — диде.

Болар әйтте:

— Бездән сорама! Инәңә барып сора! — диде.

Хан инәсеннән барып сорады:

— Әй, инә, безгә кунак килгән, бу кунак безне хан баласы түгел, нан сатарныкы баласы дип әйттеләр. Йә, инә! Әйт дөресен! Мине үзең таптыңмы, йә кешедән алып асрадыңмы?

Инәсе әйтте:

— Әй, балам, йөз егерме яшькә килдем, бер генә вакыт ялган әйткәнем бар, аннан үңкә [башка, бүтән] ялган әйткәнем юк. Мин бала күп таптым, бары да кыз булды. Бер көн айлы булдым. Бала табар вакытым булганда атаң сәфәр атланды. Анда шул вәгъдә белән йортына боерды: «Әгәр минем хатыным ул тапса, миңа сөенче ат чаптырыгыз! Әгәр кыз тапса, хатынны һәм кызны үтерегез», — диде. Ходаның әмре белән бер бала таптым, кыз булды.

Әҗәлдән куркып, бер нан сатарның зина кыла торган хатыны бар иде. Шул хатын бер ул тапты, шул улны үземә алдым. Үз кызымны шул нанчының хатынына бирдем. Син, балам, ул ул булдың, атаңа, үзеңнең тапкан улың, дип ялган сөйләдем. Син шул нанчының зина хатынының туган баласысың. Бу минем ялганым, гомремдә ялган сөйләмәгем шул. И, балам, моны ни өчен сорадың?

Хан әйтте:

— Килгән өч кунак әйтте миңа.

Инәсе әйтте:

— Әй, балам, шул кунаклар шулай йөрмәк сәбәбе ни икән, сора! Миңа кил! Йөз егерме яшемдә шул кунакларның җавабын ишетеп, аларга хөкем кылаем.

Хан кунакларга килеп, ризачылык сорап әйтте:

— Әй, кунаклар, минем нанчының һәм зина хатыныннан туганымны кайдан белдегез?

Кунаклар әйттеләр:

— Безләр акыл белән белдек. Һәр даим аш алдында нан бирәсең. Нанчының баласы икәнең шуннан белдек. Үзең хөкем кылып аермыйсың, тышкарыдан сүз тыңлатып эш кыласың, харамзадә икәнеңне шуннан белдек.

Хан әйтте:

— Әй, кунаклар, сезләр ни өчен болай йөрисез? Йөрмәк сәбәбегез ни иде?

Бу өч кеше әйтте:

— Безләр өчебез бер кешенең улыбыз. Безнең атабыз бик бай кеше иде. Атабыздан бер алтын кирпеч бар иде. Шул алтын кирпечне таңла бүлешербез дип куйганда, югалып китте. Шул кирпечне өчәвебездән үзгә кеше алган юк. Безнең беребез алды аны. Берәвебездән табылырмы икән, дип йөрибез, — диде.

Хан аннан соң инәсенә барды, әйтте. Инәсе әйтте:

— Бар, балам, шул кешеләрнең хәлен белер өчен бер өйгә кереп бер җиргә алтын-көмеш куй. Икенче җиргә кием-әсбап куй. Өченче җиргә ашап-эчеп йийә торган тәгамлар куй. Аннан соң һәр кайсысын бер-берләп чакырып, шул нәрсәләрне күргәз. Мынаки [менә] бу нәрсәләрнең кайсысын аласын әйт. Куш: алтын-көмешне ал! Булмаса, кием-әсбап ал! Булмаса, ашый торган тәгамларны ал! Кайсысын теләсәң, шуны ал! Шулай әйт! Аннан соң аны чыгарып, икенче берәвен чакырып шулай әйт! Өченчесен аннан соң тагы чакырып шулай әйт!

Хан чыгып кунакларга килеп әйтте:

— Кайсыгыз олы, кайсыгыз кече? Мин чакырсам әүвәл олыгыз килсен, аннан соң уртагыз килсен, аннан соң кечегез килсен! — дип боерды. Хан үзе чыгып бер һүҗрәгә [һөҗрә, бүлмә] кереп бер бүләк кылып алтын-көмеш салды, икенче бүләк кылып кием-әшия салды, өченче бүләк кылып, ашый торган тәгамлар, төрле җимешләр салды. Хан чакырды берәвен:

— Хуш, кунаклар, миңа риза булыгыз! Мин ничә көн сезне тотып рәнҗеттем, инде сезгә менә бу өч төрле нәрсәнең кайсысын кирәк булса, берәвен бирәем! Шул кеше кием-әшияны алды. Хан әйтте:

— Хуш, монда торсын!

Икенчене чакырды, икенчесе ашый торган төрле җимешне алды. Өченчесен чакырды, өченче алтын-көмешне алды.

Хан аннан соң инәсенә китте, инәсе әйтте:

— Кечесе алтын-көмешне алам дисә, алтын кирпечне шул урлаган

икән. Бер кеше бер тиен акча тапса, икәү булса икән, диер. Әгәр икедән ашып, ун булса тапканы, егерме булсын, дип уйлар, берем ун булса, уным йөз булсын, дип уйлар. Аның өчен бу кечесе, алтынны алтынга кушамын дип, алтынны алды. Теге икесе алтын-көмешне алмаган, атасы заманда кием кигән икән, ашка туйган. Боларның эшләрен бетереп, кечесеннән алтынны алып ризалаштырып җибәр! — дип әйтте инәсе.

Хан килеп боларга әйтте:

— Мин сезнең алтыныгызны табып бирәм. Сезнең кечегез кайсы? Шул кечегез бу алтынны алган.

Ул әйтте:

— Юк, мин алган юк!

Хан әйтте:

— Синнән үзгә алган юк. Син алдың. Дөресене әйт! Әйтмәсәң, зинданда җиде ел тотып, сигезенче ел үтерермен. Дөресене әйтсәң, агаларың белән ризалашсаң, өеңә кайтарырмын. Ахыры кечесе расын әйтте:

— Мин алтын кирпечне алып үз җиремдә җиргә күмдем, өйгә барып алып бирәем.

Хан боларның өчәвенә ат менгезеп, тун кигезеп, азыкларыны биреп өйгә җибәрде.

***Закирова Илсөяр Гамил кызы****,*
*филология фәннәре докторы,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*
*E-mail: ilzakirova@mail.ru*

УДК 398

***Д.Ш. Гыйльманов***

# СӨЕМБИКӘ ТУРЫНДАГЫ ФОЛЬКЛОР ӘСӘРЛӘРЕНДӘ МӘХБҮСЛЕК МОТИВЛАРЫ

Статья посвящена исследованию тюремных мотивов в татарском фольклоре. В данном случае анализируется баит «Тоткын Сөембикә җыруы» («Песня заложницы Сююмбики»).

**Ключевые слова:** татарский фольклор, образ царицы Сююмбики, мотив.

Халык иҗаты әсәрләрендә теге яки бу иҗтимагый чорга бәйле рәвештә тоткынлык темасы чагылыш таба. Моның мисалларын Казан ханлыгының соңгы ханбикәсе Сөембикәгә багышланган халык авыз иҗаты әсәрләрендә табарга була. Иң элек «Тоткын Сөембикә җыруы»на мөрәҗәгать итик. Аны, тарихи шәхес Сөембикәнең монологы, дияргә була. Җыр ике кисәктән тора. Беренчесендә ханбикәнең төрмәдәге аянычлы һәм авыр рухи халәте сурәтләнә:

Ничә еллар бу бинада
Ялгыз утыра башым,
Бер савыт су, бер телем икмәк —
Бәнем ашаган ашым
[Татар..., 1988, б. 40].

Хәсрәтле уй-фикерләргә, хис-кичерешләргә уралган Сөембикәнең якты дөньяны инде күптән күргәне юк, күзләре зәгыйфьләнгәннәр, күз яшьләре дә кипкән, корыган.

Төрмә темасына язылган җырларга хас булганча, ханбикәнең фаҗигасе контраст яссылыкларда — яктылык һәм караңгылыкка бәйле рәвештә яктыртыла, өмет белән өметсезлек мотивлары бергә килеп очраша:

Аһ, насыйб булырмы бәңа
Якты дөньяны күрү,
Әллә бу зиндан эчендә
Чыгармы газиз җаным
[Татар..., 1988, б. 40].

«Тоткын Сөембикә җыруы» — романтик эчтәлекле әсәр, чөнки аның үзәгендә Сөембикәнең эчке кичерешләре, хәтта аның аһ-зары космик масштабларга күчерелгән. «Дошманнары яккан хәсрәт утыннан аңа бөтен җир йөзе көйгән, янган кебек тоела» [Рәмиева, 130 б.]:

Катифәдәй яшел улып
Тора микән җир йөзе,
Яндырып бетердеме әллә
Аларны да дошманым
[Татар..., 1988, б. 40].

Җырның икенче өлешендә Сөембикәнең атасы Йосыф мирза йортында үткән күңелле, яшь вакыты, ханбикә булып Казанда яшәгән бәхетле еллары тасвирлана. Һәм шушы бәхетле-тәхетле дәвердәге тормышы коллык халәтенә дучар ителүенә, кара кайгысына каршы куела:

Алтыннар илә бизәлгән
Иде бәнем тәхетем.
Инде тәхетем улды хәзер
Шушы ултырган ташым
[Татар..., 1988, б. 41].

Татар халкында Сөембикә ханбикәгә атап чыгарылган бәетләр дә киң таралган. Аларда Сөембикәнең әсирлеккә төшү сәбәпләре инде шактый тирән, рус һәм татар дәүләте арасындагы дәүләтисәяси мөнәсәбәтләр яктылыгында аңлатыла. Бу болгавыр заманда

Мәскәү белән Казан арасындагы күңелсез хәлләр барысы да ил башлыгы Сөембикә йөрәге аша үтә. Акыллы патша буларак, ул руслар белән тыныч яшәргә тырыша; берничә мәртәбә, тынычлык солыхы төзик, дип, мөрәҗәгать итә. Әмма Явыз Иван җитәкләгән рус дипломатиясе Сөембикә тәкъдимен кабул итми, чөнки максат — сугышларны дәвам итү һәм сәүдә юллары өстендә утырган бай татар илен басып алу:

Казан — Мәскәү арасында
тагын бер сугыш булды,
Җиңелгәчтен казанлылар,
солыхка киңәш кылды.
Мәскәү соңгы солыхны
башкаларга яд кыйлган,
Мине Мәскәүгә озатуны солыхка
бер шарт кыйлган
[Татар...,1983, б. 31].

Мәскәүлеләр «якадан тоткач», яулап алу, кан кою белән куркыткач, тәхет тирәсендәге әле күптән түгел генә солыхка каршы булган төркем, рус патшасының авыр таләбенә буйсынып, бүгенгечә әйтсәк, «сепаратизмга» юл куя; Сөембикәне Мәскәүгә әсирлеккә озатып, Казан ханлыгын тынычлыкта калдырырга уйлый:

Казандагы түрәләр солыхка
кул куйганнар,
Мине Мәскәүгә озатып,
тыныч тормак булганнар.
Солыхтан соң илче килде
мине Мәскәүгә алырга,
Дәүләтемнән аерып мине,
горбәтлеккә салырга.
Ниндидер чара тәкъдиргә,
юктыр янда һич кешем,
Алындым мин хәбескә,
мөшкел булды һәр эшем
[Татар..., 1983, б. 31].

Ханбикә үзенең тоткынлыктагы газапларын, романтик шигъриятьтәгечә, тәкъдир кушуы буенча эшләнә, дип кабул итә. Алга таба бәеттә Сөембикәнең тоткынлыктагы кичерешләрен, күңел дөньясын ачуга зур урын бирелә. Ул үзенең тоткынлыктагы халәтен «үлмәгән җанлы үлекне ләхетләргә салу»га тиңли. Ханбикәгә багышланган тарихи җырлардагыча, әсирлеккә китү мәҗбүриятенә юлыккан Сөембикә өч көн буена канлы күз яшьләре коя, күзләренең нуры бетә, Сафагәрәй кабере янында такмаклап елау-сыктаудан телләре әйләнмәс хәлгә килә, хәлсезләнеп, тере үлеккә әйләнә. Хан сараендагы оркестрның йөрәк өзгеч елау көйләрен уйнап озатуы Сөембикәнең хәсрәтен тагын да тирәнәйтә. Шәһәрдәге елау-сыктау тавышлары кыямәт кубуны хәтерләтә башлый. Ханбикәне көймәгә утыртып алып китү, Казаннан мәңгелеккә аеру мотивы бәеттә аеруча тәэсирле бирелгән. Бәет тукымасына музыка культы кертеп җибәрелү, елау-сыктауларны «кыямәт кубу» белән чагыштыру, «мәңгелеккә аерылу» мотивын сурәтләү әсәрнең романтик яңгырашын бик тә көчәйтә.

Әле күптән түгел генә мөстәкыйль, имин яшәгән Казан ханлыгының фаҗигасе коточкыч. Бәйсезлеген югалткан Казан ата-анасыз калган, тамырлары өзелгән ятим бала белән тиңләштерелә.

Бәеттә азатлык һәм тынычлык сөюче Сөембикә образы күктәге ирекле кош, ә Россия һәм аның экспансив яулап алу сәясәте ерткыч карчыга образы белән символлаштырыла. Үзенең хөр дәүләтен, шәхси ирекен югалтуны аңлаган ханбикә акылсыз да, һушсыз да кала: ул коточкыч тетрәнү — катарсис кичерә:

Көймә китте кузгалып,
карчыгадай кошны алып,
Мин гарип-бичарадан
акылны алып, һушны алып.
Волгага чыкканда карадым мин
калага,
Калды җылап Казаным,
охшап үксез балага
[Татар..., 1983, б. 33].

Казаннан килеп төшкәч тә, Сөембикә чын мәгънәсендә төрмәгә — Мәскәүнең Кызлар мәйданындагы ун сакчы саклый торган бер йортка ябыла:

Күп заманнар баргачтын,
Мәскәүгә барып җиттек,
Бу бәхетсез башларга ни була? —
дип без көттек.
Кызлар мәйданы дигән
бер урынга илттеләр,
Бераз карап торгачтын,
безне йортка керттеләр.
Кергән йортка каравыл куйдылар
бер ун кеше,
Чыгармыйлар, йөртмиләр һәм
кертмиләр бер кеше
[Татар..., 1983, б. 31].

Ниһаять, ничәдер көн тоткынлыкта яткан Сөембикә улы Үтәмешгәрәй белән хан сараена китерелә һәм Явыз Иванның рәхимсез һәм катгый карарын ишетә:

Падишаһ та шунда үзе, миңа әйтә
бер сүзне,
«Балаң монда асыралыр,
иргә бирәм мин сезне»,
Диеп шунда баламны
кулымнан да алдылар,
Әсирлектә янган идем,
тагын утка салдылар.
Ишеттем мин, баламны
поплар алганнар, диеп,
Гакылы да юк сабыйны диннән
чыгаралар, дип
[Татар..., 1983, б. 33].

Бәеттә ханбикәнең дәүләтеннән, иленнән, җиреннән, газиз баласыннан аерылуы, бигрәк тә улын чукындыру кебек мотивлар куертылып, тирән психологизм һәм фаҗигалелек белән сугарылып, гиперболалар ярдәмендә көчәйтелеп сурәтләнгән.

Шул рәвешчә, бәетнең азагында күз алдына милләттәшләренең һәм дошманнарының җинаятькә тиң явыз адымнарыннан рәнҗегән, коллыкның котылгысызлыгын аңлаган, язмышына буйсынган, төшенкелеккә бирелгән, романтикларча сурәтләнгән фаҗигале Зат — Сөембикә образы килеп баса.

**Әдәбият**

*Рәмиева И.* Дөнья әдәбиятында Казан ханбикәсе Сөембикә образы: филол. фән. канд. ... дис. Казан, 2002. 262 б.

Татар халык иҗаты: бәетләр / томны төзүчеләр: Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, К.Б. Җамалетдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 352 б.

Татар халык иҗаты: тарихи һәм лирик җырлар / томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче И.Н.Надиров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 488 б.

***Гыйльманов Дамир Шәрифҗан улы****, филология фәннәре кандидаты,*
*Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының*
*татар теле һәм әдәбияты кафедрасы җитәкчесе*
*E-mail: DSG42@mail.ru*

УДК 329

*А.К. Бустанов*

# ИЗГЕ ШӘҖӘРӘЛӘР ҺӘМ ТӨНЬЯК ЕВРАЗИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ РЕГИОНАРА ЭЛЕМТӘЛӘРЕ: XVII—XX гасырларда Шиховлар гаиләсе тарихы

Статья рассматривает значение семейства Шиховых как потомков Пророка в широком контексте культурных и богословско-образовательных контактов мусульман среднего течения Сыр-Дарьи, Северного Казахстана, Тоболо-Иртышского междуречья и Турции; инструменты сохранения и распространения коллективной памяти этого большого клана, сумевшего сохранить свою особую идентичность до наших дней.

**Ключевые слова:** генеалогический нарратив, коллективная память, автохтонная идентичность, мусульмане России.

## Себердә Пәйгамбәр нәселе статусы

Бу мәкаләнең максаты, Сыр-Дәрьяның урта агымында, Төньяк Казакъстанда, Тобол-Иртыш елгалары аралыгында һәм Төркиядә яшәүче мөселманнар белән мәдәни, дини һәм дөньяви элемтәләр яссылыганнан чыгып, Мөхәммәд пәйгамбәр нәселе дәвамчысы саналган берничә буынны тоташтыручы Шиховлар гаиләсенең әһәмиятен билгеләү. Бу нәсел үзләренә генә хас сыйфатларын, коллектив хәтерләрен безнең көннәргә хәтле нинди юллар белән саклап кала алган соң? Ислам мәгарифе һәм регионара элемтәләр урнаштыруда алар нәселен дәлилләгән шәҗәрәләр нинди урын алып тора? Коллектив хәтер дигәндә, без социумның тәңгәллеген формалаштыручы үткәндәгеләрне күзаллаулар тупламын истә тотабыз [Privratsky, 2001]. Коллектив хәтер ул, беренче чиратта, нәселнең геннарда сакланып, буыннан буынга күчә барган сыйфатлары, йә булмаса, туганлык җепләренең телдән телгә күчә килгән башлангычы турында легендалар. Тәңгәллекне, элеккеге СССРның һәм бүгенге Россиянең сәяси картасында күрсәтелгәнчә, милли бердәйлек концепциясенә нигезләп карарга кирәкми. Безне генезис һәм Урта Азиядән Себергә күчеп килгән элитар төркемнәргә хас тәңгәллекнең үсеше кызыксындыра. XX гасырның бербер артлы булып узган ташкынлы сәяси вакыйгаларын кирегә әйләндереп, Россия империясендә яшәгән мөселманнарның тәңгәллек сыйфатлары мозаикасын күрәсе иде. Шул ук вакытта коллектив хәтер һәм тәңгәллек турындагы традицион күзаллауларның совет чорында һәм безнең көннәрдә ничек трансформацияләнүе кызыксыну тудыра. Милләтләр генераль концепция нигезендә тигезләнеп калды микән, әллә «рәсми булмаган», ягъни көнкүреш шартларында гына булса да сакланып калганнар иде микән.

Аерым гаиләләр язмышына багышланган кайбер мәкаләләрдә без бу теманы күтәргән идек инде. Ми-

нем Урта Азиядән Себергә күчеп килүче (Себер бохаралыларының) элитар төркемнәрне өйрәнүгә багышланган проектым Пәйгамбәр гаиләсе әгъзаларының (*садат, әшрәф*) һәм ислам изгеләренең (*әүлия*) дүрт категориясен колачлый.

1. Изге Сәет-Ата нәселе [Бустанов, 2010, с. 97—105]. Ул XVI гасырның икенче яртысында Көнбатыш Себердә нигезләнгән һәм ике тармакка — Айтикиннар һәм Имьяминовларга — аерылып, үрчеп киткән. Бу нәселләрнең икесе дә дәрәҗәле, затлы чыгышларына тәңгәл рәвештә сәяси өлкәдә дә, рухи яктан да абруй казанганнар; җир биләмәләре һәм сәүдә маллары ягыннан да зур байлыкка ия булганнар. Сәет-Атаның нәселе, Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Хөсәеннең дәвамчылары буларак, Себердә изгеләрдән саналганнар һәм *хуҗа, сәет* титулларын йөрткәннәр.

2. Изге Мәлик-Баба нәселе Шиховларга барып тоташа (бу мәкаләдә сүз алар турында бара). Шуны да истә тотарга кирәк, бу тармак Себердәге Сәет-Ата нәселенә бик якын тора, әмма Шиховлар, *шәех, сәет* титулларына ия булсалар да, беркайчан да *хуҗа* дәрәҗәсенә күтәрелә алмаганнар.

3. Изге Исхак-Баба нәселе дә, бу регионга Сәет-Ата тармагы белән бер чорда күчеп килгәнлектән, алар белән тыгыз бәйләнештә була [Бустанов, 2012, с. 473—535]. *Хуҗа* титулына да ирешәләр, ләкин аларда да, Пәйгамбәр гаиләсе әгъзалары булып саналмаганлыктан, *сәет* дәрәҗәсе булмый. Бу гаиләнең мөһим роле шунда, алар Себердә исламның сакраль географиясенә нигез салалар. Бу нәселнең бер вәкиле — Шарбати шәех — Себергә Урта Азиядән исламлаштыру турында риваять алып килә, ул бу җирлектә дә таралыш таба. Әлеге нәсел вәкилләре шулай ук Шихов фамилиясен йөртәләр, әмма алар Мәлик-Баба белән туганлыкта түгел.

4. Йан-Хуаджа (Җан-Хуҗа) гаиләсе. Аларның килеп чыгышы турында тулы мәгълүматлар юк. Дәрәҗәләре ягыннан алда әйтеп үтелгән тармаклардан калышсалар да, 1692 елдан Тобол якларында гомер кичергән бу нәсел хуҗа титулына ия була. Ф.Т. Вәлиев архивында бу гаиләнең кыскача тарихы (татар телендәге кульъязманың күчермәсе) (1883 елгы), шулай ук Янхуҗиннарның гаилә архивында документлар тупланмасы сакланган. Статуслары һәм титуллары ягыннан бу нәселләргә якын торган башка гаиләләр дә бар, ләкин алар турында мәгълүматлар әлегә җитәрлек түгел.

Бу мәкаләдә XVII гасыр ахырында һәм уртасында Сайрамнан Тара шәһәренә күчеп килгән шәехлар нәселләре турында гына сүз бара. Укучылар игътибарына Себердә һәм Төркиядә яшәүче Шиховлар нәселенә кагылышлы фарсы, гарәп һәм төрки телләрдә язылган кульъязмалардан ачыкланган тикшеренү нәтиҗәләре тәкъдим ителә. Бу материаллар безнең тарафтан Шиховларның нәсел дәвамчылары күпләп яшәгән Омск өлкәсендә (Большереченский районы, Үләнкүл авылы), Казакъстанның көньягында (Сайрам һәм Төркестан шәһәрләре), Төркиянең Конья шәһәрендә һәм Богруделик авылында 2008—2012 елларда тупланды. Телдә әле дә булса сакланып килгән бу тарихи риваятьләрне, традиция нигезендә төзелгән шәҗәрәләрне Үләнкүл авылы тарих укытучысы, җирле төбәкне өйрәнүче М.Х. Шихова (1928—2008) гомере буе җыеп барган.

### «Хөсәенов шәҗәрәсе» һәм абруйлы изге гаиләләр

Шиховлар гаиләсе турында галим-суфи Мөхәммәд-Мансур Шихов тарафыннан язылып, 1908 елда Оренбургта басылып чыккан «Хусаинова родословная шайха Сайиид-Баттала бине Давлет-Бакы аш Шайхи» дигән әсәрне алар хакындагы беренче хезмәт дип исәпләргә буладыр мөгаен. Шәҗәрә «Хөсәиния» дип атала. Аның шулай исемләнүе Шиховлар токымы вәкилләренең үз чыгышларын Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Хөсәен бине Гали бине Әбү Талиб (626—680) белән бәйләүдән килә булса кирәк [Прозоров, 1991]. Мондый фараз нигезендә Шиховлар Мөхәммәд пәйгамбәрнең турыдан-туры дәвамчылары булып чыга. Инде әйтеп үтелгән Айтикиннар һәм Имьяминовларның нәсел башы изге Сәет-Атага барып тоташса, Шиховларда бу урын изге Мәлик бабага бирелә. Чыганакта бу хакта болай язылган: «Сайиид шах авлийа‘ Малик-Баба в 750 году с добровольцами Кемал-Хусайна прибыл из степей Арабистана в Достопочтимую Бухару. После этого в награду и царскую милость бухарские государи указали потомкам шаха авлийа‘ Малика-Бабы быть правителями в городе Сайраме. С тех пор потомки шаха Малика-Бабы стали главами и правителями сайрамского народа: [но] калмыки разрушили этот город. Тогда Сайрам стал внутренней крепостью [Кокандского ханства], а [потомки Малика-Бабы] нашли приют у престола правителя Коканда сайиида Мухаммад-‘Али хана . Затем он (хан) царской милостью и наградой вновь даровал потомкам упомянутого шаха Малика-Бабы судейство, пост муфтия и прочие состояния и достойные чины» [Аш-Шаджара…, 1908].

Югарыда сөйләнгән вакыйга дөреслеккә шактый якын тора. Әйтик, бу чыганакны беренче тикшереп өйрәнгән этнограф Ф.Т. Вәлиев аңлатканча, калмыклар тарафыннан Сайрамны басып алу эпизоды тарихи мәгълүматларга туры килә, һәм ул 1684 елда Рабтан җитәкчелегендә була [Валеев, с. 1—3]. Урта Азиядә ислам тәгълиматын таратучыларның берсе булган Мәлик-Баба (‘Абдул-Мәлик-Баба) суфичылык юнәлешенең үзәк персонажы Йәсәви (Занги-Ата) шәҗәрәсенең башында тора. Бу хакта С.Н.Абашин менә нәрсә яза: «Согласно одной из версий, его [Занги-Ата] отец — Тадж-хваджа, ученик Ахмада Йасави. Отцом Тадж-хваджи был «святой» шах (шайх) ‘Абд ал-Малик-Баб или падшах Малик (ум. в 1218 г.): известны по крайней мере две его могилы — в Сайраме, где мавзолей был построен в XV в., и в Долине р. Ахангарон. Отец шайха ‘Абд ал-Малик-Баба — «святой» Мансур-Ата (ум. в 1197 г.), который по преданию, был первым муридом Ахмада ал-Йасави. В свою очередь, Мансур-Ата — сын первого учителя Ахмада ал-Йасави — Арслан-Баба (Баб-Арслан)» [Абашин, с. 151]. Кызганыч, Шиховларның «Хөсәиния» шәҗәрәсендә бу чылбыр күрсәтелмәгән, әмма Йәсәвиләр мирасына басым ясалганы сизелеп тора. Американы ислам белгече Девин Девиз, архив һәм башка мәгълүматларга нигезләнеп, түбәндәгеләрне ачыклый: Мәлик бабаның улы — Мир-‘Али-Баба-сәйед, аның уллары — хуҗа Насрулла Фарса һәм хуҗа Фәтхулла

Мәҗзуп (каберләре әтиләренеке белән янәшә дигән мәгълүмат та бар) [DeWees, 2000, p. 281]. Бу исемнәр (Фәтхулладан кала) Шиховларның нәсел шәҗәрәсе вариантларында да бар. Шәҗәрәләрдәге түбәндәге сәяси вазгыять үзенчәлекләренә дә игътибар итәргә кирәк: Мәлик-Баба токымы вәкилләренә Сайрамда хакимлек итүне Бохара әмире тапшыра, ник дисәң, бу нәсел Сайрам Галим ханның (1799—1899) Коканд гаскәрләре тарафыннан басып алынган вакытында яңа хакимгә карата лояльлек күрсәтәләр; ул заманда кулланылган «аксөяклеккә имтихан» барышында, Галим-ханның күп кенә нәселләрнең чыгышына шик белдерүенә карамастан, алар Пәйгамбәр нәселе титулын саклап кала алалар.

Алга таба шәҗәрәдә болай диелә: «Из потомков упомянутого шаха Малика-Бабы — ʻАввас-Бакы б. Хызыр-Бакы-шайх: [Ему в голову] пришли высокие и чистые мысли, [чтобы] в подтверждение и укрепление исламской веры и в распространение блестящего священного шариʻата по доброй воле прибыть из города Сайрама в Российское государство, в область Сибири. Они обосновались в крепости Тара и ее окрестностях. От упомянутого ʻАввас-Бакы-шайха родилось четыре сына: ʻАлим-шайх, ʻИшки-шайх, Баба-шайх и Файзи-шайх» [Аш-шаджара…, 1908, с.24].

1905 елның 1 гыйнварында Тусказань авылы [Омск өлкәсенең Большереченский районы) имамы Габдел-Хәким бине Хәйр Аллаһ Уфадагы дин галиме Ризаэддин Фәхретдингә хат яза, анда ул Шиховлар нәселен нигезләүче Аббас-Бакының, сәүдә итү максаты белән, Себергә килүен хәбәр итә [Архив востоковедов…]. Шиховларның финанс куәтләре төрле чыганакларда күрсәтелгән. Шулай ук аларның дини даирәдә өстенлекле статуска ия булулары да шик тудырмый. Бу инде Сайрамнан дәвам итеп килә һәм аларны Айтикиннар белән тыгыз элемтәгә этәрә (бу гаиләләр арасында никахлаштыру еш күренеш булган; чыганаклар бу ике нәселнең үзара конкурентлыкта яшәүләрен дә дәлилли [Bustanov, 2014, p. 20]. Хәер, Шиховлар үзләренең икътисади статусын законлаштыру өчен үткәннәрен изгеләштерергә һәм уйдырма шәҗәрәләргә барырга да мөмкиннәр. Башка материллардан аңлашылганча, матди омтылышлар кулдан шәҗәрәләр төзү традициясе белән бик нык бәйләнгән була [DeWeese, 1999, p. 507—530].

Аббас-Бакы бине Хызыр-Бакы шәех Сайрамнан Тара шәһәре янына килеп төпләнә. Шәҗәрәнең төп нөсхәләрендә аның төгәл датасы күрсәтелмәгән [Селезнев, 2009, с. 49]. Шулай да чыганаклар аның вакытын һәм вакыйгалар урынын ачыкларга өмет уята. Беренче чиратта, җирле халык биргән мәгълүматларда Аббас-Бакының Тара шәһәре янындагы Речапово авылына күчеп килүе ачыкланды, ә бу авылның Шихово буларак танылуы да очраклы түгелдер (ул татарча «шыклар», ягъни шәйех сүзеннән русчалаштырылган). Бу хәл XVII гасырның икенче яртысында һәм XVIII гасырда була: әлеге нәселдән барысы да диярлек (хәтта күрше авыллардан) Аубаткан һәм аның тирә-ягындагы авылларга күчеп киләләр. Гаиләнең җир милке дә тиз җайлана. Аббас-Бакының уллары шактый гына җир-суларга, урманнарга хуҗа булалар [Государственный архив Омской обл.; Корусенко, 2009, с. 98—102].

«Хөсәиния» шәҗәрәсендә түбәндәге генеалогик чылбыр китерелә:

Фәйзи шәйх — Мирза шәйх — Фәйзулла шәйх — Дәүләт-Бакы шәйх — ‘Абдулла шәйх һәм Хәсән шәйх.

Абдулла шәйхнең нәселе: Сәййид-Баттал шәйх, Мөхәммәд-шаһ шәйх, Абу-Бәкер шәйх. Хәсән шәйхтән Йосыф шәйх туган. Мөхәммәд-шаһ шәйхтән Габдел-Галәм шәйх, Мөхәммәд шәйх, Зөл-Карнәйн шәйх, Шаһзадә шәйх туган.

Абу-Бәкер шәйх нәселе: Мөхәммәд-Мансур шәйх, Мөхәммәд-Насыйб шәйх, Мөхәммәт-Рази шәйх, Мөхәммәд-Рәхим шәйх, Зәйнел-Габидин шәйх, Синанеддин шәйх.

Шәҗәрә ахырында аны төзеп бетерү датасы — 1899 (милади) елның 5 августы язылган. Барлык китерелгән мәгълүматлар да дөрес: шәҗәрә иясе — Аубаткан авылы мулласы Сәййид-Баттал бине әл-мәрхүм Дәүләт-Бакы Шихов — Аббас-Бакы шәех нәселе вәкиле, бохаралы һәм асыл Мөхәммәд пәйгамбәр нәселенә (*шәриф ән-насаб*) карый, дип тәмамланган. Шәҗәрәне түбәндәге затлар раслаганнар: Сәет Хәмзә бине сәет Мостафа ‘Атайа-ал-Мәдәни (?), имам Габдулла әфәнде, имам хаҗи Габделхаликъ ‘Имададдинов, Зайсан шәһәре (Көнчыгыш Казакъстан) имамы Әхмәд-Зәки бине Әхтәм. Болардан тыш Бохара, Хива, Коканд, Ургәнч һәм Сайрам шәһәрләренең галим-голәмасы һәм хакимнәре дә бу шәҗәрәне раслап үз имзаларын һәм мөһерләрен куйганнар [Аш-шаджара…, с.26]. Әмма бәян итү бик зур күләмле булганга, ул кыскартылган, шунлыктан без бу чыганакта күп кенә зыялы затларның исем-имзаларын, мөһерләрен күрмибез, нәтиҗәдә кайберләүләрдә текстның дөреслегенә шик туа.

Басылып чыккан шәҗәрәдә Сәййид-Баттал шәйхнең үзе турында кыскача биографик белешмә бирелгән (күрәсең, әлеге документның хуҗасы ул булган). Ул 1840 елда Тобол губернасының Тара өязенә кергән Аубаткан авылында туган. Хәзер ул авыл юк инде. Сәййид-Баттал, үсә төшкәч, гыйлем эстәргә Җиде Пулат (Семипалатинск) шәһәренең Габделҗәббар хәзрәт мәдрәсәсенә юнәлә, анда өч ел буе бик тырышып дини фәннәр һәм әхлакны өйрәнә. Өйләнеп, шунда ук берничә елга яшәп тә кала. Китап басылып чыкканда (1910 елда) Сәййид-Батталга 70 яшь була. Шәҗәрәнең ахыры шактый үзенчәлекле: «Учителя (Сайййд-Баттала) в *тарикате*: справедливый Халил-ишан из деревни Турбин Тобольской губернии и знаменитый устаз Зайнулла-ишан». Хәлил-ишан (1866—1931) үзе дә Зәйнулла Рәсүлинең (1835—1917) укучысы була [кара: Бустанов, 2013, с. 77—79]. XX гасыр башында Хәлил-ишанга Тара шәһәреннән мөридләр килү Торбы авылы мәдрәсәсенең Көнбатыш Себердәге көчле суфичылык үзәкләреннән булуын раслап тора.

Шәҗәрәне әзерләп бастыручы Мөхәммәд-Мансур Шихов үзе турында болай ди: «Я родился в 1881 году в упомянутой деревне Аубаткан, в 17 лет отправился в Семипалатинск к Сайййд-Баттал-мулле Шихову, у которого учился пять лет, потом два года учился в городе Петропавловске у ‘Абд ал-‘Азиз-хазрата. Сейчас уже четвертый год как я занят приобретением знаний в медресе хазрата Хайруллы ‘Усманова в городе Каргалы» [Аш-шаджара…, с. 28; Риза ад-Дин…, 1897; Frank…, 1780—1910, p. 118—119].

Әлеге мәгълүматлардан аңлашылганча, Шиховлар нәселенең казакъ далалары дини үзәкләре Пе-

тропавловск, Җиде Пулат (Семипалатинск), Зайсан һәм күренекле Зәйнулла шәйх җитәкчелек иткән ислам мәгарифе үзәге Троицк белән тыгыз элемтәдә яшәве ачыклана. Санап үтелгән шәһәрләрдә, шулай ук Павлодарда себер галимнәренең һәм суфиларының булуы, аларның Себергә барып йөрүе бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән. Павлодарда Шиховларның мәһабәт итеп салынган вәкиллеге әле дә булса саклана, җирле мәчетне сәүдәгәр Айтикиннар үз хисапларына салдырган булганнар, шунда ук аларның йортлары да тора. Петропавловскиның Бохарада белем алган имамы Әхмәд ишан бине Кызыл-Мөхәммәд бине Габдеррәзак бине Ишмөхәммәд бине Тимер-Гали 1860 (1855 яки 1856 дип тә әйтәләр) елда вафат булып, Себернең Тара шәһәрендә җирләнгән. Ул анда туганмы-юкмы, анысы билгесез, әмма язмышы аны гомере ахырында Тарага китергән, шунысы да мәгълүм: аның бабалары чыгышы белән Казан яны бистәләренең берсеннән [Qurban-Ali…, 2005, p. 5; Materials…, 2001, p. 15]. Танылган дини тәгълиматчы, төрки, гарәп, фарсы телләрендә берничә дистә хезмәтләр авторы Абу-Хәнифә Рәхмәтуллаһ бине Йосыф әл-Йангурази унбиш ел дәвамында Тара мәчетенең имамы булып тора, шунда ук мөдәррислек итә, ә 1884 елдан Петропавловскида алтынчы мәчетнең имамы вазыйфасын башкара, шул шәһәрдә мәрхүм була. Төмән янындагы Ембай авылыннан чыккан сәүдәгәр Кармышаковларның да язмышы Җиде Пулат (Семипалатинск) һәм казакъ далаларындагы башка шәһәрләр белән тыгыз бәйләнгән. Себердә ислам галимнәре күтәрелеп чыгуда казакъ дини үзәкләренең әһәмиятен дәлилләгән мисалларны күпләп китерергә мөмкин; икенче яктан, себерлеләр үзләре дә ул төбәкләрдә сәүдә эшләре җәелдереп җибәрү белән кызыксынганнар.

Шушы уңай белән казакъ һәм татар суфи-галимнәренең үзара элемтәләрен чагылдырган кайбер фактларга киңрәк тукталып узу урынлы булыр. Инде исеме атап үтелгән Габделҗаббар бине Гобәйдулла безгә 1911 еллар тирәсендә Корбангали Халиди әл-Айагузы әл-Чавчаш (1846—1913) төзегән биографияләр сүзлегеннән таныш. Ул сүзлектә болай диелә: «…этот человек, видимо, происходил из деревни Муслим Чистайского уезда. Сначала он учился в Казани, в медресе Мухаммад-Карима, затем, после нескольких лет жизни в Бухаре [Курбан-‘Али…, 1910], переехал в Семипалатинск и стал имамом и мударрисом (преподавателем) восьмой мечети. В его время его медресе процветала; туда стекались ищущие знания со всей округи, и они изучали [науки] вплоть до «Таузиха». Поскольку он был бесподобен в науке чтения Корана (*‘илм-е к’ыира’ат),* те, кто хотели стать хафизами, получили от него пользу. Имамы, мударрисы и халифа в разных местах являются его учениками. Он был имамом более 20 лет и умер в Турции в 1881 по милади во время возвращения из хаджа, да будет над ним милость Аллаха» [Qurban-‘Ali…, p.50—51]. Мөселман галимнәренең икенче бер биографы Әхмәт-Вәли бине Гали әл-Казани (1833—1901) болай дип яза: «мишар мулла ‘Абд ал-Джаббар б. ‘Убайдуллах изучал науки в Бухаре и читал книги о суфийском пути *(сулук).* Однажды он возвращался [на родину] из Бухары через Семипалатинск. Когда он оказался в Семипалатинске, то женился на дочери

муллы Хусам ад-Дина, преподавал там несколько лет в медресе, стал указным имамом, получил указ. Когда мулла Хусам ад-Дин умер, он стал имамом-хатыбом и мударрисом. [...] Во времена муллы ‘Абд ал-Джаббара [мечеть] была прекрасным местом для учебы». «После смерти муллы ‘Абд ал-Джаббара начались распри и очень неприятные скандалы, в результате которых имамом в мечети стал некий ‘Абд ал-Хак, происходивший из Тюмени» [Materials for…]. Әхмәд-Вәли әл-Казани бу юлларны язганда ул имам булган.

Мөхәммәд-Мансур Шиховка дини белем биргән мөдәррисләрнең берсе — Габделгазиз хәзрәт турында без икенче кызыклы чыганактан — Галимҗан Барудиның (1857—1921) «Кызылъяр сәфәре» дигән юлъязмаларыннан укый алабыз. Баруди язганча, Тамбов губернасының Аджи авылыннан чыккан Габдел-Газиз бине Мостафа Бегиш әфәнде Петропавловск мәчетенең, исәп буенча, икенче имамы булган. Ул башта туган авылы мулласы Сәйфетдин Галим-байдан белем алган, аннан соң Бохарада дамелла Габдулла мөфтидә укыган. Гомеренең соңында нәкышьбәндиләр бердәмлегенә кушыла, 1910 елда вафат була [Галимҗан, 2004, б. 96—97].

**Коллектив хәтерне тапшыру**

Ризаэддин Фәхретдиннең Санкт-Петербургта сакланган архивында тагын бер мөһим чыганак бар. Ул да булса, Кузат авылыннан мулла Фәхретдин бине Габдулла дигән затның XIX гасыр ахыры — XX гасыр башына караган исемлегендәге Шиховлар шәҗәрәсе [Архив востоковедов…, Ф.131]. Тел ягыннан караганда бу шәҗәрә өч өлештән тора: гарәп-фарсыча бирелгән кереш, фарсыча язылган төп өлеш һәм татар телендәге өстәмә. Документ читләре ерткаланган, өчкә бөкләнгән (күрәсең, почта белән җибәрү өчендер) 22,5x35 см үлчәмле саргаеп беткән кәгазь битеннән гыйбарәт. XIX гасырда эшләнгән кәгазь, су билгеләре, штемпеле юк. Аскы уңъяк почмагына СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты Ленинград бүлеге архивының мөһере (зәңгәр төстә) сугылган. Кәгазь битенең бер ягына гына 19 юлдан торган текст язылган. Текстка,ияләренең исемнәрен күрсәтеп, аларның мөһерләренә охшатып эшләнгән сигез үрнәк өстәлгән. Бераз астарак Ризаэддин Фәхретдин кулы белән карандаш ярдәмендә бу кәгазь битенең Кузат авылы мулласы Фәхретдин бине Габдулладан алынуы турында язылган. Уңнан — 3 см, сулдан 2 см бушлык калдырып, гарәп (настáлик) почеркында кара төстәге кара белән текст башлана (текст автор язганча рус телендә бирелә. — *Ред.*)

Фарсыча язылган

1. Во имя Аллаха Милостивого, Милосердного! Во имя Аллаха — имена. *И Он на каждую вещь способен . Он достаточен для меня и прекрасный покровитель.*

2. Истинное восхваление принадлежит Господу, который является причиной собственного правления. Скажи: «О *Аллах, обладатель власти»*, а печать — доказательство всех его приказаний. Скажи: *«Каждая вещь*

3. *погибает, кроме Его Лика».* Пахота — в его распоряжении. *А посевы растишь ты или мы сеем!* Все

наши молитвы лишь о его Милости. *Мы пробили в земле благородный источник.*

4. Благословение Пророку, чей высокий ранг — в его пророчестве. *Я был Пророком, а Адам был между водой и глиной.* Зерна посеяны горечью его Послания. *И мы послали тебя не иначе, как милость*

5. *для миров.* Благословление и добрая молитва за Него (Пророка) и все его семейство и всех его чистейших сподвижников. Сказал Пророк, да пребудет с ним мир: «Я — город высокого знания, врата которого — место рождения

6. Шах-и Мардана, да будет доволен им Аллах Всевышний», в Ка‘абе; а имя ему было ‘Али, Муртаза и Хайдар, а кунья его — Абу-л-Хасан, а имя его отца — Абу Талиб, а имя

7. матери их — Фатима, дочь Асада; а один из его сыновей — имам Хусайн, а его сын — имам Зайн ал-‘Абидин, а его сын —

8. имам саййид Бакир, а его сын — имам Джа‘фар Садик, а его сын — имам Муса Казим, а его сын — саййид ‘Али Рази (=Риза), а его сын —

9. саййид имам Наки, а его сын — имам Таки, а его сын — имам Хади, а его сын — саййид Хасан ‹Аскари, а его сын —

10. саййид Ахмад, а его кунья — Абу-л-Касим; а его сын — саййид Фазил, а его сын — Ибрахим, а его сын — саййид Фат[и]х,

11. а его сын — саййид Са›ид, а его сын — саййид Махмуд, а его сын — саййид Хайдар, а его сын — саййид Аджалл (=Аджил?), а его сын —

12. саййид Асалл (=Асил?), а его сын — саййид Ахмад, а его сын — саййид Шах-и Авлийа Малик Баба, [да будет] над ним мир и благоволение! — а его сын —

13. Мир ‘Али Баба, [да будет] над ним мир; его усыпальница — возвеличенное место; а его сын — Шайх Насрулла Парса, а сын

14. его — саййид Хаджи-шайх, а его сын — саййид Ахмад-шайх, а его сын — Мир-шайх, а его сын — Кочкар-шайх, а сын

15. его — Хизр-Баки-шайх. а его сын — ‘Авваз-Бакы-шайх. У ‘Авваз-Бакы-шайха четыре сына

16. было: Файзи-шайх, Баба-шайх, ‘Алим-шайх покойный, ‹Ишки-шайх, а ещё у Баба-шайха — Зайн ад-Дин-шайх;

17. его сын — Тадж ад-Дин-шайх, его сын — Хиз-Баки-шайх, его сын — ‘Абд Аллах -шайх, его сын — Фахр ад-Дин-шайх,

18. его сын — Шайх Камалиддин-шайх.

Текстка өстәлеп бирелгән мөһер ияләренең тулы исемнәре:

1. Габиджан казый бине Газизләҗан хаҗи
2. Мулла Йоныс Мөхәммәд мөфти бине Нигъмәтулла
3. Мәхмүд хаҗи мөфти бине Хан хаҗи
4. Әмир баба бине мулла Мир-Байрат кари мөфти
5. Мөхәммәдхан мөфти бине Йонысхан
6. Ишан Әгъләм мулла имам
7. Мөхәммәдша Бадал мөфти Әгъләм бине Шаһмөхәммәд Әмин
8. Кази калан Гайсә хуҗа бине мәрхүм Йоныс хуҗа

Охшатып кына эшләнгән мөһер үрнәкләре һәм татар телендә язылган өстәмә (15—18 юл) бу язма чыганакның дөреслеге бик үк югары дәрәҗәдә түгеллеген күрсәтеп торса да, андагы мәгълүматлар М.Х.Шихова тарафыннан Төркиядә Габбас-Бакы дәвамчыларыннан язып алынган «Прекрасное древо» дип атал-

ган хезмәттәге исемнәргә, нигездә, туры килә. Эш шунда ки, архив материалларыннан аңлашылганча, бу фамилиянең күпчелек вәкилләре Аубаткан авылында яшәгән, 1908 елда алар Госман империясенең Конья вилаятенә күчеп китәләр һәм анда моноэтник Ришадиййа (соңыннан ул Богруделик дип атала) авылына нигез салалар. Һиҗрәт кылуның коточкыч авырлыкларына карамастан, алар үзләре белән нәсел чылбырларын раслаучы грамоталарын һәм туган якларына багышланып иҗат ителгән хезмәтләрен дә алалар. Һәм ул очраклы булмый. XIX гасыр ахырында Шиховларның бер вәкиле Габделҗаббар бине Мөхәммәди, үзләрендә сакланган шул грамоталарга таянып, кенәзлек хокукын (абруен) торгызу өчен Санкт-Петербургка юл ала. Ләкин ул бу эшен ахырына җиткерә алмый, вафат була [Риза ад-Дин…, 1909]. Шәҗәрә тексты бу төркемнең Урта Азия чыгышын раслау өчен генә түгел, ә өстенлеккә хокукларын торгызуга да теге яки бу дәрәҗәдәге дәлил булып хезмәт итә.

Шиховлар вәкилләре Төркиядә яшәгәндә үзләренең элгәрләренең берсе булган Әхмәт Ясәвине дә онытмыйлар. Гәрчә моны дәлилләүче язма документларның әлегә хәтле табылганы булмаса да, югарыда контекстта искә алынган Йәсәви шәех Шиховларның ыру башы булуы ихтималын раслый [Bustanov, 2014, p.96—93].

Конья вилаяте (Төркия) Богруделик авылының элеккеге башлыгы Аднан Чыңгызда (1950 елда туган) Шиховлар нәселе шәҗәрәсенең тагын бер варианты саклана. (2010 елның җәендә ул мине үзенең өенә чакырып, бик җылы каршылаган иде.) Ул гарәп телендә язылган, әмма, бераз үзгәртеп, фарсычадан тәрҗемә ителгән булса кирәк. Кулъязма җыелма, 18 биттән тора. 21х32 см үлчәмле картон тышлыкта. Форзацларның икесенә дә төрек телендә дәфтәрнең Коньяда эшләнүен белдергән мөһер сугылган. Дәфтәрнең гомуми күләме сызыклы 85 биттән гыйбарәт. Текст 1949 елда Истанбулда төзелгән. Кара төстәге кара белән фарсы (рика‘) почеркында язылган. Коръән өземтәләре үзгәртелми, алар арасында, даими булмаса да, еш кына пунктуацияләр (җөмләләр арасында нокталар) очрый (*текст автор язганча рус телендә бирелә*).

1. Призываю к помощи Аллаха от шайтана проклятого. Во имя Аллаха милостивого, милосердного.

2. Он достаточен для меня и лучший покровитель.

3. Хвала Аллаху, который *не родил и не был рожден, и нет Ему равного или подобного* . Благословление и мир

4. Лучшему творению, нашему господину и Пророку Мухаммаду и его семье — тем, кого мы поминаем в каждой молитве.

5. Господи, благослови Мухаммада и его семью и ниспошли свою милость Мухаммаду, его семье и сподвижникам,

6. Тем, кто следовал истинному пути и [потому] был счастливее. Воистину, генеалогическая наука (‹илм ан-насаб) является причиной воссоединения отдельных частей.

7. И сказал Аллах, Благословенный и Всемогущий: *«О люди! Мы создали вас мужчиной и женщиной и сделали вас народами и племенами, чтобы вы познавали друг друга»,* а также в хадисе сказал Пророк:

8. «Познавайте, чтобы умножать (свои знания) и молитесь, чтобы

улучшать ваши отношения [с Аллахом и с людьми]». Воистину, лучшая из родословных — родословная Пророка,

9. Да благословит и спасет его Аллах. Сказал ‘Умар ал-Фарук, да будет доволен им Аллах, слышал, как Пророк, да благословит и спасет его Аллах,

10. сказал: «Все отношения (родственные, дружеские связи) в День Суда не будут действительны, кроме Его причин и Его связей. Сказал ‘Умар ал-Фарук,

11. да будет доволен им Аллах.

12. Когда я посватался к дочери ‘Али, да возвеличит его Аллах, Умм Гульсум и женился на ней, Пророк, да благословит и спасет его Аллах, сказал: «Я — город знания, а ‘Али — его врата». Место рождения ‘Али —

13. Преславная Ка›ба, а его прозвище *(лакаб)* — Муртаза и Хайдар, а кунья — Абу-л-Хасан. Имя его отца — Абу Талиб,

14. А имя его матери — Фатима бинт Асад. Его супруга — дочь Посланника Аллаха, да благословит и спасет его Аллах, Фатима.

15. От нее родились ал-Хасан и ал-Хусайн, и упомянутая Умм Гульсум. Имам Хусайн родился от имама ‘Али.

16. От Зайн ал-›Абидина родился имам Мухаммад ал-Бакы, от него родился Джа‘фар ас-Сиддик. От него родился Муса Ка[зым].

17. От него родился имам ‘Али Риза. От него родился имам Такы. От него родился имам Накы. От него родился имам Хасан ‘Аскари

18. и саййид Джа‘фар, а кунья его Абу ‘Абдуллах. От него родился саййид ‘Али. От него родился саййид ‘Абдуллах. От него родился саййид Рази

19. От него родился саййид Махмуд. От него родился саййид Мухаммад. От него родился саййид Джа‘фар. От него родились саййид ‘Али, саййид Джалал ад-Дин,

20. От него родился саййид Ибрахим. От него родился саййид ‘Абд ал-Фаттах. От него родился саййид Са‘ид. От него родился саййид Махмуд. От него родился

21. Саййид Хайдар. От него родился саййид Аджал. От него родился саййид Асал. От него родился саййид Ахмад. От него родился саййид шах авлийа Малик-

22. -Баба, да будет над ним Его милость и довольство. От него родился саййид Мир-‘Али-Баба, да будет над ним Его милость и место упокоения *(маркад)* пусть будет почитаемо. И саййид Рази Аллах

23. Парса. От него родился Хаджи. От него родился саййид Ахмад. От него родился саййид Мир-шайх. От него родился саййид Кучкар-шайх. От него родился саййид Хызыр-Бакы

24. От него родился саййид ‘Аввас-Бакы-шайх. Ему наследовали эти четыре сына:

25. Саййид Файзи-шайх, саййид Баба-шайх, саййид ‘Алим-шайх, саййид ‘Ишки-шайх. *Их было четыре брата.*

Изге шәҗәрәләр өстен хокуклы гаилә вәкилләре тарафыннан XVII гасырда Сыр-Дәрьяның урта агымы төбәкләреннән Көнбатыш Себергә, соңрак, XIX—XX гасырларда Төньяк Казакъстанга һәм Госман империясенә озак вакытлы күченү тарихы дәвамында язылганнар. Бу күченүләрнең сәбәпләре төрле булган, әмма аларның уртаклыгы Мөхәммәд пәйгамбәр дәвамчылыгын раслаучы аерым статус билгеләрендә һәм Сыр-Дәрья буендагы шәһәрләрдә яшәгән изге затлар турындагы легендаларда чагыла. Себер Евразиясе регионнарына күчә барган изге нәсел вәкилләре җирле элита белән актив аралашалар һәм

шул җирлектәге дин әһелләреннән ислам белеме алып, алар арасында үз урыннарын таба баралар. Мондый очракларда шәҗәрәләр Пәйгамбәр белән туганлыкны дәлилләү чарасы гына түгел, ә бу илаһи динне таратучылар чылбырын дәвам итүчеләр дә булып торалар. Шәҗәрәләр текстлары, җирле шартлардан чыгып, төрлечә чагылыш таба: Коканд ханлыгында уздырыла торган «аксөякләр өчен имтиханнар» яңа режимны яклаучы элитаны сайлауга хезмәт итә, XVIII—XIX гасырларда Көнбатыш Себер бохаралылары җир биләмәләренә ия булу хокукына омтылалар, Омск өлкәсенең Үләнкүл авылында яшәүчеләр себер-татар милли бердәмлегенең структур өлешен раслаучы генеалогик чылбыр дәвамчылары сафында булуны өстен күрәләр, ә Төркиянең Конья вилаятендәге Богруделик авылындагылар өчен ерак Себердән күчеп урнашучылар кабиләсе бердәмлеге төп маркер булып санала. Бу юнәлешләрнең икесе дә бер гаилә нәселенә генә караса да, ул нәселнең генеалогия тарихы төрлечә яктыртыла һәм яңа социаль функцияләрне үти.

## Әдәбият


*Bustanov A.K.*, «Notes on the Yasawiya and Naqshbandiya in the 17th — early 20lh Centuries,» in: Niccolo Pianciola and Paolo Sartori (eds.) Islam. Society and States Across the Qazaq Steppe (18th- Early 20lh Centuries). Wien, 2013. P. 69—93.

*Bustanov A.K.*, «The Sacred Texts of Siberian Khwaja Families. The Descendants of Sayyid Ata,» in: *Journal of Islamic Manuscripts* 2 (2011).

*Bustanov A.K.* ‘Abd al-Rashid Ibrahim‘s Biographical Dictionary on Siberian Islamic Scholars // Kazan’ Islamic Review. 1/2014. P. 20.

*DeWeese D*. Sacred History for a Central Asian Town. Saints, Shrines, and Legends of Origin in Histories of Sayram, 18th-19th Centuries // Figures mythiques des mondes musulmans (Revue des mondes musulmans et de la Mediterranee, 89—99), ed. Denise Aigle. Paris, 2000. P. 281).

*DeWeese D.,* The Politics of Sac-red Lineages in 19n-century Central Asia: Descent Groups Linked to Khwaja Ahmad Yasavi in Shrine Documents and Genealogical Charters // International Journal of Middle East Studies, Vol. 31, No.4 (Nov. 1999). P. 507—530.

Materials for the Islamic History of Semipalatinsk, 29 (English translation), 54 (facsimile of Tatar manuscript).

Materials for the Islamic History of Semipalatinsk: Two Manuscripts by Ahmad-Wali al-Qazani and Qurban-‘Ali Khalidi, ed. by A.J. Frank and M.A. Usmanov, Berlin, 2001, 15. Баруди Г. Кызылъяр сафаре. Казан. 2004

*Privratsky B.* Muslim Turkistan: Kazak Religion and Collective Memory (Richmond, 2001).

Qurban-‘Ali Khalidi. An Islamic Biographic Dictionary of the Eastern Kazakh Steppe, 1770—1912, ed. by A.J. Frank and M.A. Usmanov, Leiden, Boston, 2005, 5, footnote 6.

Qurban-’Ali Khalidi, An Islamic Biographic Dictionary, 50—51 (English translation), 132—133 (Tatar text).

*Абашин С.* Занги-Ата // Ислам на территории бывшей Российской империи. Энциклопедический словарь. Т.1. М, 2006. С. 151.

Архив востоковедов Института восточных рукописей РАН. Ф. 131. Ризаэддин Фахретдинов. Оп.1. Д.8. Л. 11-12. Родословные д. Тусказань.

*Ахметзянов М.* Татарская археография. Отчеты о результатах археографических экспедиций (1972—2010 гг.). Часть 2. Казань, 2011. С. 136.

Аш-шаджара ал-хусайнийа ли-ш-шайх Саййид-Баттал б. Давлет-Бакы аш-Шайхи. Оренбург, 1908.

*Бабаджанов Б.М.* Кокандское ханство: власть, политика, религия. Токио-Ташкент, 2010.

*Бустанов А.К.* Книжная культура сибирских мусульман. М., 2013. Мир'ат. 17. Казан, 1903. Б. 7.

*Бустанов А.К.* Рассказ об Исхак-Бабе и наследие святых семейств в Западной Сибири: предварительное обсуждение // Исламизация и сакральные родословные в Центральной Азии: наследие Исхак Баба в нарративной и генеалогической традициях. Алматы, 2012. Том I: Открытие пути для ислама: рассказ об Исхак Бабе, XIV—XIX вв. отв. ред.: Девин ДиУис, А.К. Муминов. С. 473—535.

*Бустанов А.К.* Фамильная хроника сибирских саййидов: Шаджара рисаласи (текст, перевод, комментарии) // Ислам в современном мире. №1-2 (13-14). 2009.

*Бустанов А.К., Корусенко С.Н.* Родословные сибирских бухарцев: Имьяминовы.

*Валеев Ф.Т.* Родословные записи (шэжэрэ) сибирских татар как историко-этнографический источник // Проблемы антропологии и исторической этнографии Западной Сибири. Омск, 1991. С. 103.

*Галимҗан Баруди.* Кызылъяр сәфәре. Казан, 2004. Архив востоковедов Института восточных рукописей РАН, Ф. 131. Ризаэддин Фахретдинов. Он. 1. Дело 5. Л. 70а.

Государственный архив Омской области. Ф. 183. Оп. 1. Д. 3. Л. 14, 17.

*Корусенко С.Н.* Землевладение и землепользование бухарцев в Сибири: генеалогический ракурс // Известия Алтайского государственного университета. История. 2009. № 3 (64). С. 98—102.

*Прозоров С.М.* ал-Хусайн // Ислам: Энциклопедический словарь. М., 1991. С. 285.

Риза ад-Дин б. Фахр ад-Дин. Са'ид. Казань, 1897; Frank A.J. Muslim Religious Institutions in Imperial Russia. The Islamic World of Novouzensk District and the Kazakh Inner Horde, 1780—1910 (Leiden, Boston, Koln),

*Селезнев А.Г.. Селезнева И.А., Белич И.В.* Культ святых в сибирском исламе: специфика универсального. М., 2009. С. 49.

Мәкалә «Сокральные семейства сибирских мусульман: конец XVI — начало XXI вв.» гранты (РГНФ № 13-31-01011/*al)* кысаларында язылды.

***Әлфрид Кашшаф улы Бустанов,***
*Санкт-Петербургтагы Европа университетының*
*тарих факультеты профессоры*

УДК 929

***Л.Ф. Байбулатова***

# РИЗАЭДДИН ФӘХРЕТДИННЕҢ «АСАР»ЫНДА МӨФТИ МӨХӘММӘДҖАН ХӨСӘЕНОВ ШӘХЕСЕ

В публикации представлена биография первого муфтия Оренбургского магометанского духовного собрания Мухаммаджана Хусаинова из свода «Асар» Ризаэддина Фахретдина. Особый интерес в его жизнеописании представляют фетвы, написанные самим муфтием, а также различные обращения к нему от высокопоставленных лиц и мусульман округа ОМДС. Фетвы муфтия, составленные на персидском языке, публикуются на кириллице впервые.

**Ключевые слова:** Оренбургское магометанское духовное собрание, муфтий, Мухаммаджан Хусаинов, «Асар», Ризаэддин Фахретдин, фетва.

Р. Фәхретдиннең 4 томлы биобиблиографик «Асар» җыентыгында X—XX гасырларда Идел—Урал территориясендә яшәгән һәм төркитатар мәдәнияте үсешенә өлеш керткән 733 шәхеснең тәрҗемәи хәлләре бәян ителгән. Автор бу хезмәтен милләтенә күпмедер файда китергән шәхесләрне халкы белеп торсын, гыйбрәт алсын өчен теркәп барган. Алар арасында дин әһелләре (мөфтиләр, казыйлар, имамнар, ишаннар һ.б.), мөдәррисләр, язучылар, шагыйрьләр, галимнәр, сәүдәгәрләр бар. Әмма «Асар» биографик мәгълүматлар җыентыгы гына түгел, тулаем алганда, ул — төркитатар халыкларының рухи мәдәнияте тарихын чагылдырган хезмәт. Китапка кереп калган мәдрәсә-мәктәпләр, китаплар исемнәре нигезендә төркитатарлар арасында мәгърифәтнең ни рәвешле таралуын, дәрәҗәсен ачыклап була. Шулай ук тәрҗемәи хәлләрдәге шигъри әсәрләр, шәхси хатлар, кабер ташъязмалары һ.б. тикшеренүчеләр өчен әле дә актуаль. Гомумән алганда, «Асар» тарихчылар, әдәбиятчылар, телчеләр өчен бай чыганак булып тора.

Җыентыкның жанрына килгәндә, мондый типтагы әсәрләр урта гасырлар гарәп-мөселман әдәбиятында популяр булган, ләкин Риза Фәхретдин аларны кабатламаган, бары тик ул идеяне һәм тәрҗемәи хәлләрне урнаштыруның хронологик тәртибен генә үрнәк итеп алган. Үз ягыннан төрле чыганаклар файдаланып, мөмкин кадәр объектив тарихи-биографик хезмәт язарга тырышкан. Тегә яки бу шәхеснең тәрҗемәи хәлен тарихның бер бите дип санаган, галим шәхесләрнең тормыштагы тискәре якларын да яшермәгән, чөнки ул аларда әхлакый тәрбия мөмкинлекләрен күргән. Р.Фәхретдин фикеренчә, тарих язганда хаталарны яки кешенең начар сыйфатларын яшерү тарихны бозуга китерә.

«Асар»ны язу өчен автор төрле документаль һәм нарратив чыганаклар куллана. Чыганакларның төп өлешен Р. Фәхретдин Оренбург Диния нәзарәтендә эшләгән вакытта туплый башлый, алга таба, Оренбургта «Шура» журналының мөхәррире вазифаларын башкарганда, ул журнал укучыларыннан үзен кызыксындырган шәхесләр турында материаллар соратып ала. Әлбәттә, Ш.Мәрҗанинең «Вафийәтел-әслаф», «Мөстәфадел-әх-бар» хезмәтләрен дә кулланмыйча кал-

мый. Беркадәр материал шул вакытта чыга торган татар милли матбугатыннан да җыела. Диния нәзарәтенең эш кәгазьләре (журналлар, хисаплар, гарызлар), шулай ук ревизия кенәгәләре, метрика, формулярлар, кабер ташъязмалары текстлары, колофоннар һәм фотографияләр автор өчен мәгълүмат чыганагы була. Әмма тәрҗемәи хәлләр, нигездә, нарратив чыганаклар (хәтирәләр, истәлекләр, шәхси хатлар, шәҗәрәләр, тарихи хезмәтләр) ярдәмендә язылган.

Авторы исән вакытта «Асар»ның беренче һәм икенче томнары дөньяга чыга (1900—1908 елларда: беренче кисәге — Казанда, II се — Оренбургта), өченчесе 1911 елның февралендә, типографиягә озатылыр алдыннан, конфискацияләнә, дүртенчесен бастырып чыгарырга галимнең өмете беткән була инде, беренчедән, хезмәтне чыгарырга акчасы да булмый, икенчедән, хәзерге заман укучыларына аның хезмәтенең кирәге дә юк, дип уйлый Риза казый. Ләкин, шуңа да карамастан, ул үзенең эшен дәвам итә һәм 1929 елда, күңелен юатыр өчен булса да, «Асар»ны, яңа материаллар өстәп, күчерә башлый. Җыентыкның басылып чыккан өлешләре дә укучыларга тулы вариантта килеп җитмәгән була. Ул вакыттагы китапларны бастыру таләпләре буенча кульъязма цензор аша узып, беренче томның кереш сүзе шактый кыскартыла: цензор В.Д.Смирнов керешнең төрки-татарларның язма чыганаклары сакланмавы, милли тарихны торгызу турында язылган өлешен тулысынча диярлек сызып ташлый[1]. Ләкин, шуңа да карамас-тан, китап үзенең укучысын таба, китапны һәм авторны ошатучылар, мактаучылар, тәнкыйтьләүчеләр дә табыла. Галимне хуплаучы укучылар бүтән шәхесләрне алда эшләнәчәк өлешләргә кертүне сорап язалар, «Асар»ны өнәп бетермәүчеләр исә, китаптагы шәхесләрнең, бигрәк тә руханиларның, тискәре якларын күрсәтмәскә кирәк иде, диләр.

«Асар»га кертелгән дини руханилар арасында әһәмиятле урынны мөфтиләрнең тәрҗемәи хәлләре алып тора. Китапта Мөхәммәдҗан Хөсәеневтән башлап Галимҗан Барудигә[2] кадәр булган мөфтиләрнең тормыш юллары яктыртылган һәм башка руханиларга караганда аларның биографияләре тулырак бирелгән. Андый игътибар, беренчедән, Р.Фәхретдиннең аларны мөселманнарның хокуклары сагында торучылар итеп күрүе белән аңлатыла; икенчедән, Диния нәзарәте архивында мөфтиләрнең биографияләренә кагылышлы материаллар тупланган була: тәрҗемәи хәл турындагы рәсми һәм рәсми булмаган мәгълүматлар, төрле истәлекләр, шәхси һәм эш хатлары. Автор аларның эшчәнлекләрендә һәм көндәлек тормышларындагы, уңай һәм тискәре якларын күрсәтү белән бергә, кайбер гамәл-гадәтләренә карата үз фикерен белдерә, ләкин мөфтиләргә тулы бәяләмәне бирүне, гадәттәгечә, укучыларга калдыра.

Бу хезмәттә укучылар игътибарына Р.Фәхретдин хезмәтеннән мөфти Мөхәммәдҗан Хөсәеновның тәрҗемәи хәле хәзерге татар теленә якынлаштырып тәкъдим ителә[3]. Аның биографиясендәге үз кулы белән язган фәтвалары мөһим урынны алып тора. Беренчедән, алар бик аз сакланган, икенчедән, аларның эчтәлеге мөфтинең ни рәвешле эш алып баруын, аның шул чор хөкүмәте белән мөнәсәбәтләрен, Мәхкәмә-и шәргыя Ырынбургыяның кул астындагы мөселманнарның

үтенечләрен, мөрәҗәгатьләрен ничек үтәүләрен күпмедер дәрәҗәдә ачыкларга ярдәм итә. Беренче карашка, әлеге хөкемнамәләрдә мөселманнар өчен гадәти хәлләр тасвирланган. Мәсәлән, мәчет төзекләндерү, никах рөхсәт итү һәм раслау, тагын да тирәнрәк китсәң, шул чор мөселманнарының көндәлек тормышлары, аларның динилиге, мөфтинең шәригатьтән читкә тайпылмавы, шул ук вакытта патша хөкүмәтенең таләпләрен ничек үтәү күренә. Мөфтинең 1—8 нче хатлары (фәтвалары) фарсы теленнән Р.Т. Йөзмөхәммәтов тарафыннан тәрҗемә ителеп, хәзерге татар телендә беренче тапкыр бирелә.

## Мөхәммәдҗан бине әл-Хөсәен бине Габдеррахман

Русия дәүләтендә Educational Диния нәзарәтендә[4] иң беренче мөфти булган зат. 68 яшьләрендә 1239 ел, 2 зөлхиҗҗә, пәнҗешәмбе көн (милади илә 1824 ел, июнь 17 көн. Русча басылган юбилей рисаләсенең 40 битендә матбага хатасы буларак июнь язылган) Уфа шәһәрендә вафат булып, үзенең васыяте буенча, Уфадан 60 чакрым кышкы кояш чыгышы ягындагы Атҗитәр[5] авылы каберлегендә күмелгән.

Элек Сәгыйдь вә Оренбург ягында гыйлем алып, Мөхәммәд бине Гали әд-Дагыстаныйдан да файда күргән. Соңрак Бохара вә Кабул якларында бер кадәр сәяхәт иткән вә гыйлем туплау теләге белән дә йөргән. Риваятьләргә күрә, Бохарада Гатаулла бине Һади, казый Торсынбакый бине Габдеррәхим һәм башкалар белән аралашкан, Кабулда шәех Фәезхан бине Хозырхан сохбәтендә [*дуслыгында*] булган. Камил булмаса да, бу сәфәрендә фарсы телен дә өйрәнгән.

Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Бу мәмләкәткә кайтканнан соң үзенең тырышлыгы вә яхшы иҗтиһады сәбәпле» Русия дәүләтенең олысына вә кечесенә мәгърифәт пәйда итеп, Русиядән вәхшәт вә буйсынудан нәфрәт иткән казакъ вә башкорт вә башка таифәләрне кызыктыру вә куркыту илә буйсындыру хосусында юл күрсәтүче мәэмүр [*чиновник*] булды, үзенең таләбе яки башка бер сәбәп илә Диния нәзарәте оештырылгач, биредә башлык һәм мөселманнарның мөфтие итеп билгеләнә. Гаять зур ышыныч казанган бер зат булганга, мәсҗид салырга рөхсәт иткәндә яки берәр кеше хакында «фәлән урынга лаек» дип бер кәгазь язып мөһер сугып биргәндә, сүзе үтә торган булган. Мондый ышаныч, әлбәттә, арзан төшмәгәндер, казыйларны хезмәтчеләре урынына тотып, нинди эш булса да әмер итә торган булган, теләгән кешеләрен казыйлык вазыйфасына чакыра торган булган. Ахыр гомерендә казыйлар арасында абруе шактый төшкән, казыйларының инкяр вә бәхәсләре сәбәпле, Нәзарәтнең хөкемнамәләре прокурор карамагына җибәрелгәннәр. Муллаларга исем сатып, күп дәүләт туплаган. Атабыз Баһаведдин вә Фәтхулла ахун, Байморад бине Мөхәррәм әл-Мөлкәри һәм башкалар моның камиллеген вә гыйлеме күплеген раслыйлар, ләкин язган риваятьләре вә язу рәвешләре, һич шөбһәсез, зәгыйфь вә сүзләре дә бозык, моннан башка фарсы гыйбарәләре дә гыйлеменең азлыгына вә булдыксызлыгына дәлилдер. Бу фәкыйрь Фәтхулла ахуннар дәрәҗәсеннән күп түбән бу-

лып, хәтта Габдессәлам мөфти дәрәҗәсендә булуы да шөбһәледер», — дигән.

Диния нәзарәтендә 1815 ел белән расланган тәрҗемәи хәлләр (*формулярный список*) кәгазендә бәйан ителгәннәргә күрә, бу елда мөфти хәзрәтләре илле җиде яшендә булган (ягъни 1171/1758 ел ахырында дөньяга килгән буладыр). Мирзаәхмәд исемле улы 19 яшендә булып, Петербургта чит диннәрне карый торган мәхкәмә хезмәтендә булган.

Мирзашаһбик 10 яшендә, Мирзаҗан 6 яшендә булган. Вә башка рәсми кәгазьләргә күрә, Мөхәммәдҗан мөфти сәүдәгәр кавеменнән булып, бишенче ревизия[6] хисабына күрә, Уфа ягындагы Хәрәмабад (Солтанай)[7] авылына караган булган. Әүвәлрәк иностранный коллегиядә хисап ителеп, соңрак Оренбургта офицерлык хезмәтендә булган. 1785 елның 9 июлендә чик комиссиясендә кыргызлар өчен ахун булып, соңрак, 1789 елның 22 сентябрендә, Диния нәзарәтендә җитәкче вә мөселманнарга мөфти булган. Мөфти булганга кадәр кыргызларның Русия дәүләтенә буйсынулары хакында зур хезмәте булып, Кавказ якларына барып, Русия әсирләрен азат иттергән вә кабарты [*кабардин*] таифәсен Русия кул астына керүгә ант иттергән. Әстерханнан көнчыгыштагы төрекмәннәр арасында сәяхәт итеп, Русиянең абруен күтәргән. Бу хезмәтләре өчен Русия дәүләтеннән бүләкләр алган. Императрица Екатерина вә император Павел бине Петр җәнабеннән бриллиант илә зиннәтләнгән медаль вә Оренбург шәһәрендә казнадан бер йорт вә моннан башка төрле вакытта күп акчалар вә киемнәр бирелгән.

Мөфти хәзрәтләренең тәрҗемәи хәлләреннән әүвәлге өлеше безгә караңгы. Кешеләр Бохарадан килеп мөдәррис булулары вә Кабулдан кайтып шәехлек иткән хәлдә, ни сәбәпкә нигезләнептер ки, бу зат Бохара вә Кабулдан килеп офицер булган, диләр. Фәлсәфә тарихы гыйлеме илә шөгыльләнгән затлардан берсе бу кешенең Бохара вә Кабулда ислам гыйлемен камил үзләштерү өчен йөрми, бәлки әүвәл эштән Русия тарафыннан җибәрелүен вә сәясәткә бәйле эшләр белән шөгыльләнеп көн кичерүе турында фикер йөртә. Хакыйкатьне Аллаһы җәнаблары белер. Мөфти булгач, тормышын бик тәкәллефле [*ясалмалы*] сурәткә куеп, кием-салым, ат вә туннары, зиннәт вә бәһале нәрсәләре булганнар икән. Шәһәр урамында дүртәр ат җиктереп, дәрәҗәсен белеп йөри торган булган. Никадәр генә бәхет кояшы тәмам югары күтәрелеп бетсә дә, ахыр гомерендә дәрәҗәсе тәмам бетеп, халык арасындагы абруе сүнгән. Вә дөньяның мәртәбәсендә карар, байлыгында да рәхәт вә ныклык юклыгын, бәхете сүнеп баруын күреп, вафат булуы сөйләнә. Алтыны, хисапсыз хайваны, йортлар вә җиһазлары, Уфа ягындагы башкортлардан юк кына бәяләр бәлән алынган ничә урыннардагы җирләре мирас булып калган. Бары Атҗитәр авылындагы җире дә 2284 дисәтинә булып, моны исә гаять арзан хак илә Үршәк буендагы Мирас авылы башкортларыннан алган.

Мөфти хәзрәтләренең Гайшә исемле бер хатыны үзеннән алда вафат булган. Риваятьләргә күрә, элек Русия илә Төркия арасындагы сугышларның берсендә әсир алынган төрек кызы булып, башта Казан шәһәрендә Исмәгыйль бине Апанайда никахта булып, Исхак вә Хәбибҗамал исемле балалары туган, ә Исмәгыйль вафаты соңында

мөфтигә никахланган вә 79 яшендә 1209/1795 елда Казанда вафат булып, ике бистә арасындагы зиратта җирләнгән.

Кәримә исемле хатынының туган җире Кара диңгез буендагы Анафа шәһәре икән. Мөфти вафат булганнан соң, кызы Фатыйма янына китеп, Җиһангир хан тәрбиясендә дөнья кичереп, вафат булган диләр.

Суфия исемле хатыны чиркәс кызы булып, 1172/1759 елда дөньяга килгән. Мөфтинең угыллары бу хатыннан. Мөфти вафат булгач, Атҗитәр авылындагы милекләрендә тереклек иткән вә һәр әгъзасы тәмам сәламәт хәлдә, 110 яшенә җитеп, 1866 елның 2 мартында вафат булган, мөфти төрбәсе вә мөселманнар зиратыннан төньякка таба бер чакрым сахрада бер түбә өстендә җирләнгән.

Мирзаәхмәд, мал туздырып, бөтен гомерен, һичбер эшсез, Анфиска дип танылган бер рус кызы илә кичергән. Үз милкендәге йортында (мөфти хәзрәттән мирас булып калган йортта) әлеге хатын илә бикләнеп ятуы вә кайсыбер вакытта Уфа шәһәренә барып-килеп йөрүе билгеле. Аңардан дүрт- кызы булып, Д... исемле кызының балалары Уфа шәһәрендә күп, кайберләренең хосусый буларак, маҗаралары да сөйләнә. Мирзаәхмәднең (Мирзакайның) мөфти хәзрәтләреннән мирас итеп алган милке вә җирләре шушы мөселман булмаган дүрт кызына калган. Шулай ук анасы Суфия шушы дүрт кызга 500 дисәтинә җирен вафатына кадәр үк мәхкәмәләрдә яздырып тапшырган.

Ләкин Күди[8] башкортларында булган җирләре халык илә тоташтан ничә еллар дәгъва ителгәннән соң, мөфти хәзрәт варисларына түгел, бәлки башкортлар милкенә кире кайтарылган. Ләкин башкорт халкының бу дөнья йөзендә булган бөтен әмәле вә ахирәттә дә файдасын күрү өмете илә калган ихлас гамәле туфрак (җир) сату булганга, Мөхәммәдҗан мөфтидән кайткан җирләрен Күди башкортлары тиз көндә немецләргә, латышларга шалкан илә шырпы бәһасенә сатылачак вә яки сатылгандыр.

Мирзаәхмәднең кабере анасы Суфия кабере илә янәшә булып, өсләрендә таш вә ихата-фәлән юк. Боларның болай бер тарафта күмелүләренең сәбәбен, Атҗитәр халкы илә даими низаг белән торганга, әлеге авыл халкының үз каберлекләренә күмдерергә риза булмаулары, диләр. Шуңа үз җирләренә күмелгәннәр икән. Болар үлгән вакытта мондый бер васыять тә булуы ихтимал.

Әмирҗан исемле угылы Оренбургта гаскәри хезмәттә булып, офицер иде. Якынча 1850—1860 елларда вафат булган. Үзеннән бер хатыны[9] илә Хөсни исемле бары бер кыз баласы калды. Хатыны Бикмәй фамилиясеннән Гайса мирза исемле берәүгә никах ителде. Мөхәммәдҗан мөфтидән калган китапларның бер өлеше шушы хатын аша әлеге Гайса мирза милкенә күчүе сөйләнә.

Фатыйма исемле кызы казакъ вә Бүкәй иле[10] ханнарыннан Җиһангир хан бине Бүкәй хан никахында булып, Ибраһим, Әхмәд, Гобәйдулла исемле угыллары; Зөләйха, Хәдичә исемле кызлары дөньяга килгән.

Мөфти хәзрәтенең дөрес бәхетле вә үзенең дә хәер илә исеме хәтердә калуына сәбәпче баласы шушы Фатыйма булган диләр. Чөнки барлык туганнарыннан аермалы буларак, гаять диндар, тәкъва, инсафлы, гакыллы, уйлап эш итүчән бер хатын булып, ханның мәхәббәтен

җәлеп иткән вә ханның үзен тәрбия иткән кебек, бөтен Бүкәй иленә мәдәният керүенә сәбәп булган. Казакъ гаиләләренә шәхсән үзе гореф-гадәтләренең гүзәл булганнарын өйрәткән, ә исламга туры килмәгәннәрен кире каккан, тәһарәт вә пакьлеккә аеруча зур игътибар биргән. Хан хатыны булып барганнан соң, Бүкәй иле белән Оренбург, Уфа вилайәтләре арасында килеп-китеп йөрү халык арасында таралу белән арада бөек бер дуслык вә танышлык пәйда булган. Казакъларның дәүләтлеләренең угылларын үз байлыкларыннан, мохтаҗ вә фәкыйрьләрнең балаларын үз кесәсеннән чыгым тотып, Эстәрлетамак вә Эстәрлебаштагы мөселман мәдрәсәләренә җибәреп укытканнар. Бүкәй илендә бу көндә булган могтәбәр галимнәр һәм танылган мөдәррисләр әлеге ике мәдрәсәнең вә аларны тәрбияләгән шәехләрнең тәрбия җимешләреннән. Җиһангир ханның мәсҗид салдырып һәртөрле ыруг вә кабиләләргә имамнар билгеләве вә аларга рәсми сурәттә хокук кәгазе биреп, мәхәллә балаларын укыту вә сабыйларга борынгылардан калган исем бирү нәтиҗәсендә танылуы шушы хатынның уйлап эшләве белән булган.

Мөфти хәзрәт хөкем астында калып, зур җәфалар чиккән вакытында вафат булдымы, юкса болай бәлаләрдән азат буларак, эштән бушанып, гыйлем туплый алыр идеме? Бу турыда ачык мәгълүмат юк.

Бу җирне акка күчергән вакытта махсус Атҗитәр авылына бардым. Юл буенча мөфти хәзрәтнең китап илә тулы китапханәсенә керермен, нинди китаплары бар икән, Бохара, Кабул якларыннан китергән борынгы әсәрләрен карар идем, төрле галимнәр вә бөекләрдән килгән хатларны укырмын вә монда карарсыз файда вә мәгълүмат туплармын, дип барган идем. Ләкин баруыма хәрабәгә әйләнеп баручы бер төрбәдән башка һичбер әсәр вә билге күрмәдем.

Баш очындагы зур таш гүзәл рәсем илә батырып язылган. Иң әүвәл юлы түгәрәкләнеп язылган аять шәрифеннән гыйбарәт булып, аннан соң шушы тугыз юл бар:

1. Һуәл-хәллак әл-бакый [*ул — Яратучы, ул — Мәңгелек*]
2. Әл-мәрхүм, әл-мәгъфур [*ярлыканган*]
3. Шәйхел-ислам вәл-мөслимин мөфти
4. Әл-әнам Мөхәммәдҗан
5. Бине Хөсәен
6. Әл-Болгарый тәваффа [*вафат*] фи
7. 1239 фи бруҗ [*йолдызлык*]
8. әл-мизан [*1824, сентябрьдә*] рухына
9. фатиха.

Сигезенче юлдагы мизан, минем уемча, дөрес түгел. Чөнки мөфтинең вафаты мизан/сентябрьдә түгел, әсәд/июльдә, бу исә рәсми кәгазьләр белән беркетелә. Бәлки таш мизанда язылганга шулай бирелгәндер.

Кирпечтән төзелгән бинасы, яңартылмаганга, бик искергән, вә тиз көннәрдә харап вә вәйран булачагы ап-ачык.

Мөфти хәзрәтләренең хәл вә тормышы тикшерелгәндә гыйлеменә нисбәтле гакылы артык вә мәгърифәтенә күрә дәрте зур булуы аңлашыла. Сөйләргә осталыгы вә кыюлыгы аркасында, гыйлем өлкәсендәге кимчелеген пәрдәләтмичә, хәтта ки, башкортлардан үзен бөек гыйлем иясе дип инандырырга муафыйк булган. Якыннарыннан берәү халык арасында мөфтинең карендәше икәнлеген белдерүенә каршы мөфти хәзрәтләре: «Юк-

ны сөйлисең, мөфтинең һич карендәшеме булыр?..» — дип әйткәне мәгълүм. Бу сүзеннән максаты — каза вә хөкем маддәләрендә мөфтинең һич дусты вә карендәше булмас дию, һәрникадәр мөфтилек хезмәтенә күрә бөек бер сүз булса да, беркадәр сәбәбе бар. Әмма үзен олы күреп, башкалардан өстен уйлап сөйләвендә, иң һәлакәтле бер фикер илә бәхетсезлеккә дучар булуы ачык күренә. Ислам фикер иясе Ибне Рөшд (Аллаһының рәхмәте булсын) тәрҗемәсеннән язучылар бер хикәя китерәләр. Ул Мөхәммәдҗан мөфтинең биредә сөйләнгән хәленә туры килә. Ибне Рөшд хәзрәтләре солтан Ягъкуб әл-Мансур илә тәкәллефсез сөйләшү мәртәбәсенә ирешкән бер вакытта солтанга мөрәҗәгать итеп: «Карендәшем!..» — дигән. Бу сүз падишаһларга һич мөнәсәбәтле булмаганга, мәҗлестәге вәзирләрнең йөзләре бозылуын күреп, солтан да: «Дөньяда дус вә карендәш булу нигъмәтеннән солтаннар мәхрүм, ләкин мин андый мәхрүм падишаһ вә солтаннардан түгелмен, чөнки минем дустым бар. Ул исә Ибне Рөшд», — дип җавап биргән. Инде Фас падишаһының дусты булган хәлдә, Русиядә мөфти булган затның карендәше ни өчен булмасын!..

Мөфти хәзрәтнең русчага гаять тә маһир бер зат булуын сөйләсәләр дә, имзалар сакланмаган.

Уфа шәһәрендә яшәгән урыны үзенең милке булып, Телеграфный илә Пушкин урамнарының көнчыгыш почмагында булган. Аның йортлары агач булганга, Уфа шәһәрендәге янгыннар вакытында юкка чыккан вә аның җиренә таш бина салынган. Ихтималга күрә, Диния нәзарәте дә үз биналарының берсендә булган.

Язган хөкемнамәләрен күрү өчен зур тырышлык сарыф ителеп, табу җиңел булмады. Фәкать сигез хаты вә моннан әүвәлге дүртесе үз язуы илә, хәтта ялгышларын үз хәлендә калдырып, биредә китерелә.

*Беренче хат.*

Имамнар әйткәнчә, Тимербай авылында бер ничә ел буена биш мәчет булган, шул мәчеттә һәрвакыт биш вакыт намаз үтәлгән. Ләкин җомга намазын һәм гаетне рөхсәтсез үткәрмәгәннәр, чөнки бу авыл янында җәмигъ мәчете булмаган. Бу мәчетне закон буенча төзергә һәм әлеге мәчеттә җомга намазы һәм гает уздырырга дип, әлеге Тимербай патшазадәдән рөхсәт сорады. Мәчетне үз чыгымнарына салырга дип, җавап килде. 1805. Мөфти, казыйларның иң мәшһүре, Болгар шәһәрендә ахунд Мөхәммәдҗан бине Әмир Мөхәммәд әл-Хөсәйни әл-мөтәвәккил (*мөһерендә булган тарихы ачык аңлашылмады, бәлки 1190 дыр*).

*Икенче хат.*

Имамнар әйткәнчә, Эстәрлетамак ягында Мәрсәк авылында яшәүче мөселманнарның почтасы бар, ләкин биш вакыт намаз гыйбадәте вә дога өчен бер мәчет, шулай ук бу авыл тирәсендә бер фәрсәх аралыкта (6—8 км) җәмигъ мәчете юк. Шуңа күрә сотник Баем Илбулды углы биш вакыт намаз өчен мәчет төзекләндерергә дип, законлы рөхсәт сорады. Шәригать вә хәнәфи мәзһәбе нигезендә, миннән, исемем түбәндә бирелгән мөһердә күрсәтелгән, биш вакыт намаз өчен мәчетне төзекләндерергә дип, рөхсәт вә фәтвә бирелде, чөнки бу гамәл Аллаһ каршында мактаулы һәм кешеләр каршында лаеклы эш санала, ләкин бу

эшне господин өяз исправнигына белдерергә кирәк. Аллаһ яхшырак беләдер. (*Мөһер*) номеры 058. 1811 елның 6 нчы сентябре.

*Өченче хат.*

Имамнар әйтүенчә, Аллаһ аларга рәхимлек кылсын, Уфа ягында Сәвәләй авылындагы берничә йорт белән торучы мөселманнар җәмәгать намазы вә дога кылудан мәхрүм булып, аксакаллардан Кунакбай Мирзагол углы вә башкалар бергәләшеп, мәсҗид төзергә рөхсәт вә фәтвә сораганнар. Шәригать кануны вә хәнәфи мәзһәб буенча, түбәндәге исем белән мөһер астында, рөхсәт вә фәтвә бирелде, чөнки бу гамәл Аллаһ каршында данлы вә кешеләр каршында мактаулы санала, әҗерле булачак, ләкин бу эш өяз башлыгы господин исправникка белдерелсен. Аллаһ яхшырак беләдер. 15 нче март, 1816 ел, номеры 39.

*Дүртенче хат.*

Имамнар әйтүенчә, Казан губернасы Күҗенс (?) өязе Биги авылында[11] элек мәчет булып, кышкы һәм язгы айларда җимерек хәлгә килгән. Шуңа күрә, авыл халкы үтенече белән, Мирза Шәгъбан бине Ягъкуб әлеге авылда мәчетне төзекләндерергә вә яңартырга рөхсәт вә фәтвә сорады. Шәригать вә ханәфи мәзһәбе буенча мин, исемем мөһердә сугылган, бу үтенечне Мирза Шәгъбан бине Ягъкубка ризалыгымны белдереп, бу иске җимерек мәчетне төзекләндерергә рәсми рөхсәт вә фәтвә бирәм. Бу гамәл Аллаһ каршында саваплы вә әҗерле булыр. Аллаһ кабул итсен безне вә сезне. Мөфти әл-Хөсәйни. 1819 ел, 4 нче март, номер 43. (*Мөһер.*)

*Бишенче хат.*

Имам мулла Габделкәрим Каепкол углына фәрман: миңа Орынды авылында Биби кыз Бикә Айу кызы тарафыннан шикаять гаризасы килде. Бу хатынның ире Габде Котлыбай улы хәрби хезмәткә киткәч, Биби берничә ел буена гомерен асрар өчен акчага мохтаҗ булу сәбәпле, башкага кияүгә чыгарга ниятли. Әлеге хатынның ире хәрби хезмәттә үлгән дигән хәбәре килгән икән, шуңа күрә әгәр дә чыннан бу хатынның дүртбиш бала калган, аларны тәрбия кылырга акча юклыгы расланса, үзе теләгәнчә кияүгә чыгарга рөхсәт бирелә. Бернинди киртәләр тудырылмасын. Мөфти. 1820 ел, март.

*Алтынчы хат.*

Ислам имамнары сөйләгәнчә, Сембер губернасы Буа өязе Бизнә волосте Бизнә авылының хәзрәте Габделмәҗид Сәфәр углын шул Бизнә авылы Бибихәбибә Сәгыйдь кызына никахлаштырып һәм шаһидлар үзара килешү нигезендә өч йөз уналты сум мәһәр (калым) игълан итеп, шул ук мәҗлестә расписка бирде. Бераз вакыттан соң Сәгыйдь үзенең кызы Бибинең никахын инкяр итеп, вә аны Мәҗидкә хатынлыкка бирүдән кире баш тартты. Шунлыктан дәгъвачы Мәҗид өяз башлыгы господин исправник Николай Фёдоровичка гариза язып, приказ алып, мулла Бәшир вә мулла Вәлид имамнар белән, Ибраһим главага господин исправникның әмере белән барып, әлеге авылда хөкем мәҗлесе җыялар. Мәҗид бине Сәфәр белән Бибихәбибә никахын тикшереп, дәгъвачы Мәҗиднең Бибихәбибәгә дип төзегән өч йөз уналты сумлык никах килешүе расланып кабул булды һәм канун белән ныгытылды. Җыелышыта шаһидләр вә искә

алынган голәмалар глава Ибраһим хозурында тикшерү үткәреп, хөкем үтәлү йөзеннән Хәбибә Сәгыйдь кызын Мәҗид Сәфәр улына хатынлыкка бирергә дип, фәтва төзеп имзаладылар. Шаригать вә хәнәфи мәзһәб буенча бу хөкем карарын исеме мөһердә язылган түбәндәге зат, имамнар Ибраһим глава хозурында карадылар, шаригатькә туры килә һәм үтәлергә тиеш, дип әйттеләр һәм фәтвә бирделәр, чөнки Мәҗид үзенең дәгъвасына күпчелек шаһитлардан исбатлауларын алды. Өяз башлыгы, господин исправник әлеге Бибихәбибә Сәгыйдь кызын Мәҗид Сәфәр улына хатынлыкка бирүне карар кылдылар һәм бер нинди кире кагу булмаска тиеш, диделәр. Мөфти. 1820 ел. (7) июль. 86 нчы номер. (*Мөһер.*)

*Җиденче хат.*

Буа округының господин глава Рәфикъ улы... ошбу июнь йолдызында сезнең волостьнең Габделмәҗид Сәфәр улы илә очраштым, ул волостьнең имамнары мулла Вәлид Биккол улы илә Буа нахиясенең господин исправник приказ илә дәгъва ителгән Габделмәҗид Сәфәр улы илә Бибихәбибә Сәгыйдь кызының никахы хакында низаглары булып, господин исправникның Николай Федорович бөек җәнапләренең тикшерүе илә Бибихәбибә Сәгыйдь кызын Габделмәҗид сәфәр углына хатынлыкка шәргый рәвештә алуны исбат иткән шул имамнар һәм глава алдында. Габделмәҗид дәгъваларын шәргый яктан исбат ителеп, бәхәстә өстен булырга теләп имамнар главалар алдында хөкем ясадылар. Шул сәбәпле миннән 84нче номер белән фәтва бирелде Бибихәбибәне Габделмәҗидкә никахларга. Шул фәтва нигезендә Хәбибәне законсыз никахлаган мулла Нигъмәтулла Бәшир углыннан җавап аласыз, башканың хатыны булган Хәбибәне никахландырган мулладан сез гыйззәтле глава, имам мулла Вәлид Биккол улы илә мулла Йормаш улы карамагында шул мулла Нигъмәтулла Бәшир углыннан җавап аласыз: нинди шәригать илә башка бер кешенең никахында булган кызны Сәйфетдин Биккол улына никах укыган. Җавап алып рапортны миңа җибәрәсез. Икенчедән, әгәр Хәбибәне Габделмәҗидкә кайтарырга теләмәсә, господин исправникка хәбәр итеп, исправник җәнапләрен алып, аның ярдәме белән кайтарырга. Әгәр дә господин исправникка каршы килсә, господин исправник гали җәнапле Сембер шәһәренең губернаторы Андрей Петровичка хәбәр итеп, хәрам никахтан аерып, Габделмәҗид Сәфәр улына кайтарып, миңа рапорт бирәсез. Господин глава Рәфикъ бу фәтванамәне сиңа бирәм, элеккеге глава Ибраһим илә ике мулла хөкемнамәләрне син алардан сорап, соңра фәтваны господин исправникка күрсәтеп, гамәл итәсез. Мөфти. 1820 ел, 7 нче июль, 87 нче номер.

*Сигезенче хат.*

[...] бер генә галим дә тыкшынмасын, чөнки Мөхәммәд шәригатендә, бөек имам (Хәнәфи) мәзһәбендә, Коръән Шәрифтә вә фәтвә китапларында, вә тәфсирдә анык әйтелә: «Никах ирекле башкарыла, тәрбияче һәм башкаларның катышы булмаска тиеш» («Мохтасар әлвикая»); «Бәлигъ булган кызларга, тол хатыннарга үз теләкләре белән ирекле рәвештә кияүгә чыгарга мөмкин»(Хәнәфия китапларында). Аллаһы Тәгалә Коръән Шәрифтә әйтә: «Алар ни эшләргә теләсәләр дә, гөнаһы булмас»[12], «Үз ирләренә

кияүгә чыгарга комачауламагыз»[13], «Ул башка иргә кияүгә чыкмыйча, ярамый», «Бер-берсенә кире кайтсалар, зыянлы түгел». Исламда болай әйтелә: «Кияүгә чыгарга хатын-кызның хакы тәрбиячесенекеннән күбрәк» (Зильги фәтвасе)[14]. Шәфигыйләрдә шундый риваять бар: «Гаишә галәйһи-с-сәлам әйткән ди, ниндидер хатын үз тәрбиячесенең рөхсәтен алмыйча кияүгә чыкса, мондый никах саналмый». Аллаһы Тәгалә әйткән: «...Хәтта башка иргә кияүгә чыксын...». Кабат кияүгә чыгу турында пәйгамбәребез әйткән: «Тол хатыннарның кияүгә чыгу хакы тәрбиячесенекеннән күбрәк була». «Никах уку сүз белән кавышуны дәлилли. Исламда тол хатынның хакы аны караучының сәламәтлегеннән дә мөһимрәк итеп күрсәтелә. Бер авыру кеше Гайшәгә (Аллаһ анардан разый булсын) аның хатыны Габдеррәхмән абыйсының кызы дип сөйләгән, һәм бу сүзләр сөйләүченең авыру икәнен ачык күрсәтә. Бохахи мондый никах хаклы булмый, дип әйткән. Хәдис опекунның никах өчен таләпләрен күрсәтә» («Мәҗмәгъ-л-бәхрәйн шәрхе»).

Кырым мөфтие риваятендә (*үз редакциясендә язылган*) болай диелә: «Опекунның рөхсәте булмыйча, кияүгә чыгу ярамый һәм ялган санала».

Бу әйтем шәфигый мәзһәбеннән бер имамныкы булыр: «Хатын-кыз үз теләге белән генә кияүгә чыга алмый, үземе, кызымы, анасымы — бары тик тәрбиячесе рөхсәте белән генә».

Дәгъва кылучы һәм җавап бирүче хәнәфи мәзһәбендә, барлык мөселманнар бөек император буйсынуында, мин бөек имам Хәнәфинең мәзһәбендә торып, эш итәм. Шәфигый мәзһәбе безнең мәзһәб өчен тыелган. Кемдер хәнәфи мәзһәбеннән шәфигый мәзһәбенә күчеп китә икән, эштән чыгарылырга тиеш. Халык тәнкыйтьләргә лаеклы (тиеш). Әгәр дәгъва кылучы һәм җавап бирүче шәфигый мәзһәбендә булса, бу очракта шәфигый хәзрәт мәзһәбе белән опекун рөхсәт бирмичә өйләнергә ярамый, дигән фәтва бирелә. Кырым мөфтие Хәсән риваяте Әбү Хәнифәгә хилаф риваятьтер. Бу риваять кулланылмый. Вә Гаишә хәзрәтенең, Аллаһ аңар рәхимле булсын, законлы булмаган, ирекле вә рөхсәтсез булган никахлар турында риваяте килгән. Ләкин бу хәдис нигезсез, гәрчә «Ихтияр китабында» булса да. (Риваять буенча, Мәлик һәм Җөрәйҗ дигән кешеләр Зәһрадән Гаишә хәдисе турында сораганнар, ләкин теге белмәгән. Әгәр риваятче үзе дә хәбәрнең дөреслеген белми икән, димәк ялган булуы дәлилләнә). 1823 нче ел. 2 нче апрель.

Ошбу хатны мөфти Габделвахид бине Сөләйман язуыннан күчердем. Хатның эчтәлеге һәм ахырында имзасы мин күргән һәм күчергән нөсхәдә юк иде, ләкин мөфти Габделвахид бине Сөләйман кулы илә ошбу сүзләр язылган иде: «Дөрес, Петербургта имам, хатыйб, тархан Габделвахид Сөләйман ахун углы, миңа тапшырылды 19 апрельдә мәрхүм мөфтинең үз хаты». Собрание архивында 29 нчы кисәк эшләре арасында булган Сөләйман углы эшеннән аңлашылганга күрә, Нижгород вилаятенең Тәмимдар исемле кеше дәгъвасы хакында, вәлидән *[опекуннан]* башка никахның дөрес булу-булмавын сорап белгәнгә күрә, бу хат Мөхәммәдҗан мөфти бине Хөсәен тарафыннан имам Сөләйман углына язылган.

Болардан башка җиде хаты «Мөстәфадел-әхбар» да китерелгән, шунда мөрәҗәгать итәрсез (2 нче бүлек, 83—84, 290—295 бб.). Хат-

лары исә барысы да бер тәртиптә, хәтта хаталы сүзләре һәм бертөсле булганга күрә, бер караламадан күчерелгән, дип уйлый.

**Мөляхәзә**

Үзебезнең ана телебез төрки телебез булган хәлдә, мөфти хәзрәтләре ошбу әмер вә фәтваларны ни сәбәпкә нигезләнеп фарсы телендә язган? Моның исә, әлбәттә, берәр хикмәте булыр. Фәкать бу хикмәт безгә әле билгеле түгел. Фәнни китапларны вә яки бөтен дөнья халкы куллануына лаек әсәрләрне (кагыйдәләрне муафыйк язу шарты белән) фарсы яки гарәп телендә язу зарарлы булмас. Ләкин мөфти хәзрәтләренең биредә аталган әсәрләре гомум ислам галәменә кагылышлы нәрсәләр булмаган кебек, фәнни бәхәсләр дә түгел. Хәл болай икән, үз ата-бабаларыбыз вә сөекле аналарыбыздан бөек бер ядкәр буларак калган телебезне читкә куеп, фарсыча язуыбыз — кирәк тәмам кагыйдәсенә туры китереп язылсын, һичбер вакыт гафу ителмәячәк көфер нигъмәт булыр.

Гәрчә элек яулап алынган заманда ислам дәүләте Гыйрак вилайәтләрендә фарсы телен рәсми сурәттә куллансалар да, бу бары тик җирле халыкның хәтере өчен генә булган. Шушы ук сәбәп белән Мисырда — кобыт, Сүриядә рум язуының рәсми кулланылуы турында сөйләнелә. Бераз вакыт узуга, бу гадәтләр бетерелеп, гарәп теле кулланыла башлаган.

Ни гаҗәп! Тибетта утыручы лама үз диндәшләре вә җенестәшләренә фәрман вә дини нәсыйхәт язганда гарәп вә яки латин телендә язамы икән?.. Минемчә, бу зат хат җибәрәсе кавемнәрнең үз телләрендә һәм иң ачык сурәттә язар иде. Безнең мөфти хәзрәтләре исә Тимербай, Сәвәләй башкортларына иң мөһим фәрманнарын ни өчен фарсы телендә язган?.. Язылган кавемнең хәле кайгыртылса, үз телләрендә, утырган урыны кайгыртылса, дәүләт теле булган русча язылырга тиеш иде.

Телебез ярлы, сөйләшергә вә язарга җитми дип, дәгъва иткән карендәшләребезнең сүзләре укучыларга бер нәрсә язмауга, язылганнары укымауга ялкаулык икәнлеген яшерер өчен корылган бер пәрдә. Тиешле урында бу сүз дөрес бер сүз дә булсын, ләкин телләрне баетучылар вә киңәйтүчеләр алар илә сөйләүче вә язучы адәмнәр булса кирәк, юкса тик торган вә яки юеш урында тутыгып яткан тимер кебек, бозылып яткан хәлдә һичбер телнең баеганы вә мәйданга чыкканы, минемчә, ишетелгәне юк.

Шул сәбәпле Казан шәһәрендә гарәби хәреф илә 1177/1764 елда ачылган матбагадан әдәбиятыбыз кирәк дәрәҗәдә файдалана алмады. Чөнки 100 ел эчендә таралган китапларыбыз вә рисаләләребезнең 5—10 тирәсе саналмаганда, бары тик гомер ашаучы вә вакыт үтерүче нәрсәләр генә булыр.

Аллаһы Тәгалә хәзрәтләренә күп шөкерләр булсын ки, күктәге Кояш файдасы илә аналардан ядкәр калган тел нигъмәте һичбер җирдә һичбер кавемгә артык күрелмәс.

**Мөфти (Мөхәммәдҗан Хөсәенов) хәзрәтләренә язылган хатлар**

*Беренче хат.*

Духовный собрание, шушы 1810 елның июнь көннәрендә олуг император Александр Павловичның фәрманы илә мине, Рахманколый углын, Мәкәрҗә ярминкәсендәге мәсҗидтә

мөселман сәүдәгәрләргә имам буларак, намаз укырга вә башка дини эшләрне үтәргә җибәргән иде. Мин исә, әлеге әмер буенча боерылган хезмәтләрне үтәгәндә Казан губернасы Сары Кукшай (Царевококшайск) өязе Оры[15] иленең указлы имамы Хәбибулла Хөсәен угылы минем хезмәтемә тарлык ясады. Бу гамәленә Казан шәһәренең гражданский губернаторыннан указым бар дип, сәбәбен күрсәтә. Икенче, Казан шәһәрендә Иске бистәнең Өченче таш мәсҗид мулласы Сәгыйдь ахун да минем хезмәтемә тарлык күрсәтте. Хәлбуки, һич бер урыннан әмере юк. Тиешле булган мәхкәмәләргә мәгълүм итми, үзенең хезмәтен ташлап, монда килгән. Шулай ук үзенең мөәзине Халидне дә бергә алып килеп, мөәзин куяр өчен миңа ихтыяр бирмәде. Иске бистәнең агач мәсҗидендә имам Мортаза да монда килгән. Болардан башка кешеләрдән тарлык булмады. Шулай ук мәсҗидкә караган кибетләрдән җыелган акча Иске бистәнең сәүдәгәр Бәшир Гаед углында калып, безгә бөтенләй акча бирелмәде. Мәсҗид ерак булганга, тактадан мәсҗид ясатып, намаз кылдык, падишаһыбыз император хәзрәтләренә дога укыдык. Чистай өязе Кече Бахта волосте Колай авылында имам, мөдәррис, мөхтәсиб Әбүшәхмә Рахманколый угылы. 1810 ел, 18 сентябрьдә.

*Икенче хат.*

Тиешле мәхкәмәләрдән рөхсәт алмаган хәлдә Сары Кукшай өязе Оры авылының Хәбибулла мелла Хөсәен углының Петербург шәһәренә баруын, быел 20 январь һәм 2 мартта булган кәгазьләрегез илә күрсәтелгәннәргә нигезләнеп, мин падишаһ император хәзрәтләренә мөрәҗәгать иттем. Әлеге мелла Хөсәен углын үз авылына кайтарып җибәрү хакында император хәзрәтләре фәрман чыгарды. Бөек император хәзрәтләрен мондый бөек чараларын җәнабегезгә шушы кәгазь илә белдердем. Князь Лопухин. 1804 ел, 14 апрель.

*Өченче хат.*

9 нчы санда булган язуыгызга күрә бәйан итәм: Орының мелла Хәбибулла Хөсәен угылы мөселманнар арасында гыйбадәт үткәрергә лаек булса кирәк. Чөнки мөселманнарның дин хезмәтләрен үтәүгә рөхсәт ителеп, 1802 елның 4 сентябрендә Бөек император хәзрәтләренең Указлары әлеге затка бирелгән.

Икенче, 1810 елның июнь аенда мөселман сәүдәгәрләре гариза биреп, әлеге Хөсәен углын имамлык өчен билгеләргә миннән сораганнар иде. Шуңа күрә ярминкәгә килгән мөселманнарга имамлык өчен мәгълүм Хөсәен углын расларга Нижгород губернаторына фәрман язган идем. Моны исә сезгә бәйан итәм. 1765 нче номер. 1811 ел, 29 март. Петербург. Имзасы ачык түгел. Башкача тамгалар юк.

*Дүртенче хат.*[16]

Узган 1811 ел 24 майда Сары Кукшай өязендә Оры авылында булган Хәбибулла Хөсәен углы хакында булган гаризагызны эчке эшләр һәм юстиция министрларында булган эшләре илә карагач, тиешле мәхкәмәләрнең рөхсәтеннән башка Петербург шәһәренә баруын сәбәп күрсәтеп, Собрание мәхкәмәсе әлеге Хөсәен углын 1803 елның 30 январендә урыныннан төшерүе мәгълүм булды. Шул елда булган суд эшегездә Хәбибулла Хөсәен

углының начар мәзһәбләрдән булуы вә үз-үзен шәех дип күрсәтеп, хәтта Саратов губернасында үз-үзен угодник һәм чудотворец дип игълан итүе, үзенә канцелярия ачып кыйммәтле урындык куюы һәм акчалар җыюы расланды, дип күрсәтәсез. Хәлбуки, земский суд тикшерүе буенча бу эшләрнең берсе дә расланмаган. Шулай ук бу хакта мәгълүм Хөсәен углы Саратовның уголовный палатага карау өчен бирелгән. Саратовның гражданский губернаторы бу турыда болай күрсәтә: «Шәгъбан Муса углы, үзенең остазы булган Хәбибулла Хөсәен углы үтенеп, кунакка чакырган. Шуңа күрә Хөсәен углы 1804 елның февраль аенда Труир авылына Шәгъбан Муса углының өйнә килгән. Ләкин бу авылдан башка авылларга чыгып йөргән. Тирәякта булган авыл халкыннан теләгән кешеләр килеп, Хөсәен углы илә күрешкәннәр, вә бу авылда Хөсәен углы илә берлектә гыйбадәт кылганнар. Һәркем үз ихтияры белән күпме-әзме Хөсәен углына садака биргән, ләкин мал җыю булмаган, кыйммәтле урындык кую һәм Хөсәен углы үз-үзен угодник вә чудотворец дип күрсәтмәгән. Мөселман халкы уйлавынча, Хәбибулла мулла — галим, итагатьле вә иҗтиһадлы бер зат». Шулай ук Казанда гражданский губернатор миңа язадыр: «Мөселман җәмәгатенең күбесе Хәбибулла Хөсәен углына ышаналар, аны начар мәзһәбтән димиләр, изге холыклы вә инсафлы дип, мактыйлар. Сез никадәр Хәбибулла Хөсәен углының бозыклыгы ителде дисәгез дә, исбаты өчен дәлил китермисез. Гәрчә юстиция министрына биргән гаризагызда бер китап җибәреп, бу китапның 58—59 битләрендә Хәбибулла тарафыннан Мәхәммәд (с.г.с.) шәҗәрәсе китерелеп, үзенең һәм Уфа шәһәреннән ерак булмаган Җәгъфәр исемле бер кешенең хәлифә икәннәрен язган дисәгез дә, бу китапның шул битләрен тәрҗемә иткәч, сез әйткәннәр табылмады. Хәтта бу турыда юстиция министры тарафыннан сезгә: «Мондый нигезсез әйберләр язуыгыз яхшы түгелдер» дип, язылган икән. Шуңа нигезләнеп, мәнсабегезнең хөрмәтен саклар өчен хәкыйкать түгел эшләрне тәкъдим итүегез лаек түгелдер. Кенәз Александр Голицин. Санкт-Петербург, 127нче номер, 16 март, 1812 ел.

*Бишенче хат.*

Хәбибулла Хөсәен углы әһле ислам галимнәреннән булуы өчен Собрание мәхкәмәсенә итагатьле итеп тоткан фикерендә булганыгызга бернәрсә дә йәтеп булмый. Бу морадыгыз, әлбәттә, илтифатсыз калмас. Сезнең илтимасыгызга күрә 1804 елда император хәзрәтләреннән Петербургтан җибәреләсе хакында фәрман да булган. Ләкин Юстиция һәм Эчке эшләр министрлыкларыннан алган мәгълүматка күрә Хөсәен углы гаепле күрелми. Казан губернаторы да аны үз тарафыннан аклый. Шуңа нигезләнеп аны урыннан төшерү хакында тәдбир итә алмыйм. Кенәз Голицин. Санкт-Петербург, 516 нчы номер, 1812 ел, 5 сентябрь.

*Алтынчы хат.*

Үткән 1812 елның 12 октябрендә язганыгызга мөнәсәбәтле рәвештә, Хөсәен угылы хакында Казан губернаторыннан сорадым. Казан губернаторы исә тикшергәннән соң, әлеге шәхесне гүзәл холыклы вә инсафлы бер зат дип тапкан икән. Тикшерү кәгазенең күчермәсе дә шушы хат илә Сезгә җибәрелде. Шул сәбәпле, минем фикеремчә, бу зат илә булган

дәгъваларыгызны бетерү тиештер. Кенәз Александр Голицын. 381 нче номер. 1813 ел, 21 август. Санкт-Петербург.

## Мөляхәзә

Бу хатларның беренчесеннән башкасы русчадан, фәкать эчтәлеген биреп, тәрҗемә ителгән. Мөфтинең үз хатлары бигрәк озын булганга һәм үткән гасыр гадәте буенча, язуы танылмаганга һәм бик төгәл булмаганга, тәрҗемәсеннән ваз кичелде. Ни булса да, Хәбибулла ишанны хөрмәтләмәве, мактамавы язган кадәребездән дә мәгълүм була. Фикеребезчә, Хәбибулла ишанга бу кадәр ачу күзе белән каравы әлеге затның мөфти булуыннан куркудан. Хәтта моны бер-ике хатында кенәз Голицынга да сөйләгән. Мөфти белән үзара хәбәрләшкән кенәз Голицын шул заманда Синод идарәсендә обер-прокурор вазыйфасында булган икән.

Мөфти хәзрәт заманында мөселманнарны җирләр өчен үзләренә махсус бер каберлек вә җәмәгать намазы укыр өчен мәсҗид Уфа шәһәрендә булмавы сөйләнелә. Фәкать моның мәслихәт күрүе белән Казан шәһәрендә кайбер нәрсәләр басылган, моның өчен үзен кулыбыздан килгән кадәр хәер-дога илә искә алу безнең бурычыбыз. Бу уңайдан Габделгазиз Туктамыш угылы тарафыннан 171 битле 1802 елда Мөхәммәд бине Бәркиленең (Мөхәммәд әфәнде Бәркәви) тезмә бер әсәре басылып, ахырында: «Мөхәммәдҗан мөфти фәтвасы илә» — дип, бер гыйбарә бирелгән. Моннан башка, әүвәл Ислам Мәхкәмәсе ачып юлга куюы вә Диния нәзарәтен рәсми сурәттә мәхкәмәләргә кабул иттерү дәрәҗәләренә китерү аз мәшәкать илә мәйданга килмәгән. Мондый эшләрнең гамәлгә чыгуы көч җитмәстәй тырышлык сарыф ителүгә бәйле икәнлеге һәркемгә мәгълүм. Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре һәрникадәр гафу вә гофран әйләсен!

## Искәрмәләр

1. Бу турыда карагыз: Байбулатова Л.Ф. «Асар»ның сызып ташланган юллары // Гасырлар авазы-Эхо веков. 2002. №1/2. Б. 19—25.

2. Мөфтиләр арасында Гатаулла Баязитовның тәрҗемәи хәле юк. Аның кыскача тормыш юлын Р. Фәхретдинов «Казан вә Болгар төрекләре» исемле хезмәтендә урнаштыра (Уфа фәнни үзәгенең фәнни архивы. Ф. 7. Оп. 2. Эш. 13. Б. 62, яңа акт).

3. Текстның төп өлеше түбәндәге басмадан алынды: Ризаэддин Фәхретдин. Асар. 1 җилд / төз. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, С. Рәхимов. Казан: Рухият, 2006, 98—106 бб.

4. Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыя (Оренбургское магометанское духовное управление) — Екатерина II указы белән 1788 елның 22 сентябрендә барлыкка килгән, 1789 елның 4 декабреннән эшли башлаган.

5. Атҗитәр — 1735 елда барлыкка килгән, хәзерге вакытта Башкорстанның Кырмыскалы районындагы авыл.

6. Бишенче ревизия 1794—1808 елларда уздырылган.

7. Солтанай — хәзер Башкортстанның Аскын районына керә.

8. Күди — башкортларның айле төркеменә керә торган борынгы төрки кабилә.

9. Әмирҗанның Хөсниҗамал бинте Габдессаттар исемле бер хатыны бар иде.

10. Бүкәй иле — XIX гасыр урталарында барлыкка килгән казакъ ыруларының ярымавтоном дәүләт берәмлеге, административ бүленеш буенча Әстерхан губернасына кергән.

11. Ихтимал, Саратов губернасы, Кузнецк өязендәге Биги авылы турында сүз бара.

12. Коръән, 2—234.

13. Коръән, 2—232.

14. Хәсән бине Ибраһим бине Хәсән Гали әз-Зилги әл-Җөбрәти әл-Хәнәфи, факыйһ (вафат — 1188 һ.к. ел)

15. Хәзерге вакытта Татарстанның Балтач районындагы авыл.

16. Оригиналда шулай.

***Байбулатова Лилия Фәрит кызы**,*
*тарих фәннәре кандидаты,*
*Ш. Мәрҗани исем. Тарих институтының*
*баш фәнни хезмәткәре*

УДК 372.881.512.145

***Н.В. Максимов***

# ТЕЛГӘ ӨЙРӘТҮ ТЕХНОЛОГИЯСЕ

В статье рассматривается технология обучения татарскому языку как неродному. Обосновывается целесообразность обучения на синтаксической основе. Выделение синтагматической модели речи в качестве основы обучения неродной речи позволяет акцентировать внимание обучаемого на алгоритме построения словосочетаний и предложений. Опора на алгоритмы помогает обучаемому варьировать стабильными синтаксическими конструкциями в процессе создания текста-основы и выстраивания диалога.

**Ключевые слова:** слово, словосочетание, простое предложение, технология обучения татарскому языку.

Ана телен белмәгән татар яки рус баласына татар телен өйрәтүдә тупланган эш тәҗрибәсе шуны күрсәтә: баланы ана телендә яки чит телдә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү сөйләм калыпларын эзлекле үзләштерүгә нигезләнеп оештырылганда гына — телгә өйрәтү технологик процесс буларак алып барылганда гына, көтелгән соңгы нәтиҗәгә ирешеп була. Соңгы нәтиҗә ул — өйрәнүченең өйрәнгән телендә ситуатив темалар буенча иркен аралаша алуы.

Әдәби сөйләм теленә өйрәтүне мәктәп укучысына кайсы да булса бер телнең (безнең очракта, татар теленең) сүз байлыгын, фонетикасын, орфоэпиясен, орфографиясен, морфологиясен һәм синтаксисын сыйныфтан сыйныфка эзлекле рәвештә кагыйдәләрне өйрәтү белән бутарга ярамый.

Сөйләм теле (теләсә кайсы телдә) сөйләм калыпларына нигезләнеп өйрәтелергә тиеш. Сөйләм калыбы телдә булган барлык кагыйдәләргә нигезләнеп, дөрес әдәби сөйләм нормаларын өйрәтү өчен төзелә.

Сөйләм калыбы барлык халыкларда да, гадәттә, ата-бабадан электән килгән сөйләм кагыйдәләренә таянып, билгеле бер тема (темалар) буенча көндәлек тормышта, мәсәлән, *кая да булса баруга* яки *кайтуга; кайсы да булса эшне кайда, ничек, кем белән, ни өчен башкаруга* мөнәсәбәттә кара-каршы сөйләшү өчен, диалог формасына яраклаштырып төзелә. Ул темаларның барысын берләштереп, **«Үзебез турында сөйләшү»** дип атап булыр иде. Үзебез турында, ягъни үзем, якыннарым, туганнарым, танышларым, дусларым, күршеләрем турында, аларга мөнәсәбәттә.

«Сөйләм калыплары» дигән атама инглиз һәм немец теленә өйрәтү методикасы белән шөгыльләнүче белгечләр (Б.Ф. Корндорф һ.б.) тарафыннан бик күптәннән кертелсә дә, аны сөйләмгә тулысынча яраклаштырып куллану технологиясе хәзергә кадәр бер телдә дә эшләнелмәгән дияргә була.

Барлык телләрдәге сүзләр, уртак гомуми мәгънә (мәсәлән, хә-

рәкәтне, эшне, хәлне, аралашуны, уйлауны, кабул итүне һ.б.ны) белдерүләре ягыннан чыгып, гомуми сорау астында — төркемнәргә, төркемнәр төркемчәләргә бүленеп берләштерелгән. Сөйләм калыбында ул сүзләр укучыга да, телгә өйрәнүчегә дә тема кысаларында куллануга, гадәттә, **әзер формада** тәкъдим ителә. Сөйләүче яки телне өйрәнүче шул әзер сүзләрне, сорау сүзгә — *кем? нәрсә? кайсы? нинди? ничә? кайчан? кая? кайдан? кайда? нәрсәдә? нәрсәгә? кем белән? нәрсә белән? кем турында? нәрсә турында? ничек? нишли? нишләми?* һ.б.ш. сүзләргә — җавап буларак, сүзтезмә һәм җөмлә калыпларына гына урнаштыра. Сөйләмдә төп сүз — затланышлы хикәя фигыль формасы белән белдерелгән компонент. Сөйләмдә катнашучыларның фикере, нигездә, затланышлы хикәя фигыльгә мөнәсәбәттә формалаша. Сөйләм сүзне сүзгә ялгаудан — сүзтезмәдән яки җыйнак җөмләдән башлана.

Бәйләнешле сөйләм лексик, грамматик һәм интонацион чаралар ярдәмендә оеша. Сөйләм оешсын өчен, сөйләм калыбын төзи белергә кирәк. **Сөйләм калыбы** ул — конкрет бер тема буенча сөйләшүне коммуникатив һәм композицион бөтен (микротекст, макротекст) буларак оештырырлык, көндәлек тормышта мәгънәсе ягыннан иң еш кулланыла торган сүзләр, җыйнак җөмлә модельләре, сүзләрне һәм җөмләләрне бәйләүче мәгънәви чаралар: бәйлекләр, бәйлек ролендә йөрүче ярдәмче исемнәр — бәйлек сүзләр; тезүче һәм ияртүче теркәгечләр, кисәкчәләр, ымлыклар, модаль сүзләр тупланмасы.

Сөйләүче һәрвакыт үзе эшләгән яки эшлисе эш, үзе күргән хәл турында хәбәр итә, хәбәрендә һәрвакыт кайсы да булса эшнең, хәлнең, күренешнең булуын йә раслый, йә инкарь итә. Шуңа нигезләнеп, тыңлаучылары өчен сөйләшүнең **темасын** билгели. Тема тәкъдим ителгәч, сөйләмнең эчтәлеген мөмкин кадәр тулырак ачу өчен, гомуми мәгънәсе якын булган сүзләрдән, беренче чиратта, раслау яки инкарь төрдәге җыйнак җөмлә яки сүзтезмә модельләре сайлана. Бәйләнешле сөйләм калыбы, аралашу алга таба бары тик шуларга нигезләнеп кенә төзелә.

Сөйләшү, аралашу кайсы ягы белән кызыклы һәм үзенчәлекле? Сөйләм башлангыч текстка нигезләнеп төзелгән диалог — сорау һәм җавап рәвешендә формалаша. Аралашу темасы барысына да кызыклы булганда гына, сөйләмдә катнашучылар актив була: берсе икенчесенә сораулар бирә, фикер алыша. Соравына үзен канәгатьләндерерлек җавап алганда, фикерләр уртак булганда, яклар сөйләшүдән тәм таба, аралашу теләге тагын да арта.

Кайсы да булса телдә сөйләшергә өйрәнү өчен, лексик минимумны үзләштерү белән бергә, шул телнең җөмлә (сорау җөмлә һәм җавап җөмлә) калыпларын өйрәнергә, алардагы компонентларның ***кайсы сорауга җавап буларак урнашу тәртибен*** хәтердә калдырырга кирәк. Алга таба, бирелгән калыплар үрнәгендә, җөмләнең грамматик төзелешенә зыян китермичә, бер сүзне икенчесе белән алмаштырып, яңа һәм тулырак эчтәлекле җөмләләр төзү күнекмәләре булдырыла.

Татар телендә сорау җөмлә, нигездә, сорау алмашлыклары *(кем? нәрсә? кайсы? нинди? ничә? кайчан? кая? кайда? нәрсәдә? кайдан? нәрсәдән? ничек? нишли? ниш-*

*ләми?)* яки сорау кушымчалары *(-мы //-ме, -мыни //-мени)*, сорау интонациясе, кайбер очракларда гына билгесезлекне белдерүче кушымчалар *(-дыр //-дер, -тыр //-тер)* ярдәмендә төзелә. Телгә өйрәтүче дә, телгә өйрәнүче дә татар сөйләмендә алар ярдәмендә сорау җөмләдән — җавап җөмлә, җавап җөмләдән сорау җөмлә төзү алгоритмын эзлекле куллана белү күнекмәләренә төшенергә тиеш.

Сөйләмнең төп элементы — фикереңне, кичерешләреңне, мөнәсәбәтеңне башкаларга аңлата белү сәләте. Сорау җөмләләр төзүгә, сөйләмдә катнашучыларның төрле тойгыларын белдерүгә, сөйләмгә тойгылы аһәң бирүгә, барыннан да элек, сорауны белдерүче сүзләр һәм сорау кушымчалары ярдәм итә. Сорауны белдерүче сүзләр һәм сорау кушымчалары — I затның сөйләм, сөйләмдә катнашучы затлар белән идарә итү, сөйләм темасын үзе теләгәнчә хәл итү коралы. Сөйләшү шулар ярдәмендә генә матур, эзлекле, эчтәлекле, тулы, аңлаешлы һәм дәвамлы була ала.

Татар җөмләсендә сорау кушымчасы, сүзнең аваз төзелешенә карап, калынлыкта яки нечкәлектә ярашып, җөмләдә тулы мәгънәле лексик берәмлек белән белдерелгән теләсә кайсы кисәккә генә түгел, хәтта бәйлек, бәйлек һәм хәбәрлек сүзләргә, кисәкчәләргә дә ялгана ала. Бу очракта, сорау һәм гаҗәпләнү, шатлану, кайгыру кебек эмоциональ мәгънәләр өстәлгән тойгылы сорау һәм тойгылы җавап җөмләләр барлыкка килә. Сорау кушымчалары, гадәттә, тулаем җөмләгә дә, аерым сүзгә дә карарга мөмкин.

Телгә өйрәтүче һәм өйрәнүче шуны хәтерендә калдырырга тиеш: татар телендә сорау кушымчасы сүзгә соңгы кушымча булып ялгана, аңа басым төшми. Сорау кушымчасы булган сүзләрдә басым, кагыйдә буларак, сорау кушымчасы алдындагы иҗеккә төшә. Татарча аралашканда, сөйләүче зат сөйләменә матурлыкны, тәэсирле яңгырау көчен, әңгәмәдәшенә карата булган җылы яки бик үк җылы булмаган мөнәсәбәтне сорау кушымчасы алган сүзләр бирә дә. Аларны сөйләм калыбында таләп ителгән эчтәлеккә яраклаштырып әйтә белергә генә кирәк.

Сөйләм калыбына урынлы кертелгән һәр керешмә сөйләмдә катнашучыларның бер-берсенә булган мөнәсәбәтен күрсәтә. Тәкъдим ителгән сөйләм калыбында, мәсәлән, түбәндәге керешмәләр кулланылса, сөйләшү тагын да матураер һәм тулыланыр, эмоциональ яктан баер иде.

| Керешмәләр | Мәгънәләре |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Зинһар, зинһар өчен | Сөйләүче үтенә |
| Гафу ит, кара әле, тыңла әле, беләсең килсә, әйтсәм әйтим | Сөйләүче, игътибар итүләрен сорап, тыңлаучыларына мөрәҗәгать итә |
| Минемчә, синеңчә, аныңча, кем әйтмешли | Сөйләүче үз фикерен әйтә, башкаларның фикере белән кызыксына |
| Чынлап та, әлбәттә, дөрес, билгеле, бәхәссез, сүз дә юк | Сөйләүче фикерне хуплый, теләген белдерә |
| Гадәттә, билгеле булганча, табигый | Сөйләүче кемдер әйткән фикерне электән билгеле фикер итеп күрсәтергә тырыша |

| 1 | 2 |
|---|---|
| Мәсәлән, мисал өчен, беренчедән, икенчедән, өченчедән, әйтик, киресенчә, кыскасы, бер сүз белән әйткәндә, шулай булгач, шулай итеп, гомумән | Сөйләүче әйтелгән фикернең эчтәлегенә карата мөнәсәбәтен белдерә, йомгак ясый |
| Бәхеткә, кызганыч, валлаһи, билләһи, ичмасам, янәсе, имеш | Сөйләүче әйтелгән фикергә карата эмоциясен белдерә, кисәтә, шаярта, мыскыл итә |
| Бәлки, мөгаен, күрәсең, ихтимал, ахрысы, шәт, никтер | Сөйләүче әйтелгән фикернең дөреслеген шик астына куя |

Телгә өйрәнүчеләр һәм өйрәтүче катнашында, беренчедән, сөйләм калыбына *лексик материалны туплау* эше башкарыла: шушы сөйләшү темасы өчен кирәк булган сүзләр, сүзләрне үзара бәйләүче чаралар (бәйлекләр, теркәгечләр), тулы җөмләгә яки җөмлә составында кулланылган аерым бер сүзгә генә кайсы да булса мәгънә төсмере өсти торган махсус кисәкләр (кисәкчәләр), сорау кушымчалары туплана; икенчедән, тема буенча тупланган лексик материал катлаулырак формага — грамматик материалны туплау яссылыгына күчерелә: өйрәнүчеләргә җыйнак җөмлә калыбы (иясе — зат алмашлыклары, хәбәре затланышлы фигыль белән белдерелгән, ягъни үзара ярашкан баш кисәкләр) тәкъдим ителә. Реплика кайсы алмашлык белән башланганда, җөмләнең кайсы кушымчага тәмамлануы ачыклана.

Шуннан соң өйрәнүче бирелгән җыйнак җөмлә калыбына, лексик материаллар тупланган өлештән, бәрәмләп яки тиңдәш кисәкләр ясап, **кем белән?** соравына җавап бирүче үзе теләгән сүзләрне куя.

Бу мәкаләдә сөйләмгә өйрәтү технологиясенең тәмамланган кечкенә бер өлеше буларак, мисал өчен, **«Мин яшим»** темасы бирелә. Сөйләм калыбы, шушы җыйнак җөмлә моделен кулланып, өч этапта тулысынча формалаша. Беренче этапта **мин** (сөйләүче) **үзенең** *кем белән* яшәве турында сөйли.

***1 нче этап***

| Лексик материалны туплау<br>*Концентрация лексического материала* | Грамматик материалны туплау<br>*Концентрация грамматического материала* |
|---|---|
| **Керешмәләр**<br><br>кем?<br>**1**<br>**мин**<br>яшим — яшә́**ми**м<br>торам — то́р**мый**м<br>*живу — не живу* | Сөйләм төзү өчен<br>үрнәк җөмлә калыплары<br><br>**1**<br>**Мин** ...... кем **белән** ......... яшимме?<br>*Я ........ ... с кем .................... живу?*<br><br>**Мин** ...... кем **белән** ......... яшимме?!<br>*Я ....... .... с кем .................... живу?!* |

| сорау кушымчалары *вопросительные окончания* | | |
|---|---|---|
| -мы?<br>-ме? | -мы?!<br>-ме?! | -мыни?!<br>-мени?! |

| кисәкчәләр *частицы* | бәйлекләр *послелоги* | теркәгечләр *союзы* |
|---|---|---|
| генә<br>бит<br>ич | белән | һәм<br>дә<br>тагын<br>бары |

| кем белән? | | | *с кем?* |
|---|---|---|---|
| **1** | | | |
| мин | | | |
| әнием | | | *мамой* |
| әбием | | | *бабушкой* |
| этием | белән | *с* | *папой* |
| апам | | | *сестрой* |
| бабам | | | *дедушкой* |
| абыем | | | *братом* |
| сеңелем | | | *сестрёнкой* |
| энем | | | *братишкой* |
| дустым | | | *другом*<br>*подругой* |

| кем? |
|---|
| **1** |
| без |
| яши́без — яшә́мибез |
| тора́быз — то́рмыйбыз |
| *живём — не живём* |

минме? .............................. яшимме?
*я ? ........................................... живу?*

минме?! ............................ яшимме?!
*я ? ........................................... живу?*

кем белән? ..................... кем беләнме?
*с кем?............................ с кем?*

кем белән?! ................... кем беләнме?!
*с кем?............................ с кем?*

**1**
Мин ....... әнием белән ............. яшим.
*Я ................ с мамой ................. живу.*

Мин әнием һәм әтием белән .. яшим.
*Я ....... с мамой и папой .......... живу.*

Мин ... әнием белән генә .......... яшим.
*Я ........ с мамой только .......... живу.*

**1**
Без ....... әнием белән ............. яшибез.
*Мы .......... с мамой ................. живём.*

Без ....... әнием белән ............. яшибез.
*Мы .......... с мамой ................. живём.*

Без ... әнием белән ... генә ...... яшибез.
*Мы ...... с мамой ... только .... живём.*

Без .... әнием белән .............. яшәмибез.
*Мы ....... с мамой ................ не живём.*

Икенче этапта сөйләүче белән җавап бирүче затларның роле бик еш алышына: мин (сөйләүче) икенче затның кем белән яшәве белән кызыксына, димәк, аның кем белән яшәвен сорый. Икенче затның да беләсе килә: аның да сораган кешенең кем белән яшәвен беләсе килә. Сорый — беренче зат вазифасын башкара. Шулай итеп, сорау — җавап — сорау репликаларына нигезләнгән кара-каршы сөйләшү — диалог формалаша.

***2 нче этап***

<table>
<tr><th>Лексик материалны туплау<br>*Концентрация<br>лексического материала*</th><th>Грамматик материалны туплау<br>*Концентрация<br>грамматического материала*</th></tr>
<tr><td>
<table>
<tr><td>кем?</td></tr>
<tr><td>2</td></tr>
<tr><td>син</td></tr>
<tr><td>яшисең — яшәмисең</td></tr>
<tr><td>торасың — тормыйсың</td></tr>
<tr><td>живёшь — не живёшь</td></tr>
</table>
<br>
<table>
<tr><td colspan="2">кем белән?</td><td colspan="2">с кем?</td></tr>
<tr><td colspan="4">2</td></tr>
<tr><td colspan="4">син</td></tr>
<tr><td>әниең</td><td rowspan="8">белән</td><td rowspan="8">с</td><td>мамой</td></tr>
<tr><td>әбиең</td><td>бабушкой</td></tr>
<tr><td>әтиең</td><td>папой</td></tr>
<tr><td>апаң</td><td>сестрой</td></tr>
<tr><td>бабаң</td><td>дедушкой</td></tr>
<tr><td>абыең</td><td>братом</td></tr>
<tr><td>сеңелең</td><td>сестрёнкой</td></tr>
<tr><td>энең</td><td>братишкой</td></tr>
</table>
<br>
<table>
<tr><td colspan="4">билгесезлек кушымчалары</td></tr>
<tr><td>-дыр</td><td>-дер</td><td>-тыр</td><td>-тер</td></tr>
</table>
<br>
<table>
<tr><td>кем?</td></tr>
<tr><td>2</td></tr>
<tr><td>син</td></tr>
<tr><td>яшә — яшәмә</td></tr>
<tr><td>тора — торма</td></tr>
<tr><td>живи — не живи</td></tr>
</table>
</td><td>
Сөйләм төзү өчен үрнәк җөмлә калыплары<br><br>
2<br>
Марат, син ........ кем белән .... яшисең?<br>
Марат, ты .......... с кем ...... живёшь?<br><br>
яшисең ... яшисеңме? ... яшисеңмени?!<br>
живёшь ... живёшь? ........... живёшь?!<br><br>
Марат, син ... әниең белән ... яшисеңме?<br>
Марат, ты ..... с мамой ........ живёшь?<br><br>
Марат, син әниең белән ... яшисеңдер?<br>
Марат, ты с мамой живёшь,что ли?<br><br>
Марат, син әниең белән яшисеңмени?!<br>
Марат, ты с мамой ........... живёшь что ли?!<br><br>
Марат, син ... әниең белән ... яшәмисеңмени?!<br>
Марат, ты ... с мамой ............ не живёшь?!<br><br>
2<br>
Марат, син ........ әниең белән ....... яшә.<br>
Марат, ты ......... с мамой .......... живи.
</td></tr>
</table>

Өченче этапта I зат II зат ярдәме белән әңгәмәдә катнашмаган кеше (III зат) турында охшаш әчтәлекле белешмә ала, ягъни сөйләшүдә катнашучы затлар кемдер яхшы белгән, кайсыдыр бик үк яхшы белмәгән бер кеше турында, аның кем белән яшәве хакында сөйләшә, фикер алыша, киңәшләр бирә, яшәешенә карата мөнәсәбәтен белдерә.

**_3 нче этап_**

<table>
<tr><th>Лексик материалны туплау<br>*Концентрация лексического материала*</th><th>Грамматик материалны туплау<br>*Концентрация грамматического материала*</th></tr>
<tr><td>
<table>
<tr><td>кем?</td></tr>
<tr><td>3</td></tr>
<tr><td>Гүзәл<br>Марат<br>ул<br>алар<br>кемдер<br>кемнәрдер</td></tr>
<tr><td>яши — яшә́ми</td></tr>
<tr><td>тора — то́рмый</td></tr>
<tr><td>живут — не живут</td></tr>
</table>
</td><td>Сөйләм төзү өчен үрнәк җөмлә калыплары<br><br>3<br>Марат, Гүзәл ....... кем белән ....... яши?<br>Марат, Гузель ....... с кем ...... живёт?<br><br>яши ......... яшиме? ............. яшимени?!<br>живёт ... живёт? ................. живёт?!</td></tr>
<tr><td>
<table>
<tr><td colspan="2">кем белән?</td><td colspan="2">с кем?</td></tr>
<tr><td colspan="4">3</td></tr>
<tr><td colspan="4">ул<br>алар<br>кемдер<br>кемнәрдер</td></tr>
<tr><td>әнисе</td><td rowspan="8">белән</td><td rowspan="8">с</td><td>мамой</td></tr>
<tr><td>әбисе</td><td>бабушкой</td></tr>
<tr><td>әтисе</td><td>папой</td></tr>
<tr><td>апасы</td><td>сестрой</td></tr>
<tr><td>бабасы</td><td>дедушкой</td></tr>
<tr><td>абыйсы</td><td>братом</td></tr>
<tr><td>сеңлесе</td><td>сестрёнкой</td></tr>
<tr><td>энесе</td><td>братишкой</td></tr>
</table>
</td><td>3<br>улмы? .................................... Гүзәлме?<br>она? ......................................... Гузель?<br><br>кем белән? ...................... кем беләнме?<br>с кем? ........................... с кем?<br><br>Гүзәл ......... кем белән ............. яшиме?<br>Гузель .......... с кем ................ живёт?</td></tr>
<tr><td>
<table>
<tr><td>кем?</td></tr>
<tr><td>3</td></tr>
<tr><td>Гүзәл<br>Марат<br>ул<br>алар<br>кемдер<br>кемнәрдер</td></tr>
<tr><td>яшәсен — яшәмәсен</td></tr>
<tr><td>торсын — тормасын</td></tr>
<tr><td>пусть живёт — пусть не живёт</td></tr>
</table>
<table>
<tr><td colspan="4">билгесезлек кушымчалары</td></tr>
<tr><td>-дыр</td><td>-дер</td><td>-тыр</td><td>-тер</td></tr>
</table>
</td><td>3<br>Марат, ул — Гүзәл ... әнисе белән ... яшиме?<br>Марат, она — Гузель с мамой живёт?<br><br>Марат, Гүзәл әнисе белән яшимени?!<br>Марат, Гузель с мамой ....... живёт?!<br><br>Марат, ул ..... әнисе белән ..... яшидер?<br>Марат, она ... с мамой ... живёт, наверно?<br><br>Гүзәл ..... әнисе белән ..... яшәмиидер?<br>Гузель с мамой ... не живёт, наверно?<br><br>3<br>Марат, Гүзәл ... әнисе белән ... яшәсен.<br>Марат, Гузель с мамой пусть живёт?</td></tr>
</table>

***Максимов Николай Валентинович**, филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты доценты*

УДК 215:297

*Д.Р. Гыйльметдинов*

# ҖАН, КАН ВӘ ИМАН: Госманлы империясе вакытлы матбугатында «татар йөзен» чагылдырган төп чаткылар

*Статья посвящена исследованию силы и целостности национальной и религиозной традиции волго-уральских татар на примере их участия в общественно-политической жизни Османской империи периода её распада в начале XX века. Для анализа были взяты статьи, письма, речи, напечатанные в прессе религиозно-политической направленности, которая являлась единой площадкой для большого количества народов, исповедующих ислам.*

**Ключевые слова:** диалог культур, Османская империя, халифат, тюрко-татары, Габдерашит Ибрагимов, Халим Сабит, «Сират мустаким», татаро-турецкие связи.

Бүгенге татар халкының иң зур проблемасы — шәһәр катламы юклыгы. Шәһәр ул глобализация җимеше генә түгел. Ул — интеллектуаль, фәнни көчләрнең тупланмасы да. Билгеле, татарларның шәһәр инфраструктурасы Явыз Иван явыннан соң аякка басмады, торгызылмады, һәм дәүләт тарафыннан хупланмаган хәлдә калды. Әмма, гәрчә дәүләт һәм шәһәрләр булмасалар да, үз туган җирен ярату бөтен татарларда нык тамыр җәйгән. Моңа гасырлар буе давам иткән көчләү системасы да тәэсир ясамый калмаган әлбәттә. Татар мәдәнияте Октябрь инкыйлабына кадәр «консервацияләнгән» хәлдә булган күрәсең.

Билгеле булганча, XIX гасырның икенче яртысында Россиядә җәмгыять хәрәкәтләнә, сәяси эшчәнлек җәелдерә башлый. Татарларга да бу процесслар тәэсир ясамый калмаган. Иң көчле хәрәкәт ирексезләп чукындыруга каршы күтәрелгән. Милләт хисләре үсә барган саен, зыялыларның кайберләре — либераль, ә икенчеләре социалистик идеяләрне үз иткән. Мондый сәяси активлашуны матбугат заманы дип бәяләргә дә мөмкин. Кайбер галимнәр бу чорны «матбугат капитализмы» дип тә атаганнар [Андерсон]. Дини китапларны инде унтугызынчы гасырдан үк күпләп чыгара башлаганнар, әмма милләткә бу гына җитми башлаган. Мәгълүмат тарату, аралашу, җавап алу чарасы буларак, вакытлы матбугатка игътибар көчәйгән. Дәүләт рөхсәте булмаганга күрә, татарлар башка җирләрдә үз фикерен «бастыру юлларын» эзли башлыйлар.

Төркиядә госманлы телендәге беренчесе газета 1860 елда чыга башлый. Аларны җәелдерүчеләр исә Европа илләреннән укып кайткан дөньяви белемгә ия кешеләр булган. Алар күбрәк мәгърифәт идеяләрен таратырга омтылганнар. Беренче «патриотик» газеталар XX гасыр башында гына басыла башлый. Габделхәмид солтан «ислам бердәмлеге» сәясәтен алып барган. Шуңа да 1908 елгы «яшь төрекләр» инкыйлабына хәтле ис-

лам тәгълиматына нигезләнгән даими басмалар популярлык яулаган. Ататөрк чорына хәтле аларга ихтыяҗ кимемәгән. Төркичелек әләмен күтәргән газеталар элгәрләре дәрәҗәсенә ирешә алмаганнар [Koloğlu]. Россиядәге татарлар госманлы матбугаты турында хәбәрдар булганнар. Кайберләре хәтта аларны даими күзәтеп барганнар. Танылган җәмәгать эшлеклесе Габдерәшит Ибраһимов 1903 елда «Миръат» журналы сәхифәләренең берсендә «госманлы матбугатында рәһбәр [*зур шәхес, алып баручы*] булмау аркасында бер нинди мәсләк [*сукмак, юнәлеш*] юк» дип яза. 1911—14 елларда ул үзе Истанбулдагы ике журналның мөхәррире вазифасын башкарган. Чыннан да, татар зыялылары эшләгән мәгълүмат чаралары идеяләр, фикерләр муллыгы белән аерылып торган. Госманлы дәүләтендәге мәсләксезлекне безнең якташыбыз Гаяз Исхакый Россиядәге халыкларның принципиальлеге белән чагыштырып болай ди: «Һәр шәйдән мәхрүм була калсак, мәсләкемезе мөхафәзә идеерәз [*саклый алабыз*]. Бездә госманлы төрекләре кеби әлбисә [*киемнәрне*] дикешдерәҗасына [*алыштыруга*] мәсләк дикешдермәк һич юктер. Госманлы төрекләрендә тәгаммам идән [*таралган*] мәсләксезлек бездә юктер. Бондан башка без һәр шәй хакында ачык, мәгълүм фикерләр белмәке сөерез [*белергә яратабыз*] ... Без китаб хакында бер тәнкыйд язсак, бер гадәтемез хакында бер сүз сөйләсәк, бер фикер фәлсәфи хакында конышсак [*сөйләсәк*] ... һуб ачык, сарих конышмайе тәрҗих идеерәз [*җиткерәбез*]» [Исхакый, 1909, б. 62].

Истанбулга килгән зыялы милләттәшләребезнең һәркайсының милли мәсьәләләрдә үз юнәлеше, үз мәсләге булган, әмма куелган максатына карап, алар төрле нәтиҗәләрне күз алдында тотканнар. Бу язмада алар шартлы рәвештә, «җан», «кан» һәм «иман» дип билгеләнде. Болар — туган туфрагына (татар милләтенә), төрки тамырларына (төркичелек идеясенә) һәм ислам кыйммәтләренә күбрәк игътибар бирүне ассызыклый торган төшенчәләр. Госманлы матбугатында Россиядәге мөселман һәм татарлар тормышына кагылган материаллар имзасыз да басылып торган. Әмма фактлар сайлау, җирле халыкның аларны кабул итүе — башка тема. «Кан» га (ягъни, Европа фәненең асылына) игътибар арту 1911 елда күзәтелә. Бу елда Й. Акчура мөхәррирлегендә «Төрк йорду» («Төрек йорты») журналы оеша. Татарның милли аңы формалашуда бу басманың тәэсире зур була. Бу борылышта Г.-Р. Ибраһимов иҗатының да йогынтысы бихисап. Әмма «төркичелек», «тәңречелек», «туранчылык» идеяләре Госман империясе чикләрендә тулы рәвештә яклау таба алмаган булса кирәк.

Россия империясендә ислам диненә табынучы милләтләрнең саны егерме миллион чамасы тәшкил иткән. Алар арасыннан Россия уртасында яши торган татарлар гына, беренче булып, ислам динен кабул иткән һәм Россия составында иң озак яшәгән халык. Шуңа күрә Россия үзенчәлеге, «җир тәэсире» иң көчле шәкелдә аларда чагылыш тапкан. XIX гасыр Ильминский сәясәте хөкем сөргән Россиядә, азчылык халыкларга, урыс теле белән бергә, христиан дине һәм культурасы укытыла башлаган вакыт. 1905 елга хәтле дәүләт ислам диненә кайтучыларны хөкемгә тарта торган булган. Шушындый тәртипләргә каршылык йөзеннән XX гасыр башында Россия

мөселманнары арасыннан Госманлы солтанатына, «Дар сәгадәткә» һ.б. илләргә һиҗрәт итүчеләр саны кискен арткан. Анатолия ярымутравында, Финляндиядә һәм Россиягә чиктәш башка җирләрдә татар-мөселман диаспоралары оеша башлый. Шул ук вакытта Россиядә калган зыялылар госманлы матбугатына яза башлыйлар. Истанбулда беренче татар китабы унтыгызынчы йөзьеллыкның ахырында дөнья күрә. «Госманлы җирендә беренче татар студенты» [Тюркоглу, 2011, с. 89] Габдерәшит Ибраһимов «Чопан [Чулпан] йолдызы» әсәрендә Россиядә мөселманнарга карата көчләү сәясәте уздырылуын бәян итә. Әлбәттә, бу тема көндәлек матбугат битләрендә дә дәвам иткән. Икенче төр язмалар гомумән ислам тәгълиматына, аның бердәмлегенә, сәясәтенә кагылган. Өченче төр язмалар аерым мөселман милләтләре яшәешенә, Ислам бердәмлеген саклый торган хәлифәтне яклауга багышланган була.

Россиядән Истанбулга китеп белем алучы шәкертләр арта тора. Гаяз Исхакый әйткәнчә, акча булмау аркасында татар мәдрәсәләрендә яхшы белем бирү мөмкин булмый. Яшүсмерләр йә урыс мәктәпләренә, йә Истанбулга китәргә мәҗбүр итеlә [Исхакый, № 53, б.15]. Казандагы «Бәянелхак» журналында Габдерәшит Ибраһимов бер мәзәк хәл турында яза: «Бер вакыт Истанбулда әмир Тимур (Тамерлан) турында сәхнәләштерелгән тамашаны күрсәтәләр иде. Татар студентлары, тарихтан Тимурның болгар шәһәрләрен тар-мар итүен белеп, Тимурны хуплый торган спектакльне сәхнәдән төшерергә таләп итә. Татар студентлары саны шул кадәр зур булган күрәсең, тамашаны туктатырга мәҗбүр булалар» [Ибраһим, 1911, б. 3].

Идел татарлары төркеме нәрсә белән аерылып торган соң? Алар, госманлыларга караганда, күбрәк динне хөрмәт иткән, Россиянең басымына каршылык күрсәтә белгәннәр һәм интеллектуаль фикер йөртү өстенлегенә ия булганнар. Татарлар янәшәсенә азәрбайҗанлы Әхмәд Агаевны гына куярга була. Тик ул да бик күп аналитик язмаларны читләтеп, шигыйлар төркемендә булуы сәбәпleме, төп игътибарын Иранга юнәлтә. Кырым татарлары вәкиле Ягъкуб Камал исә күпчелек материалларын милли гадәтләргә, бидгатьләргә каршы, җиһадны яклап яза. Россиядәге каршылыклы, үзенчәлекле вазгыятьне шуннан килгән мөселманнар гына аклый алганнар. Әмма бу төркем Казан татарларыннан гына тормаган. Аларның яртысыннан күбрәген диярлек Себер, бүгенге көньяк Казакъстан, Урта Азия вәкилләре тәшкил иткән.

1908 елның ахырында «Сират мөстәкыйм» журналында Уфадан килгән ике материал (гарәп телендә) басылган (икенче мәкаләдә автор үзен «Г.» дип атаган). Исемсез һәм имзасыз беренче язмада «милләт» төшенчәсенә карата гомуми татар фикере чагылдырыла, дип әйтер идем. Башта автор, мөселман бердәмлек идеясен яклый торган хадисләргә нигезләп, Россиядә башка дин вәкилләре белән идарә иткән мохиттә мөселманнарга үз хакларын якларга авыр икәнлеген искәртә. Аннан соң ул гражданлыкның («җинсиять»нең), аерым дәүләт кануннарына буйсынуның исламга туры килмәгәнен әйтә. Ахырда ул, кешене нәфестән, шәхси мәнфәгатьләрен өстен куюдан, Коръән өйрәткәнчә, кавемнәр вә кабиләләр бердәмлекләре коткара ала, дигән фикерне дәлилли. Ягъни кешене

милли җәмгыять кенә дөрес юлда тота ала [Таҗетдин, 1908, № 118]. Уфадан җибәрелгән «Г». имзалы хатта ислам берлегенең өч өлеше — җомга намазлары, хаҗ мөрасиме һәм «Шура» (мөселманнар фикер алыша торган җыелыш) турында сүз бара. Мәгърифәткә ия булмаган өндәүчеләр — низаг чыгаручылар, «уймаклы» сәясәт шелтәләнә. Ахырда, ватанга хөрмәт аерым кешеләрнең бәхетле һәм канәгать булуыннан килә, дип ассызыклый билгесез автор. Минем уйлавымча, бу мәкаләнең максаты — Россия мөселман җәмәгатенә каршы чыгучы аерым кешеләрне үзгәртү.

Ислам бердәмлеге хисе татарларда аеруча көчле булган. Идел — Урал татарларында, гражданлылык идеяләре белән бергә, «мөселман экуменизмы»на омтылыш көчәя барган. Ул татарларда мәгърифәтчелек чоры «йолдызы» Ризаэддин Фәхретдин иҗатында зур урын алган. Дәүләтчелек булмаудан килеп туган хисләрен сублимацияләштерү (ачыклау, формалаштыру) чагылышы булган күрәсең. Әмма үз халкыннан аерылып, ерак илдә яшәгән татарлар «ислам теориясе»нә, нигездә, ирекле караганнар. Мәсәлән, шул ук Риза казый Госман империясендә хокуксыз булып саналган Мөхәммәд бине Габделваһһаб идеологиясен хуплап кабул иткән, аның үзен зур шәхес, исламны заманлаштыручы дип санаган. Ә без бу атаклы татар дин галимен үзен классик мөселман традициясен дәвам итүче буларак беләбез.

Риза казыйны Истанбулда да шундый итеп белгәннәр. «Ислам мәҗмугасы»нда Ибне Тайлиянең бүгенге көндә дә күп сораулар тудырган бердән-бер әсәрен бастырганнар. Госманлы матбугатына аннан башка да язучылар шактый була бит. Мәсәлән, иң активлардан Габдерәшит Ибраһимовны, Хәлим Сабитны, Троицк публицисты Әхмәд Таҗетдинне, Йосыф Акчураны, Гаяз Исхакыйны, Галимҗан Идрисины һәм Себердәге Вәлиулла Әнвәрине, Шир Идрисны, Гайшә ханымны атарга мөмкин. Г.-Р. Ибраһимны, Х. Сабитны һәм Й. Акчураны без чит мохиттә чыгып килүче татар басмаларының мөхәррирләре буларак та беләбез. Санап кителгәннәрнең күбесе Россиядәге татар матбугатында да иң актив катнашучылардан булганнар.

Габдерәшит Ибраһимов Россиядә классик «панисламист» булып танылып өлгергән шәхес. Шулай да, аның публицистик әсәрләре белән танышканнан соң, күңелгә бүтән фикерләр дә килә. Әйе, ул Европа илләре белән җиһад алып барырга чакырган һәм шәхсән госманлылар ягында Италиягә каршы сугышкан. Моны ул үз-үзен саклар өчен генә эшләгән, дип карарга да була. Россия һәм Төркия матбугатларында басылган мәкаләләрен чагыштырганда берничә кызыклы күзәтүләргә тап буласың. Г.Ибраһимов госманлы империясендә яшәүчеләрне башка илдәге мөселманнар көнкүреше, язмышы белән таныштыру максатын күздә тоткан булса кирәк. Ул бит соңгы көненә хәтле үз ватанындагы милләттәшләребез турында күбрәк борчылган. Россиядәге мәдрәсәләрне тикшереп йөргән [Гильмутдинов, 1913, с. 54—62], Исмәгыйль ага Гаспринскийны ул, гомумдөнья мөселман журналы «Әннәһда» чыгарганчы, аңа тотылган акчаны милләттәшләр өчен файдалансаң, отышлырак булыр иде, дип искәрткән [Ибраһим, 1908], гомеренең ахырында ул үз кулы белән язган «Намаз» дигән

китапчыгын Казанга җибәргән [Ибраһим, 1942]. Авторның Төркиядәге мәкаләләре, ничектер, төссез сыман, алар сәяси проблемаларга юнәлдерелгән. Чөнки ул анда мөселман сәясәтенең чишмә башында торган «Иттифак мөслимин» хәрәкәтен оештыручы булган. Андагы «катлаулы», үзенчәлекле вазгыять татар зыялыларын, күбрәк, җайлашырга мәҗбүр иткән күрәсең.

XX гасыр башында Россиядә дә, Төркиядә дә берничә инкыйлаб булып уза. Муса Бигиев уйлавынча, Россиянең тотрыксызлыгына исә Төркия инкыйлабы тәэсир ясаган [Бигиев, 1927, б. 132]. Гаяз Исхакый да шушы фикердә була. Россиядәге беренче — 1905 елгы инкыйлабны татарлар хуплап каршы алганнар. Г. Исхакый язганча, ул татарларга гражданлык хокуклары һәм тигезлек алып килгән [Исхакый, 1909, №56, б. 60]. Габдерәшит Ибраһимов та үзенең Петербургтагы «Өлфәт» журналында инкыйлаб заманы белән файдаланырга өнди [Ибраһим, 1907]. Әмма алга таба зыялы татарларның төрле инкыйлаблардан тәмам гаҗиз булганы сизелеп тора. Төркиядә 1908 елда солтан Габделхәмид төшерелгәннән соң, Габдерәшит Ибраһимов элеккеге солтан заманын сагынып искә ала, чөнки бөтен җирдә әхлаксызлык чәчәк ата башлый. «Инкыйлаб галәим» («Инкыйлаб галәмәтләре») мәкаләсендә Йосыф Акчура забастовкаларның зарарлары турында фикер күтәрә [Акчура,1908] (Й. Акчура М. Веберның тарихи концепциясен яклаган, ягъни, кешелек дөньясында прогресс дәүләт хезмәткәрләре катламы барлыкка килгәндә башлана, дигән.) Дин галиме Халим Сабит Иран һәм Йәмән чуалышларын руханилар котыртуы белән бәйли һәм, дәүләт белән дин бер-берсенең эшенә тыкшынмаска тиеш, дип саный. Димәк галимнәр хискә таянмыйча, рациональ фикер йөртә белергә тиешләр. Әмма егерменче гасыр башы руханилар катламының зәгыйфьлеге белән аерылып тора [Сабит, 1908].

Беренче дөнья сугышы бөтен мөселманнарны тетрәтә. Муса Бигиев, мәсәлән, Россия хөкүмәтендә коммунистик режимның ныгуын нәкъ менә сугыш китергән зәгыйфьлек белән бәйли [Бигиев, 1987]. Мөселман зыялылары Төркия—Германия союзына зур өмет баглыйлар. Әмма госманлылар солтаны тарафыннан игълан ителгән җиһад Италия белән сугышта да, Антанта белән көрәштә дә уңыш китерми. Госманлы империясенең җиңелүен һәм таркалуын Истанбул матбугатында бу хакта өметле фикерләрен язып чыккан татар зыялыларының да җиңелүе дип кабул итәргә туры килә. Чөнки аларның иң мөһим дошманы булган Англия Бөтендөнья сугышы вакытында астыртын гына үзенең көчен икеләтә арттыра. Төркия үзенең мөстәкыйльлеген саклап кала алса да, дөнья мөселманнары каршында үзенең абруен төшерә. Озакламый хәлифәлек тә бетерелә. Яңа оешкан Төркия Республикасында «беренче вәзир» вазифасын, «исламчылар» урынына, төркичелек идеологлары ала. Төркия матбугаты Россиядәге Октябрь инкыйлабына башта өмет белән карый, кимсетелгән милләтләр бердәм булса гына көчле дип саный [Галәм ислам...]. Әмма вакыт узган саен мөнәсәбәт тә үзгәрә. Һәм моңа татар фидакарьләре дә битараф кала алмый әлбәттә. Габдерәшит әфәнде үзенең «Коммунизм вә әдъян» («Коммунизм һәм диннәр») мәкаләләр

сериясендә коммунистик идеологияне «сионистлар уены» дип атый. Муса Бигиев «Коммунизм» мәкаләсендә аны йә «ясалма, акыл уеннары», йә балалык (ягъни, җавапсызлык) белән бәйләгән, әмма аның позитив ягын — динне дәүләттән аеруны — күрә алган. Бу фикер аның танылган «Ислам әлифбасы»нда үз урынын били. Әлеге мәкаләләр 1923 елдан соң гына күренә башлый. Вазгыятьне тиз төшендерә белгән Гаяз Исхакый 1918 елда ук Габдерәшит Ибраһимовка язган бер хатында коммунистларны — дошманнар, ә Галимҗан Ибраһимовны, Мулланур Вахитовны һәм башка революционерларны хыянәтчеләр, дип атаган [Исхакый, 1916].

Татарларда барлыкка килгән ике юнәлеш — модернизм («җәдидчелек») һәм консерваторлык («кадимчелек») Госман империясе җирлегендә күтәрелеп китә алмый. Чынлыкта, анда көчеп килгән зыялылар туган туфрагында хөкем сөргән агым буенча эш алып барганнар. Элеккеге исламны кайтару фикерләре исә, янәрыш идеяләре белән бертигез популяр булган. Мәсәлән, шул юнәлешнең иң актив тарафдары, Г.-Р. Ибраһимовның кардәше Әхмәт Таҗетдин «Дин вә мәгыйшәт» журналы турында язганда, бу караш тарафдарларын «фанатик»лар («тәгассыб») дип атамый, аларның фикерләренең дәлилле булуын гына тели [Таҗетдин, 1909]. Шушы журналның икенче бер санында ул театрны ахмаклык («сәфаһәт») дип атый [Таҗетдин, 1910]. Ә менә дин фикерен ныклап өйрәнгән М. Бигиев белән Х. Сабитны модернистлар сафына да кертеп булыр иде, ләкин Х. Сабит бик еш чын, элеккеге, «саляфлар» исламына кайтырга чакыра [Сабит, 1908]. Татар милләтенә, җанына һәм җиренә иң якын торган кеше — ул Гаяз Исхакый. Аның антиподы — Галимҗан Идриси. Беренчесе төрекләрне, язучыларны гавамга якынрак булырга, әдәбиятыбызны фарсы һәм гарәп сүзләреннән арындырырга өндәсә [Исхакый, 1909], икенчесен, киресенчә, татарлар арасында иң космополитик фикерле зат дип атарга була. Г. Исхакый Россия мөселманнары турындагы белешмә мәкаләләрендә Казан татарларын, илдәге иң алга киткән мөселман халкы, дип бәяли һәм аларның үз гадәтләренә, тамырларына бик нык, хәтта фанатизм чигенә җитеп бирелүе турында яза.

Ислам галимнәре, татарлар, башка халыклар белән чагыштырганда, гыйбадәттә күбрәк Коръәндәге кагыйдәләргә таяналар, дип белдерәләр. Әмма бу күренешнең асылын мантыйк һәм фәнни теорияләр нигезли. Бу Х. Сабитның фикер йөртү ысулында ачык чагыла. Аның ышануынча, бөтен галәмгә — камиллеккә омтылу, ә адәм баласына «фикри тәрбия» сыйфаты хас. Җәмгыять иминлекне һәм гаделлекне саклар өчен барлыкка килә, ул һәркемгә бурычны да, җаваплылыкны («вазифаны») да йөкли. Әмма инсаннар, табигатьләре буенча, күбрәк агрессиягә һәм шәһвәткә омтыла. Шушы түбән инстинктив хисләргә каршы көрәшнең дүрт юлы бар: җәза, намус (үз-үзен хөрмәт итү), кануннар һәм дини фикерләү. Беренчесе — пычрак һәм вәхши ысул (мәхкәмә карарында уртачылык юк). Кануннар аерым төркемнең генә мәнфәгатьләрен чагылдыра. Югары урыннарны һәрвакыт азгыннар яулый. Җәмгыятьтә битарафлык һәм эгоизм үсә бара. Намус катлаулы

хис. Бер яктан караганда, ул кешене начар гамәлләрдән саклый. Әмма чынлыкта ул төрле сурәтләр ала һәм аның мәгълүм чикләрен билгеләү кыен. Дәүләттәге «намус» сугышка ук этәрергә мөмкин. Ә мөселман өчен хиҗабсыз йөргән хатын намуссыз булып күренер. Намус исә, Х. Сабит уйлавынча, сәгадәтнең энергиясе («хамәсе»). Сәгадәт ул тормышта үзеңнең урыныңны табу (сәләтеңчә эшләү, дин юлында булу һ.б.). Синең намуссызлыгыңны әйләнәтирәңдәгеләр генә сизә ала. Шуңа күрә, намус та бик үк тотрыклы сыйфат түгел икән. Җәмгыятьләрне сугыштан нәрсә саклар соң? Аллаһны тану гына [Сабит, 1908]. Х. Сабит уйлавынча, ислам һәм иман — шәхси эш. Шулай да адәмне ялгыш юлдан саклап калуда җәмәгатьчелекнең роле чиксез. Кыскача әйткәндә, чын мөселман булыр өчен, иң мөһиме, шәригать кануннарын саклау зарур.

Татарлар, нигездә, динле булсалар да, ирекле, үз-фикерле, прогресс яклы милләт. Шулай да дини-сәяси карашларда төрле сыйфатларны табарга була. Зыялыларыбыз арасыннан, мәсәлән, гомер буе үзара дустанә мөнәсәбәттә булган Габдерәшит Ибраһимов белән Муса Бигиев хәлифәлек мәсьәләсендә, госманлылар солтаны тарафыннан игълан ителгән җиһад, хәтта ислам «футухатлары» (җирне яулау) буенча капма-каршы фикердә торганнар. Әмма татар мөселманнар арасында урта позициядә торучылар күбрәк булган.

Билгеле булганча, Мисыр мөфтие Мөхәммәд Габдо Каһирәнең әл-Әзһар университетында Европа тәртипләрен керткән. Бик көчле ислам тәгълиматын белүче Х. Сабитка исламны аңлауда һәм аның тәгълиматларын тормышта куллануда француз социологы Э. Дюркгейм идеяләренең ярдәме зур булган. Без Габдерәшит Ибраһимовның Карлейль, Драпер һәм Европаның башка мәшһүр зыялылары фикерләре белән таныш булуын беләбез. Андый белемгә ирешү бөтен мөселманнарның уртак җирендә — Госман империясенең башкаласында гына булырга мөмкин иде.

Сугыш һәм якынлашып килгән һәлакәт консерватив фикерле ике галимне — Мостафа Сабрины һәм Сәед Нурсине таныта. Алар икесе дә мөселманнарның эчке, әхлак мәсьәләләренә артык зур игътибар юнәлдерүләрен, дөньякүләм алдынгы карашлы татарларның теорияләрен кабул итмәгәннәр. Аларның традицияләре XX гасыр дәвамында үсә барган һәм бүгенге көндә дә бик күп яклаучыларын таба.

Нәтиҗәсе билгеле. Татарларның Төркиядәге диаспорасы үзенең «татарлыгын» югалтты диярлек. Модернизация чоры ике аерым агым барлыкка китерде. Татарлар урыслаша башлый, төрекләр европалаша, глобализациягә күбрәк авышып китә. Әмма, «татар эзе» төрек мәдәниятендә шактый урын алып тора. Татарларның тарихы турында төрек матбугатында материаллар юк диярлек. Мәдәнияте хакында да мәгълүматлар тар. Госман империясе ислам динен сәясәткә һәм теориягә бүлде, шуңа бәйле рәвештә татарларның «фокусы» югалып кала. Татарлар, туып үскән җире ерак булганга күрә, мохиткә яраклашканнар, әмма алар ислам дөньясы белән бик үк яхшы таныш булмаганнар күрәсең. Һәм шушы гына аларны бәладан коткарган да инде. Алар, башка милләтләр белән чагыштырганда, үз йөзләрен, милли үзенчәлекләрен саклый алганнар. Дин һәм милләт мәсьәләләре буенча аларның көндәшләре дә булмаган күрәсең.

**Әдәбият**


*Koloğlu O.* «tewspapers» In Encyclopedia of the Ottoman Empire. New York, 2009. pp. 431—434.

*А.И. [Акчура Йосыф]*. Галәим әл-инкыйлаб // Сират мөстәкыйм. Җ. 5. № 112. Б. 129—131. (1908. 17 ноябрь).

*Андерсон Б.* Воображаемые сообщества. М.: Канон-Пресс, 2001.

*Бигиев М.* Коммунизм (Галейһиндә Муса Җарулла әфәнденең нәшер итдеке китабы) // Сират мөстәкыйм. Җ. 23. № 581. Б. 132—137. (1927. 13 ноябрь).

Бисмилләһи-р-рахмани-р-рахим // Сират мөстәкыйм. Җ. 5. № 110. Б. 182-183. (1908, 8 декабрь).

Г. Бисмилләхи-р-рахмани-р-рахим // Сират мөстәкыйм. Җ 5. №118. Б. 231—234. (1908. 28 декабрь).

Галәм ислам вә большевиклар // Сират мөстәкыйм. Җ 20. № 511. Б. 197—201. (1922. 29 июль).

*Гильмутдинов Д.Р.* Система образования у российских мусульман в исторической перспективе (по материалам дневников, путевых заметок и других аналитических материалов Абдуррашида-казыя Ибрагимова) // Инновационные технологии в совершенствовании учебного процесса в мусульманских учебных заведениях: материалы международной научно-практической конференции. Казань. 2013. С. 54—62.

*Заки И.* Крымдан мәктүб // Мират. СПб. 1902. № 7. Б. 18—21.

*Ибраһим Г.-Р.* Инкыйлаб заманы белән файдаланыйк! // Өлфәт. 1907. № 65. Б. 1—2.

*Ибраһим Г.-Р.* Коммунизм вә әдъян // Сират мөстәкыйм. Җ 22. № 578. Б. 93—95. (1923. 6 декабрь); Җ. 23. № 580. Б. 127-128, № 582; 155-156; № 583. Б. 169-170; № 586. Б. 217-218 (1924. 11 гыйнвар).

*Ибраһим Г.-Р.* Төркиядә татарлар // Бәян әл-хак. 1911. №791. Б. 3.

*Ибраһим Г.-Р.* Мирза ага хыялы // Мират. Казан. 1908. № 22. Б. 6—9.

*Ибраһим Г.-Р.* Мөхәррирләр (Язучылар) // Мират. СПб. 1903. № 15. Б. 6—8.

*Ибраһим Г.-Р.* Намаз хуҗасы. Һәркем укыса аңларга мөмкин халис татар теле берлән язылган. Токио, 1942.

*Идриси Г.* Кавагыйд фикһия турында // Тәаруф әл-мөслимин. Җ. 2. № 25. Б. 5—6. (1910. 3 декабрь).

*[Исхакый] Гаяз Казанлы.* Лисан мәсьәләсе («Тәсвир әфкяр» мөхәррирләрендән Сөләйман Назыйф бәккә) // Сират мөстәкыйм. Җ. 2. № 46. Б. 316—317. (1909. 22 июль).

*[Исхакый] Гаяз Казанлы*. Русия мөселманнары // Сират мөстәкыйм. Җ. 3. № 53. Б. 14—16. (1909. 9 сентябрь); № 55. Б. 47—48; №56. Б. 60—62. (1909. 29 сентябрь).

*Исхакый Г.* Русия мөселманнарының мәшһүр мөхәррирләреннән Гаяз Исхакый әфәнде тарафыннан күндерелгән мәктүбедер // Сират әр-ришад. Җ. 14. № 362. 228 б. (1916. 8 август).

*Камал Я.* Дин вә гадат гайр мәшруга // Сират мөстәкыйм. Җ. 2. № 29. Б. 38—40. (1908. 21 март).

*Сабит Х.* Голәма вә гавам // Сират мөстәкыйм. Җ. 2. № 48. Б. 342—344. (1908, 11 август).

*Сабит Х.* Инсаниять, фикер дини, мәдәният //Сират мөстәкыйм. Җ. 1. № 2. Б. 27—30. (1908. 3 сентябрь).

*Таҗетдин Ә.* Тәсхих әфкяр (Оренбургта мөнташир «Дин вә мәгыйшат мәҗәлләсе) // Сират мөстәкыйм. Җ. 3. № 66. Б. 219—221. (1909. 8 декабрь).

*Таҗетдин Ә.* Театру намы вирелән сәфаһәтханәләр // Тәаруф әл-мөслимин. Җ. 1. № 12. 190 б. (1910. 2 сентябрь).

*Тюркоглу И.* Взаимоотношения Османской империи с мусульманами Волго-Уральского региона России (1876—1917): по османским архивным материалам // Волго-Уральский регион в имперском пространстве XVIII — XX вв. М.: Восточная литература, 2011. С. 82—93.

*Мәкалә ТР хөкүмәте фәнни грантлары кысаларында («Османская империя как «окно в Умму» для татар мусульман к. XIX — н. XX вв.», проект номеры 15-60 т/Г 2014) эшләнде.*

***Гыйльметдинов Данияр Рөстәм улы,***
*тарих фәннәре кандидаты,*
*Татарстан Фәннәр академиясе*
*Исламны өйрәнү үзәгенең чыганаклар бүлеге җитәкчесе*
*E-mail: ascoldan@gmail.com*

УДК 929

*З. Г. Гарипова*

# ГАБДЕЛХАК ГАЛИУЛЛИН (1919—1999)

Статья приурочена 95-летию со дня рождения Г.С. Галиуллина — известного ученого в области теоретической механики, основателя научной школы по изучению программного движения управляемых систем, нашего земляка, долгие годы возглавлявшего кафедру теоретической механики в Университете дружбы народов им. П. Лумумбы в Москве. В ней рассматриваются основные вехи его жизни и творчества, направления научной деятельности, открытия и достижения.

**Ключевые слова:** Г.С. Галиуллин, история науки, теоретическая механика, программное движение управляемых систем.

Габделхак Сафиулла улы Галиуллинның исеме Казан зыялылары даирәсендә генә түгел, ә Мәскәү-Россия һәм кайбер чит илләрдә дә билгеле. Татар галименең Мәскәүдәге Патрис Лумумба исемендәге Халыклар дуслыгы университеты тәкъдиме белән физика-математика факультетын һәм теоретик механика кафедрасын оештыруы һәм җитәкләве үзе үк игътибарга лаек.

Г. Галиуллинның балалык һәм яшьлек еллары Казан белән бәйле. 1919 елны татарлар яшәгән Яңа Бистәдә эшче гаиләсендә туа ул. Каюм Насыйри исемендәге атаклы 13 нче татар мәктәбендә укый. Аның сыйныфташлары — Харис Якупов һәм Лотфулла Фәттахов (булачак күренекле рәссамнәр), Җәвад Тәрҗеманов (галим һәм язучы) була. Габделхак мәктәптә укыганда Казанның Үзәк пионерлар клубында Абдулла Алиш оештырган әдәби түгәрәккә йөри, язучы белән якыннан аралаша. Татар әдәбияты укытучысы Шакир Нигъмәтуллин, «иҗекләре матур, малайдан язучы чыгар», дип сөенә. Габделхак язган шигырьләр һәм язма-мәкаләләр «Яшь ленинчы» газетасында, «Пионер каләме» журналында дөнья күрә. Аның бер шигыре «Шат балалык» исемле альманахта да урын алган. Габделхак, хәтта, Татарстан язучыларының беренче съездына делегат итеп сайлана һәм пионерлар исеменнән анда чыгыш та ясый.

«Безнең 13 нче мәктәптә әдәбият түгәрәге бар. Ул шактый яхшы эшли. Түгәрәк членнары әдәбият белән кызыксыналар... Әсәрләрдә тере маҗаралар да, юмор да җитми. Мин барлык пионерлар исеменнән әсәрләргә көлке моментлар күбрәк кертүегезне үтенәм. Рус әдәбиятында балалар өчен кызыклы китаплар бик күп, шуларның иң яхшылары татарчага тәрҗемә ителсеннәр иде... Безнең пионерларның акчасы юк. Китап бәяләре югары. Шулай булуына карамастан, тышлыклары шәптән түгел. Без нәшрияттан һәм Оргкомитеттан балалар китапларының техник яктан яхшы басылуын һәм арзан булуын үтенәбез...», — дип, яшүсмер трибунадан съезд делегатларына мөрәҗәгать итә. Президиумда утыручы Мәскәү кунаклары — драматурглар Александр

Николаевич Афиногенов һәм Владимир Михайлович Киршон — аның сөйләвен дикъкать белән һәм елмаеп тыңлыйлар. Драматургларның бу фактны һәм Габделхакның үзе хакында Алексей Максимович Горькийга сөйләгәннәре дә билгеле.

Яшь корреспондент «Известия» газетасына мәкалә язган. Аңа I Бөтенсоюз язучылар съездына делегат мандаты да бирелгән була, әмманиндидер сәбәпләр белән съездга бармый калган.

Мөгаллимә Илсөяр Сөнкишеваның шәхси архивында Габделхак Галиуллинга кагылышлы ядкәрләр саклана. Шуларның берсе — аны үз кулы белән язган «Һәрвакыт рәхмәтле һәм бурычлы без» мәкаләсе. «...Абдулла Алиш Казанда татар телендә чыгып килгән «Техника» журналы редакциясендә эшләде. Монда ул техника белән кызыксынучы балалар өчен дә материаллар бастыра, балаларның үзләрен дә журналда катнашырга чакыра иде. Шул максаттан чыгып, журналның соңгы битләрендә «Балалар бүлеге», «Яшь техниклар почмагы» исемле сәхифәләр биреп килде. Балалар белән очрашуларда да шул мәсьәләне күтәрә иде. Бервакыт ул безнең мәктәпкә «Техника» журналы вәкиле буларак килде. Залга җыелган укучылар алдында чыгыш ясап, «Техника» журналы, илебездә техниканың үсеше, уйлап табулар, бу өлкәдә кадрлар тәрбияләү кирәклеге турында бик мавыктыргыч һәм аңлаешлы итеп сөйләде, шул темаларга мәкаләләр язарга кушты.Ул көннәрдә без төрле планнар, хыяллар белән рухланып йөрдек, хәтта мәктәбебездә кече обсерватория төземәкче булып мәш килдек. Мөмкинлекләр бик чикле, шул эшләр белән шөгыльләнергә урыныбыз да юк иде. Безгә мәктәпнең чардагын бирделәр. Бер төркем малайлар, җыелып, шунда эшли башладык. Обсерватория үк төзи алмасак та, нәрсәләрдер эшләп йөрдек. Мин үзем телескоп ясадым һәм шул хакта язган мәкаләмне «Техника» журналына Алиш абыйга китердем. Озак та үтми басылып та чыкты. Бу минем техника темасына язган беренче мәкаләм иде. ... Безнең буын яшьләренә җан азыгы биргән 30 нчы еллар язучыларына һәрвакыт рәхмәтле һәм бурычлы без...» — дип язып калдырган булачак профессор.

Мәктәптә укыганда ук, 9 класстан Г. Галиуллин Казан дәүләт университетындагы профессор Григорьевның математика түгәрәгенә йөри. 1938 елда мәктәпне «бик яхшы» билгеләренә тәмамлап, университетка укырга керә. Бу 13 нче мәктәпнең математика укытучысы Хисам Садыйковның да уңышы була.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Казан университеты физика-математика факультетының 3 нче курс студенты Габделхак фронтка китә. Югары командование Г. Галиуллинны, укуын дәвам иттерү өчен, Жуковский исемендәге Хәрби-һава академиясенә җибәрә. 1944 елдан егет Совет Армиясе сафларында хезмәт итә.

Хәрби инженер дипломы аның киләчәк тормыш юлын билгели. 1946 елны туган шәһәренә әйләнеп кайткач, Казан авиация институтында (хәзерге Казан милли-тикшеренү техник университеты) инженер-механик һәм өлкән укытучы булып эшли башлый. Профессор Г.С. Салихов егеткә аспирантурага керергә киңәш бирә. Имтиханны Хәмит Мозаффар улы Мөштәри кабул итә. Г. Галиуллин 1947—1950 елларда аспирантурада танылган галим, КАИ ректоры Г.В. Каменков җитәкчелегендә кан-

дидатлык диссертациясе яза. Шунысы игътибарга лаек: аспирантураның 3 нче курсында ук, ягъни 1950 елда, диссертациясен уңышлы яклый!

Остазы Г.В. Каменков, шәкертенең талантын һәм фәнни кыюлыгын күреп, яшь галимгә автомат көйләү теориясе буенча (теория автоматического регулирования) яңа лекцияләр курсы эшләргә тәкъдим итә. 1950 еллар башында кибернетика өлкәсендә бәхәсләр әле тынмаганлыктан, проблема актуаль була.

Шушы ук елларда доцент Габделхак Галиуллинның программ хәрәкәтнең тотрыклылыгына, алмашынучан массаның җисемен тикшерүгә багышланган беренче фәнни хезмәтләре басылып чыга. Аларда үзгәрүчән массаның программ хәрәкәттә авырлык ноктасы табылу, координат һәм тизлеккә карата программ тотрыклылык шартлары ачыклана, массаның үзгәрү һәм алмашынучан массаның тизлек законнары билгеләнә. Бу мәсьәлә аның мәкаләләрендә үстерелә башлый [Галиуллин, 1953; Галиуллин, 1957; Галиуллин, 1958; Галиуллин, 1960].

Казан авиация институты докторлык диссертацияләре яклату хокукы алгач, 1958 елда беренче булып техник фәннәр докторы дәрәҗәсенә Галиуллин ирешә. «Идарә ителүче системаларның программ хәрәкәтендәге тотрыклылык» дигән фәнни проблема Казандагы Четаев фәнни мәктәбеннән үсеп чыга, шул ук вакытта Г. Галиуллин, фәндә беренче булып, үз юнәлешенә нигез сала.

1960 елда Г.С. Галиуллинның «Некоторые вопросы устойчивости программного движения» исемле монографиясе дөнья күрә. Аңа профессор Н.П. Еругин һәм башка авторлар менә мондый бәя бирәләр: «Анда программ хәрәкәт тотрыклылыгының гомуми проблемалары һәм аларны хәл итү юллары күрсәтелә, болар хәрәкәт программасының матди системадагы гомумиләштерелгән координатлары үзгәрү законыннан үсеп чыга һәм хәрәкәт белән идарә итү гомумиләштерелгән көч һәм системаның кайбер параметрлары үзгәрү белән бәйләп аңлатыла...» [Еругин].

1961 елда Габделхак Галиуллинны бер ел элек ачылган Патрис Лумумба исемендәге Халыклар дуслыгы университетына эшкә чакыралар. Ул анда физика-математика һәм табигыять фәннәре факультетын оештыра, 1961—1964 елларда аны җитәкли. Бер үк вакытта теоретик механика кафедрасы да булдыра, аларны үстерүгә зур көч куя. 27 ел дәвамында (1961—1988 елларда), кафедра мөдире вазыйфасын башкара.

Университет ел саен 88 илдән студентлар кабул итә. Кайбер лекция курсларын Габделхак Сафиулла улы инглиз телендә укый. Ливаннан килгән бер студент белән аны Тукай шигърияте якынлаштыра. «Яшьтән шигырьләр язу белән мавыгуы әле дә узмаган: ул шигырьләр яза. Шкафыннан Англия һәм Америка шигърияте антологиясен алып, үзе яраткан шигырьләрен яттан укый», — дип яза «Советская Татария» газетасының махсус корреспонденты В. Гудкова [Гудкова].

1960 еллар башында Г.С. Галиуллин югары уку йортлары өчен даими семинарлар оештырып җибәрә. Анда илебезнең күренекле галимнәре — математик һәм механиклар — теоретик механика проблемаларын тикшерәләр. Казаннан да күп кенә күренекле галимнәр, Мәскәүгә килеп, фәнни докладлар укып китә.

Ул елларда Г. Галиуллин һәм аның укучылары башкарган фәнни тикшеренүләр, тәҗрибәләрнең нәтиҗәләре «Построение систем программного движения» исемле коллектив монографиядә чагыла. Хезмәттәшләре һәм укучылары профессор Галиуллинның мавыгучанлыгын, фәнни хезмәтләрен беренче чиратта халык хуҗалыгы, икътисад ихтыяҗларыннан чыгып башкарганын аерып күрсәтәләр. Кул астында эшләүче хезмәттәшләреннән дә ул шуны, гамәли юнәлешле эшчәнлекне таләп итеп торган. Әйтик, Г. Галиуллин җитәкчелегендә каты матдәләрнең почмаклы хәрәкәтләре белән актив гироскоп һәм маховиклар ярдәмендә программ идарә итү мәсьәләләре чишелә, роботлар белән манипуляцияләп идарә итү проблемалары хәл ителә.

Халыклар дуслыгы университетында эшләгән елларында ул хәрәкәт тотрыклылыгы, аналитик механика буенча, шулай ук программ хәрәкәтләр белән идарә итү фәнни мәктәбен барлыкка китерә. Укучылары арасында утызлап фән кандидатлары һәм докторлары бар. Р.Г. Мөхәрләмов, И.А. Мөхәммәтҗанов, В.Д. Фурасов, А.Г. Александров, Л.Г. Червяков һ.б.лар Мәскәү, Казан, Саратов, Ереван, Алма-Ата, Ташкент һәм башка шәһәрләрдә эшлиләр.

Г.С. Галиуллин җитәкчелегендәге кандидатлык диссертациясе яклау Советы бик күп еллар уңышлы эшләп килгән. Бу эшнең ни дәрәҗәдә җаваплы булуын фән дөньясы яхшы белә. Шуның өстенә, башка күптөрле җәмәгать эшләрен алып барырга да туры килә аңа. Мәсәлән, ул берничә махсус совет әгъзасы (Спецсовет), Советлар Союзы чорында СССР Югары уку йортлары министрлыгы каршындагы теоретик механика буенча фәнни-методик мәкаләләр җыентыгы редколлегиясе әгъзасе, СССР Югары уку йортлары министрлыгы каршындагы методик совет Президиумы әгъзасы, «СССР — Алжир», «СССР — Иордания» иҗтимагый оешмаларының идарә әгъзасе. Болардан тыш, Чехословакия, Һиндстан, Болгария, Сурия университетларына барып, студентларга лекцияләр укый.

Шундый күп энергия һәм вакыт сарыф ителә торган эшләр, фәнни тикшеренүләр монографияләр бастыру белән үрелеп бара. Алар исә галимнең исемен дөньяга таныта [Галиуллин, 1965.; Галиуллин, 1969; Галиуллин, 1973; Галиуллин, 1981; Галиуллин, 1986; Галиуллин, 1989 һ.б.].

Шунысы сөенечле: Г.С. Галиуллинның олы хезмәтен, Азия, Африка, Латин Америкасы өчен кадрлар әзерләүгә керткән өлешен дә күздә тотып, һәрчак югары бәялиләр. 1969 елда аңа Хезмәт Кызыл Байрагы ордены тапшырыла, 1974 елда Атказанган фән һәм техника эшлеклесе исеменә лаек була. Әмма, ни аяныч, бу исем аңа докторлык диссертациясен яклаганнан соң (1958 ел) 16 ел узгач кына килеп ирешә (ул заманда бу исемне докторлык диссертациясе яклаганнан соң ук бирергә дә мөмкинлек була). Югыйсә, бу олы шәхес һәрчак тормышның, җәмгыятьнең алгы сафында, әйдәүчеләр рәтендә була.

Татар мохитендә тәрбияләнгән, татар мәктәбендә белем алган Габделхак Галиуллин үзеннән соң тирән матур эзләр, зур гыйльми мирас калдырып киткән шәхес. 2014 елда аңа 95 яшь тулган булыр иде. Истәлекле шушы датага бәйләп, аңа хөрмәт хисләребезне белдерик.

## Әдәбият

*Бәдретдинов Х.* Татарстаннан читтәге татар галимнәре. Йошкар-Ола, 2000. Б. 93—95.

*Галиуллин А.С.* Аналитическая динамика: учеб. пособие. для университетов и вузов. М.: Высшая школа, 1989.

*Галиуллин А.С.* Динамика механической системы. М.: Университет дружбы народов. им. Патриса Лумумбы, 1965.

*Галиуллин А.С.* К вопросу о правильности систем линейных дифференциальных уравнений // Труды КАИ. 1960. Вып. 59.

*Галиуллин А.С.* Об одной задаче устойчивости движения тяжелой точки переменной массы // Труды КАИ. 1953. Вып. 28.

*Галиуллин А.С.* Обратные задачи динамики. М.: Наука, 1981.

*Галиуллин А.С.* Построение уравнений программного движения управляемых систем. М., 1969.

*Галиуллин А.С.* Решение основной задачи внешней баллистики неуправляемых ракет при одном оптимальном режиме полета // Авиационная техника. 1958. № 4.

*Галиуллин А.С.* У устойчивости движения тяжелой точки переменной массы // Труды КАИ. 1957. Вып.37.

*Галиуллин А.С.* Устойчивость движения. М.: Университет дружбы народов им. Патриса Лумумбы, 1973.

*Галиулллин А.С.* Методы решения обратных задач динамики. М.: Наука, 1986.

*Гудкова В.* Всегда в сердце // Советская Татария. 1973. 13 марта.

*Еругин Н.П., Шестаков А.А., Демин В.Г.* һ.б. Абдельхак Сафиуллович Галиуллин // Дифференциальные уравнения: всесоюзный ежемесячный журнал. Минск. 1980. Том.XVI, № 5. С. 950.

*Хәмитов М.* Бәхетле язмыш // Казан утлары. 1972. № 6. Б. 97.

***Гарипова Зөбәрҗәт Газиз кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты*

УДК 929

*Л.Х. Хәмидуллин*

# ДӘРДЕМӘНД ДАИРӘСЕ

*Олуг шәхесебез тууының 155 еллыгына багышлыйм*

Статья посвящена исследованию деятельности татарской интеллигенции конца XIX — начала XX века, которая находилась в окружении братьев Рамиевых. В частности, особое внимание акцентировано на творческой деятельности Ризаэддина Фахретдинова, Фатиха Карими, Яруллы Валиева, Тимерши Соловьева-Саллави. Путем доказательств и уточнений, автор статьи корректирует данные, приведенные в татарской энциклопедии, татарских литературоведческих словарях.

**Ключевые слова:** история татарской литературы, персоналия, теория литературы, репрессии, татарская энциклопедия, издательская деятельность татарской интеллигенции.

Милләтебезнең рухи күтәрелеш чорында бу хәрәкәткә үз өлешләрен керткән шәхесләребез байтак. Дини, иҗтимагый-сәяси һәм тарихи хезмәтләре белән башка төрки халыклар арасында да дан казанган Шиһап Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйрилар тәрбиясендә үскән бер буын исә татар әдәбияты үсешенең яңа бер тармагын — роман, повесть, хикәяләр иҗат итү тармагын башлап җибәргән. Әдәбият гыйлемендә «чәчмә әсәрләр яки проза, драма әсәрләре» дип билгеләнгән бу өлкәдә иң беренче уңышка ирешкән авторларыбыз арасында иң күренеклеләреннән Пенза төбәге кешеләре Муса Акъегетзадә белән Заһир Бигиев санала. Аларның «Хисаметдин мелла» белән «Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә» романнары бербер артлы 1886, 1887 елларда Казанда дөнья күргән. Татарлар арасында беренче проза әсәрләре тууга рус һәм төрек әдәбиятлары үсеше дә үрнәк булган, этәргеч биргән, дигән фикерләр безнең әдәбият тарихын барлаучылар тарафыннан әйтелгәләде инде.

Шул фикерне дәлилләрдәй бер мисал буларак Дәрдемәнд һәм аның агасы Шакир Рәмиев хатларыннан берничә җөмлә китерү дә җитәдер мөгаен. Мәгълүм ки, Закир Рәмиев-Дәрдемәнд 1880—1881 елларда Төркиядә укып йөргән. Ике бертуган еш кына хат алышканнар. Менә Шакирның 1881 елда энесенә язган хатларыннан кайбер җөмләләр. «Безнең халык өстендә чапан, башында чалмасы булмаган кешенең сүзенә игътибар итми. Халыкка һәртөрле әхвәлне аңлата торган китапларны укырга кирәк. Шуңа күрә дә фәһем алырдай китапларны, романнарны күбрәк алып кайта күр», дип язган ул. Шул ук зыялылар арасында ул елларда: «Татарлар арасында хәзер чалмалы муллалар җитәрлек, чалмасыз муллаларга кытлык», дигәнрәк әйтем дә йөргән. «Чалмасыз муллалар»ның — киң белемле затларның халыкка файдалырак хезмәт итәчәге турында да, халыкның рухи үсеше өчен, дини, гыйльми китаплардан тыш, әдәби эчтәлекле хезмәтләрнең кирәклеге хакында да шулай хәбәрләшкәннәр ул чорның зыялы шәхесләре. Муса Акъегетзадә һәм аның чордашлары тудырган әдәби әсәрләрне укып үскән икенче, өченче буын

вәкилләре исә шушындый фикерләрне тирәнәйткән, баеткан әсәрләр тудырырга хыялланганнар.

Дәрдемәнд һәм аның абыйсы Шакир Рәмиев даирәсенә кергән, алар белән бер дәвердә яшәгән, кулгакул тотынып эшләгән шәхесләрнең кайберләренең XIX—XX гасырлар аралыгында ук әдәби әсәрләре белән танылганлыклары мәгълүм. Монда искә алыначак ул кешеләрнең барысы да диярлек Оренбург каласында яшәгән, алар тудырган әсәрләрнең дә күпчелеге шушы төбәктә иҗат ителгәннәр. Соңгырак елларда бу төбәкнең кайбер шәхесләре белән кискенрәк мөнәсәбәттә булган Гаяз Исхакыйның да узган гасыр башында берникадәр вакыт шунда яшәвен, «Хөсәения» мәдрәсәсе хәлфәсе булуын, кимендә ике әсәрен, шул исәптән «Ике йөз елдан соң иңкыйраз»ын шунда иҗат иткәнлеген таныырга тиешбез. Аның тәүге әсәрләреннән «Бай угылы» романы, «Ике гашыйк» комедиясе һәм ул чорда «озын хикәя» жанрында йөргән «Очрашу» әсәре дә шул шәһәрдәге «Кәримевләр басмаханәсе»ндә дөнья күргәннәр.

Сүзне Ризаэддин хәзрәт Фәхретдиновтан башлап җибәрик. Берничә дини-тәрбияви эчтәлекле китабы элгәрерәк язылган һәм чыгарылган булса да, аның төп иҗади хәзинәләре Оренбургта язылган һәм шундагы басмаханәләрдә нәшер ителгәннәр. Бертуган Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә аның кырыклап китабы, якын туганнары булган «Кәримевләр басмаханәсе»ндә егермеләбе басылып, төрки дөньяга таралганнар. Бертуган Рәмиевләр белән Уфада, мөфтияттә эшләгән еллардан ук дустанә мөнәсәбәттә булганлыгы турында хәзрәтнең үз истәлекләре сакланган. Моңа ул шәхесләрнең нәселе бер төбәктән булуы да, Рәмиевләрнең кайбер буын бабаларының дин әһелләре булуы да ярдәм иткәндер мөгаен. Риза хәзрәтнең яшьтәше Дәрдемәнднең бабалары да бит чыгышлары белән хәзерге Әлмәт районына кергән Тайсуган авылыннан. Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләрендә бу авылда XVIII йөз башында ук шул төбәктә танылган мәдрәсә эшләгәнлеге хәбәр ителә. 1913 елда «Шура» журналында бертуган Рәмиевләрнең шәҗәрәсе басылган. Анда аларның бабалары Габделкәримнең, яңа оеша башлаган Стәрлетамак өязенә күченеп киткәнче, «Тайсуган төбәгендәге бер авыл имамы» булуы теркәлгән. (Нишләптер, хәзерге Әлмәт төбәге түрәләре генә элекке алтын приискалары хуҗалары һәм танылган матбагачыларны — Рәмиев морзаларны үз төбәкләреннән чыккан шәхесләр дип танып бетерми шикелле.)

Ризаэддин хәзрәт Фәхретдиновның бертуган Рәмиевләр белән аралаша башлаган елларда дини, иҗтимагый-тарихи һәм тәрбияви эчтәлекле «Тәрбияле бала», «Тәрбияле ана» һ.б. хезмәтләре генә түгел, 1898 елда «Сәлимә, яки гыйффәт» исемле романы да нәшер ителгән була. Бераз соңрак аның тагын бер күләмле әсәре — «Әсма, яки гамәл вә җәза» бәяны дөнья күрә. Дөрес, ул вакытта әле бик күпләр ул әсәрләрне мөфтияттә эшләүче танылган дин вәкиле, казый Риза хәзрәт язган дип белмиләр. Чөнки ул әсәрләр әүвәл «Гафил бине Габдулла» тәхәллүсе белән басылганнар. Әмма шунысы гыйбрәтле, ул әсәрләрнең берсендә шагыйрь Дәрдемәнднең дә бер шигыре — «Үткән көннәр»е киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителгән була.. Ул дәвердә әле Дәрдемәнд тәхәллүсе белән шигырьләр иҗат

итүченең шәхсән кем икәнлеген бик күпләр, шул исәптән әлеге әсәрләр авторы да белмиләр. Уфада һәм Оренбургта даими рәвештә очрашкалап торган мизгелләрнең берсендә, ике автор да үз тәхәллүсләренең серләрен ачканнар булса кирәк. Әйе, мөфтият казые да ул елларда Оренбург төбәгенә еш килгәләп йөргән. Хөсәенев, Рәмиев кебек байлар тарафыннан җәдиди мәктәп-мәдрәсәләрне ачу тантаналарында да, андый уку йортларын ачарга каршы килүчеләрне күндерергә кирәк булганда аның сүзе зур роль уйнаган.

Ризаэддин хәзрәт «Тәрҗемәи хәлем» язмасында әдәби әсәрләр иҗат итәргә керешүе турында мондыйрак аңлатма бирә: «Сәлимә...» илә «Әсма»ны галимнәр җәмәгатеннән булган затлар сөймәделәр (сүз, әлбәттә, дин галимнәре турында бара. — *Л.Х.*). Әгәр дә минем әсәрем икәнен белгән булсалар, башыма кыямәтләр кубарачаклар иде. Фәкать авторлары билгеле булмаганлыктан, беркадәр сүрелделәр», — ди.

Аның «Сәлимә, яки гыйффәт» әсәре 1898 елда Казанда, «Әсма, яки гамәл вә җәза»сы 1904 елда Оренбургта басылып чыкканнар. Хәзрәтнең кызы Әсма Шәрәф этисенең бу күләмле әдәби әсәрләрен язарга керешүенең сәбәпләрен түбәндәгечә бәян итә: «Әткәйнең күп еллардан соң сөйләгән сүзләре: «Сәлимә...» белән «Әсманы...» язуыма сәбәп роман тәртип итү генә түгел иде, бәлки күңелгә урнашкан файдалы фикерләрне үз телебездә язып, укучыларга ирештерү иде».

Димәк, күпсанлы дини, иҗтимагый-тәрбияви эчтәлекле китапларында әйтеп бетерә алмаган фикерләрнең әдәби әсәр аша халыкка уңышлырак җиткерелүен аңлап эш иткән икән Риза хәзрәт. Сүз уңаенда шуны да искәртеп үтик, бөек акыл иясе алтышар, сигезәр табаклы әсәрләренең, гәрчә нәшер ителгән китапларында «хикәят» дип тамгалануына карамастан, жанр дәрәҗәсе буенча киңрәк, тулырак атамага ия булганлыгын да чамалаган икән. Хәер, хәзерге заман әдәбият галимнәре дә ул әсәрләрне повесть яисә роман дип билгеләү ягында. Фәкать «Әдипләребез» белешмәлегендә (2009) генә алар «хикәя» дип күрсәтелгәннәр. Күренекле әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов та Риза хәзрәт эшчәнлегенә багышланган конференциядә сөйләгән докладында ул әсәрләрне роман буларак бәяләгән иде. «Чыннан да һәр ике әсәр дә образларның бирелеше, вакыйгаларның бәян ителеше, идея эчтәлекләре белән роман дип аталырга лаек», дип яза ул шул конференциягә багышланган җыентык битләрендә («Ризаэддин Фәхретдин: мирасы һәм хәзерге заман», 2003, б. 152). Профессор Мөхәммәт Гайнуллин да «Татар әдәбияты тарихы»ның 2 нче томында урнаштырылган хезмәтендә ул әсәрләрне повесть буларак билгели һәм аларны бәяләп, «татар проза жанрын үстерүдә Р.Фәхретдиновның да зур өлеше бар», дип яза.

XIX йөз ахыры белән XX йөз башларында проза жанрында эшләүче язучылар саны бермә-бер арта. Оренбург төбәгенә бәйләнеше булган язучылардан бу чорда Гаяз Исхакый А.Пушкинның «Капитан кызы» һәм Н.Гогольның «Борынгы алпавытлар» әсәрләрен тәрҗемә кылып, каләм чарлау белән бергә, бер-бер артлы хикәя, бәян, романнарын да иҗат итәргә керешә. XIX гасыр ахырларында аның ике хикәясе, «Бай угылы» романы, «Өч хатын берлә тормыш» драмасы аерым-ае-

рым китап буларак басылып чыгалар. Фатих Кәрими дә бу елларда бик актив эшли. Ике гасыр аралыгында аның «Салих бабайның өйләнүе» (1897), «Җиһангир мәхдүм» (1900) хикәяләре, «Бер шәкерт илә студент» (1899) һәм «Морза кызы Фатыйма» (1901) повестьлары нәшер ителә. Соңрак «Хыялмы? Хакыйкатьме?» повесте (1908), «Аурупа сәяхәтнамәсе» (1902), «Кырымга сәяхәт» әсәре (1904) һәм Балкан сугышы вакыйгаларын чагылдырган «Истанбул мәктүбләре» китабы (1913) дөнья күрәләр. Ул шулай ук бер дистә чамасында дәреслек, ике дистәдән артыграк исемдә фәннипопуляр китап һәм тәрҗемәләр авторы да. Әдипнең, иң соңгы тәрҗемә хезмәте буларак, утызынчы еллар башындагы тагын бер эшен билгеләп үтәргә кирәктер. 1992 елда Г.Ибраһимовның мин төзеп чыгарган «Казакъ кызы» китабында олуг әдипнең Мәскәү түрәләренә атап русча язылган күләмле бер хатының тәрҗемәсе китерелде. Ул алда исеме аталган шушы романны русчага тәрҗемә итүче Фатих Кәрими хезмәтеннән канәгать булмавын белдерә. Аның кульъязмасын типографиягә төшерүгә мин каршы киләм, ул әсәрне рус әдәбиятын яхшырак белүче башка кеше тәрҗемә итәргә тиеш, ди. Ф.Кәриминең бу хезмәте шул рәвешле юкка чыгарыла. Әмма без аның шундый эшкә талпынып караганлыгын истә тотарга тиешбездер мөгаен.

Фатих белән бер үк елларда Чистайдагы Закир ишан хәзрәтләре мәдрәсәсендә белем алган Галиәсгар Гафуров-Чыгтай да аңардан калышмаска тырышкандыр күрәсең, тиздән матбугатта аның «Тутам» повесте дөнья күргән. Бу әсәрне язу чорында авторның Бозаулык шәһәрендә мәчет имамы булып торуын искә алырга тиешбез, һәм шушы яшь мулланың 1898 елда үз каласында, җәдиди ысулда укытуга керешкән яңа төр мәктәпләр ачуга күп көч түккән һәм күп акча тоткан Гани бай Хөсәенев белән берлектә, яңа ысул белән укытырга тиешле мөгаллимнәр курсын оештыруын да онытмасак икән.

Әлбәттә, бу елларда Дәрдемәнд, Ризаэддин хәзрәт, Г.Исхакый, Ф.Кәримиләрдән аерымрак төбәктән — Буа тирәләреннән чыккан Шакир Мөхәммәдевне һәм аның хезмәтләрен да атамый үтү гөнаһ булыр иде. Ике гасыр аралыгында ерак Харбин каласында гомер иткән Шакир да ( Оренбург янәшәсендәге Каргалыда мөгаллимнәр әзерләү мәктәбендә Фатих Кәрими курсларын үткән шәкерт) бер-бер артлы ике повестен бастырып чыгара: «Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр агай»ны — Казанда (1901), «Яфрак асты, яхуд Мәкәрҗә ярминкәсе»н — Оренбургта (1901). Шуннан соң ул янә Оренбургка кайтып төпләнә һәм шактый актив иҗат итә башлый, һәм, берара, шунда «Карчыга» исемле көлке-сатира журналын да нәшер итә. Ул 1923 елда шул калада гүр иясе дә була.

Безнең әдәбият гыйлемендә элек Оренбург төбәгендә яшәп иҗат иткән шәхесләрнең эшчәнлеген барлау өлкәсендә беркадәр сүлпәнлек сизелә кебек. Ә кайбер фактлар турында язганда төгәлсезлекләр дә очрап куйгалый. Узган ике гасыр аралыгында шул төбәктә яшәп иҗат иткән кайберәүләрнең әдәби эшчәнлеге, әдәби талпынышлары исә күп очракта телгә дә алынмыйлар. Мәсәлән, Г.Исхакый, С.Максуди, Х.Ямашевлар белән бер чорда Казан укытучылар мәктәбендә укыган, узган гасыр башларында

иҗат җимешләре беркадәр мәгълүм булган шәхесләрдән Габдерахман Дәүләтшин (бала чактан ук Әхмәт Хөсәенев өендә тәрбияләнгән), Шакир Мөхәммәдъяров (Орск шәһәрендә туган, Дәрдемәнд кебек үк, шундагы сәүдәгәр Борнаев кызына өйләнгән), Габдерәуф Ниязбаев (Оренбург янәшәсендәге Каргалы «каласы»нда туган) исемнәрен алыйк. Ул чорда бит аларның үз драма әсәрләре дә, А.Пушкин, Н.Гоголь, А.Островскийларның әсәрләреннән тәрҗемәләре дә яңа туып килүче театр сәхнәләреннән төшмичә уйналган, әдәбият, мәдәният темасына язган хезмәтләре газеталарда даими рәвештә басылып килгән. Болар төркеменә шул ук уку йортын тәмамлаган, иҗади хезмәткә бәйле еллары шул ук Оренбург каласында узган Тимерша Соловьевны да, кайбер истәлекләрдә «Бозаулык каласы сәүдәгәре» буларак кына теркәлгән Ярулла Вәлине дә кертергә хаклыбыз.

Татар энциклопедиясенең бер томында «матбагачы, журналист» буларак кына теркәлгән Тимерша Салаватулла улы Соловьевның да иҗат юлы хикәя, бәяннар иҗат итүдән башланган ич. Ниһаять, «Татарская энциклопедия» томнарының 5нчесендә (2010, 378 б.) аңа багышланган мәкаләне уку, өлешчә генә булса да, күңелне сөендерде. Димәк, ул да искә алынган. Ә «Әдипләребез» белешмәлегенә, нишләптер, аны кертмәгәннәр. Кайбер хезмәтләрен «Саллави» тәхәллүсе белән дә бастырган бу шәхеснең татар әдәбияты, татар мәдәнияте өлкәсендә хезмәтләре зурдыр. 1900 елда Оренбургта татарча басмаханә ачкан элекке ахун Гыйльман Кәримовның икенче кызы Гасыйманың ире, димәк ки Фатих Кәримигә дә, Риза хәзрәт Фәхретдингә дә кияү булган бу кеше байтак еллар «Кәримевләр басмаханәсе»нең мөдире дә булып тора ич. Бу басмаханәдә йөз җитмештән артыграк татарча китап басылган, дип саный китап белгечләре. Шуларның күпчелеге, минем исәпләвемчә, Казанда учительская школада белем алган Тимерша Саллави фатихасы белән чыккан булырга тиеш. Мәдрәсәләр өчен рус теле һәм әдәбияты хәлфәләрен әзерләүче әлеге мәктәптә ул елларда байтак кына булачак татар зыялылары укыганнар. Хәтернең иң өске өлешендә саклanганнарыннан Г.Исхакый, С.Максуди, Ш.Мөхәммәдъяров, Х.Ямашев, Ф.Туктарларны кабат атап үтү зыян итмәстер. Мәрхүм академик Әбрар ага Кәримуллин — татар телендә китап басу эшләрен төпле өйрәнгән шәхес. Ләкин Оренбург архивлары белән якыннанрак таныш булмау сәбәплеме, яисә «Кәримевләр басмаханәсе»н яшәтүчеләрдән Фатих Кәримигә күбрәк өстенлек бирергә теләүдәнме, «Тимершаһ кияү»нең эшчәнлеген ул беркадәр күләгәдәрәк калдыра кебек. Әбрар аганың Оренбург басмаханәләренә багышланган кайбер фикерләре белән килешмәвем турында инде мин хәбәр иткәләдем шикелле. Мәсәлән, ул, Рәмиевләр басмаханәсендә Риза Фәхретдиновның 24 китабы басылып чыккан, дип яза. Дөреслектә, алар 39 данә, диелә башка чыганакларда. 1999 елда нәшер ителгән соңгы китабында Әбрар ага Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсенең фактик хуҗасы Ф.Кәрими, нинди китапларга юл ачуны ул хәл иткән кебегрәк яза. Бер байга ялланган хезмәтче ничек хуҗасының мал-мөлкәтенә хуҗа була алсын икән? Бигрәк тә үзе дә әдәбият өлкәсендә каләм тибрәткән

хуҗаның кул астында эшләгән килеш? Шул ук китабында галим, «атасы вафатыннан соң Фатих Кәрими «Кәримевләр басмаханәсе»нең төп хуҗасы булып кала», китап басу тәртибен ул гына хәл итә, дигәнрәк фикер үткәрә. Дөрес, 1902 елның җәеннән 1906 елга чаклы басмаханә белән җитәкчелек итү Фатих мәхдүм карамагында була. Энеләре һәм «Тимершаһ кияү» ул чорда аның кул астында йөриләр. Әмма тиздән Гариф Кәримов — Мәскәү, Камиле Казан университетларында укый башлыйлар. Димәк, Оренбургтан китәләр. Кул көче кулланып эшләтелгән иске басмаханә ике кеше карамагында кала. Атасы вафат булгач (май, 1902 ел) элекке йортларын, сыер, атларын сатканнан һәм Шакир Рәмиевтән 3 мең сум акча алып торганнан соң, бу типографиягә икенче искерәк станок та алына. Ләкин уңышлы эшләп китү өчен ул чаралар да җитәрлек булмый, басмаханә зур табыш китерми. Алынган заказларны үтәү вакытлары бик еш кичектерелә, басма китапларның сыйфаты да күпләрне канәгатьләндерми. Шуның өстенә Ф.Кәримине 1906 елның февралендә «Вакыт» газетасы мөхәррире итеп билгелиләр. Үз басмаханәсе эше белән шөгыльләнергә вакыты калмавы сәбәпле, бу эштән ул бераз читләшә. Басмаханәгә иркенрәк бина, яңарак җиһазлар алу нияте белән алар сәүдәгәр Мәхмүд Хөсәенев гаиләсенә мөрәҗәгать итәләр. 1906 елда «Кәримев, Хөсәенев вә шөрәкясе» ширкәте оештырыла. Аның рәисе итеп Мәхмүд бай улы Хөсәен билгеләнә. Ул, нигездә, китап сатуны оештыру, башка төбәкләрдә (мәсәлән, Уфада) басмаханә филиалларын ачу һәм тоту өчен җаваплы була. Тимерша Соловьевка төп басмаханәнең мөдире вазифасын үтәү йөкләнә. Шуңа чаклы да ул инде басмаханә эше өчен җаваплы булган.

2000 елда «Рухият» нәшриятында нәшер ителгән «Фатих Кәрими» китабының 95нче битендә басылган бер истәлеккә күз төшерик. Истәлек авторы — Фатих мәхдүмнең иң кече сеңлесе Закирә, Казан матбагачылары Шәрәфләрнең кечесе — Борханы 1908 елда Оренбургка сөргенгә җибәрелгәч, шуңа кияүгә чыккан кыз. 1960 елда язган истәлегендә ул гасыр башындагы хәлләрне болайрак бәян итә: «Типографиягә Хөсәеневләр кушылгач, матди ягы бераз төзәлә. Алынган эшләрне вакытында өлгертү, пөхтәлек арта... Шул елның ахырындарак типографияне яңадан үстереп... бер юристның йортын арендага алып, чын техника белән эшли торган типография корып җибәрәләр... Шул чакта Фатих абзый, үз өлешендә булган пай акчасын алып, бөтенләй басмачылыктан чыга, аерыла. Кәрвансарай урамында кечерәк йорт сатып ала... (Шуннан соң) күбрәк вакытын өендә язу, тәрҗемәләр белән мәшгуль була, Шакир Рамиевнең өч баласын укыта.» (Ул яшәгән йортны барып күргәнем бар, бигүк кечкенә дип әйтмәс идем.) Әдип сеңлесе язмасының соңгы җөмләсен ачыклап китү сорала. Билгеле, Ф.Кәрими бу елларда өйдә генә утырмаган. Бу истәлектә аның сәгать икеләр тирәсенә чаклы «Вакыт» газетасы редакциясендә эшләп кайтканнан соң кылган гамәлләре бәян ителә. Закирә ханым Ф.Кәриминең «Кәримевләр басмаханәсе» ширкәтеннән чыгу вакытын төгәл әйтми, 1906 ел вакыйгаларына бәйләп кенә язып үтә. Башка бер чыганакта Ф.Кәриминең бу ширкәттән чыгу вакыты итеп 1909 елның беренче яртысы күрсәтелгән. Мөгаен, бу

вакытта инде ул «Тимершаһ кияү» белән дә басмаханә эшчәнлегенә бәйле мәсьәләләрдә килешә алмагандыр. Закирә ханым да бит әнә шул ук язмасында: « Озакламыйча Фатих абзый белән эшләгән наборщиклар да, мөдир белән килешә алмыйча, чыгып китәләр», — дип яза. Әмма мөдир җизнәнең исемен атап тормый.

«Татар энциклопедиясе» китабының татарча Знче томында: «1914 кә кадәр басмаханә белән Ф.Кәрими идарә итә», дигән сүзләр теркәлгән. Башка төр төгәлсезлекләр дә ул мәкаләгә хас. Әйтик, анда Ф.Кәриминең «100 гә якын китабы» үзләрендә басылган кебегрәк әйтелә. Дөреслектә, аның 1918 елга чаклы нәшер ителгән 60—70 ләп китабының берничәсе Казанда, Петербурта һәм 10 лабы, шул исәптән 450 битле «Истанбул мәктүбләре» Рәмиевләр басмаханәсендә чыкканнар. Димәк, бу мәкалә дә Әбрар аганың хаталарына нигезләнеп язылган булып чыга. Мәкалә авторы күрсәтелмәгән. Тимерша Саллавиның Кәримевләр басмаханәсендә тулы хуҗа булуы хакында Зариф Бәшири истәлекләрендә дә телгә алына («Замандашларым белән очрашулар», 1968).

Бу шәхеснең туган авылы хәзер Кайбыч төбәгенә караган Шуширмә була. Аның атасы Салаватулланың соңрак Апас тирәлегендә яшәвен әйтүчеләр дә бар. Тимершаның бер улы Казанда, икесе Мәскәүдә гомер иткән. Оренбург төбәге шәхесләрен барлаучы Мәдинә Рәхимкулованың 1980 еллар ахырында хәбәр итүенчә, Мәскәүдәге улларының берсендә Тимерша аганың зур архивы сакланган була. Анда «Шура», «Чүкеч» һ.б. мәҗмугалар төпләмәләре һәм «Вакыт» газетасы бәйләмнәре булган. 1993 елда, Мәскәүгә Бәшир Рәмиев белән очрашуга барганда, мин ул кешене эзләп тә караган идем. Мәдинә апа миңа аларның исемнәрен, телефоннарын язып биргән иде. Бу шәхеснең бер улының хатыны Мәрзия миңа ул ике бертуганның соңгы елларда вафат булулары турында әйтте. Архив сакланган өй хуҗасы соңгы вакытларда ялгыз яшәде, ул вафат булганда мин Казанда, туганнарымда кунакта идем. Архив иясе үлгәч, аның фатирын башка кешеләр алган, архивы юкка чыккан, дип сөйләде. Мөгаен, шулай булгандыр да. Тимерша ага үзе 1947 елда, җитмеш ике яшендә Мәскәүдә вафат була.

«Татарская энциклопедия»нең 5 нче томында, Тимерша агага багышланган мәкаләдәге «Ул Түбән Новгородта да яшәде, фәлән кунакханә мөдире булды», дигән җөмләне ачыклыйсы килә. Дөрес, бу шәһәрдә Әхмәт бай Хөсәенев зур бер кунакханә тоткан. Аннан килгән керемне «Хөсәения» мәдрәсәсен яшәтү өчен кулланган. Әхмәт бай исән чакта да, ул үлгәч тә (1906 ел) бу кунакханәнең исәп-хисап эшләрен шул байның конторасында да эшләүче Тимерша ага башкарган булса кирәк, һәрхәлдә, ул кайсыдыр елларда шул кунакханәнең мөдире вазифасын да үтәгән. Ләкин ул анда озаклап яшәдеме икән? Юк бугай. Белүемчә, аның вазифасы кунакханәне Мәкәрҗә ярминкәсе көннәренә әзерләү һәм ярминкә кунакларын урнаштыру, ашатуэчертү эшләрен күзәтүдән торган, һәм шул эшләрне башкаруда ярдәмләшү өчен ул, гадәттә, каникулга чыккан мәдрәсә шәкертләрен үзе белән ала торган булган. Гасыйма-Тимерша гаиләсенең бу шәһәрдә яшәве турында туганнары истәлекләрендә дә телгә алынмый.

Дөрес, җәйге айларда, ярминкә көннәрендә кунакханә мөдиренең анда гаиләсе белән яшәвенә берәү дә каршы килмәгәндер. Димәк, һәр елны алар гаиләсенең анда бер-ике ай торып кайтуы ихтималы зур. Гаилә башлыгының шул вазифаны башкарудан киткәч, аларның ул шәһәрдә яшәп калу-калмавын ачыклау кирәктер мөгаен.

Тимерша Соловьёв-Саллавиның китап рәвешен алган вә барланган әдәби иҗат үрнәкләреннән кесә дәфтәренә теркәлгән бер язмамда, аның беренче китабы «Хикәят» (1900), дип аталган дигәнмен. Энциклопедиядә, Марсель Әхмәтҗанов мәкаләсендә исә 4 китап исеме теркәлгән. Шуларның өчесе — әдәби эчтәлекле әсәрләрен туплаган «Мужик илә мулла...» (1902, Оренбург), «Биби Казан» (1905) һәм «Ишан Хәдичәсе» (1906). Болар хикәяме, кечерәк күләмле бәянмы (ул заманнарда бәянны «озын хикәя» рәвешендә дә тәкъдим иткәннәр), әллә соң романнармы — әйтә алмыйм. Әсәр жанрлары энциклопедиядә теркәлмәгән. «Мәктәп вә мәдрәсәләрне Духовное собраниегә бирү» китабы (1908), әлбәттә, безнең темага керми. Тимерша Саллавиның үзе нәшер иткән «Чүкеч» һәм башка мәҗмугалар битләрендә дә аерым әдәби парчалары, юмор-сатира әсәрләре басылган булырга мөмкин. Ләкин алар әлегә барланмаган булса кирәк. Узган гасыр башында Оренбургта чыккан татар матбугаты тарихы тупланган архив Кызыл Урда шәһәрендә саклана, дигән хәбәр бар. 1925 елда Казакъ Республикасы башкаласы Оренбургтан шул шәһәргә күчерелгән. Безнең галимнәрдән әлегә ул архив ишеген ачып керүчеләр турында ишеткәнем юк. Ә менә башкорт кардәшләрнең анда да барып җитешкән булуы ихтимал. Соңыннан Уфада яшәп иҗат иткән олуг шәхесләрдән Афзал Таһиров, Давыт Юлтый, Сәгыйть Агиш һ.б., шул исәптән «Башмагым» һәм шуның ише комедия әсәрләре тудырган Хәйбүш Ибрайларның башлангыч иҗат юлы Оренбург каласына бәйле ич.

Татар әдәбиятына багышланган хезмәтләрдә сирәгрәк искә алынган шәхесләрнең тагын берсе — Ярулла Вәли. «Татар әдәбияты тарихы» тупламасының 2нче томында (1985) аның исеме бер урында, Мөхәммәт ага Гайнуллинның «Драматургия» гә багышланган очеркында телгә алына. Ике гасыр аралыгында иҗат ителгән һәм китап буларак басылып чыккан проза әсәрләрен барлау, бәяләү бүлегендә исә ул автор бөтенләй дә искә алынмый.

Ә хәзер язучы Ярулла Вәли белән якыннанрак танышыйк. Элегрәк, «Татарстан хәбәрләре» газетасы күренеп алган бер мәлдә, ул шәхес турында кечерәк бер мәкаләм басылган иде. «Татар энциклопедиясе»нең русча һәм татарча чыккан вариантларында да шул мәкаләнең сөземтәсе бирелде. Газетада әлеге мәкалә басылганнан соң миңа Ярулла Вәлиулла улын якыннан белгән берничә кеше белән аралашырга, аның турында кызыклы истәлекләр ишетергә туры килде. Әмирхан ага Еники дә, үз биографиясенә бәйле вакыйгаларны тасвир иткән соңгы әсәрләренең берсендә Ярулла Вәли исемен бик җылы итеп искә алган. Яшүсмер елларында, Дәүләкәндә яшәгәндә мавыгып, йотлыгып укыган әсәрләре арасында бу язучының шактый күләмле «Үзеңә кайту» китабы булуын да бәян итә ул. Шушы юлларны укыгач мин Әмирхан абый

белән очрашып та сөйләшкән идем. «Язучы Ярулла Вәлине күреп тә белә идегезме әллә?» — дип тә сорадым. «Юк, якыннан таныш түгел идек. Аның хәл-әхвәлен болай гына, ишеткәләп кенә беләм»,— дип җавап биргән иде әдип. Ул яратып укыган «Үзеңә кайту» әсәренең жанры буенча повестьмы, романмы булырга тиешлеген, нәшер ителгән елы 1913 тирәсендәдер, дип әйтүен бер җирдә теркәп тә куйганмын. Әмирхан аганың «Ул китап минем өстәл өстендә озак ятты, кат-кат укыган идем мин аны. Күршедәге бер кызга күзем төшеп йөргән чаклар иде», — дип сөйләгәне хәтердә.

Узган гасыр башында Ярулла Вәли драма әсәрләре авторы рәвешендә дә бик популяр шәхес була. Аның ике драма әсәре — «Оят, яки Күз яше» белән «Ачлык кушты»сы ул чорда эшләгән барлык театр труппалары тарафыннан да сәхнәләштерелгән булса кирәк. «Сәйяр» труппасында бу ике әсәр китап рәвешендә басылып чыккан яисә, труппа эшли башлаган көннән үк диярлек, даими рәвештә уйналган. Сәхнә тормышына, сәхнә әсәрләрен иҗат итүче авторларга багышланган гаять тә бай эчтәлекле «Октябрьгә кадәрге татар театры» китабында (1988 ел, 398 бит. Авторлары Б.Гыйззәт, Һ.Мәхмүтов, И.Илялова) Ярулла Вәли һәм аның пьесалары исеме еш очрап тора. Менә 41 нче биттәге берничә җөмләгә күз төшереп алыйк (Казанда 1907 — 1910 елларда «Яшьләр» труппасы актив эшли): «1907 — 1908 елларда гына да алар Г.Исхакыйның «Ике гашыйк» һәм «Алдым-бирдем», Г.Камалның «Бәхетсез егет», Я.Вәлинең «Оят, яки Күз яше», Д.Таҗдаровның (чын исем-фамилиясе Габдерахман Дәүләтшин. — *Л.Х.*). «Яшь хатын» әсәрләрен сәхнәләштереп, шактый уңыш һәм популярлык казаналар.

Икенче бер урында, «Сәйяр» труппасының 1910 елда Чиләбе шәһәрендәге гастроле турында язганда: «Оят, яки Күз яше» драмасы аеруча уңыш китерә», дигән җөмләне дә укыйбыз. Бу әсәр, аерым китап буларак, Оренбургта 1902 елда Гыйльман Кәримев басмаханәсендә нәшер ителгән. Бу язучының аңа чаклы һәм аннан соң басылган әсәрләре дә, башлыча, шушы басмаханәдә дөнья күргәннәр: «Мәңгелек мәсҗед» — 1901 дә, «Әфиюн» —1906 да, «Җанлы җеназа», «Ахырызаман бәласы» һәм «Урман әүлиясы» — 1907 дә һәм «Ачлык кушты» драмасы — 1908 елда. «Әдипләребез» китабында алар хикәя буларак теркәлгәннәр. «Оят, яки Күз яше» драмасының басылып чыгу датасы бу белешмәлектә 7 елга кичектерелгән, гәрчә ул әсәр 1907 ел урталарыннан башлап берничә труппа тарафыннан сәхнәләштерелеп өлгергән булса да. «Шура» журналына багышлы хезмәтләрдә бу авторның тагын 1909 елда дөнья күргән «Каравыл тавы» нәсере булуы да әйтелгән. Алда хәбәр ителгәнчә, «Үзеңә кайту» әсәре башка жанрда язылган булырга тиеш.

Революциягә кадәрге татар театрлары тарихына багышланган китап битләренә тагын күз төшерик. 1908 елда басылып чыккан «Ачлык кушты»ны да шул чор театрлары үз иткән. Чөнки ул — татар кыз балаларының фаҗигале язмышын тасвирлаучы әсәр. Татар авылларында, ачлык елларында зур гаиләне ачлык фаҗигасеннән йолып калу ниятеннән чыгып, яшь кызларны үзбәк, төрекмән һ.б. байларга сату гадәте дә булган. Шул вакый-

галарга багышланган күләмле бер мәкаләсендә Мөхәммәд Мәһдиев тә андый гадәтнең хәзерге Татарстан төбәге авылларына хас булуын язган иде. Я.Вәлинең «Ачлык кушты» драмасында шундый аянычлы бер вакыйга бәян ителә, һәм, әлбәттә инде, ул әсәрне шул чор театр труппалары көтеп алган кебек була. Аны басылып чыккан елында ук сәхнәләштерә башлыйлар. Театр тормышына багышланган әлеге китаптан тагын берничә язма китерик. «Бу чорда драма әсәрләреннән Г.Исхакыйның «Мөгаллим», Г.Камалның «Уйнаш», Я.Вәлинең «Ачлык кушты», Ф.Әмирханның «Яшьләр»е аерылып тора... «Ачлык кушты» матбугатта күренү белән, Г.Камал һәм Ф.Әмирхан аңа карата зур-зур мәкаләләр язып чыгалар. Г.Камал бу драманың кыскарак булуын тели, сәхнәгә куяр өчен катлаулы эшләнгәнлегенә игътибар итә», — диелә китапта. — «Әсәрне сәхнәләштергәндә әлеге фикерләр искә алына. «Сәйяр» аны Төркестаннан кайтышлый беренче тапкыр Оренбургта күрсәтә... Аннары драма Казанда, Панаев бакчасындагы Җәйге театрда уйнала». Бу китапның «Йомгаклау» өлешендәге нәтиҗә чыгару җөмләсендә дә Я.Вәлинең исеме Ф.Бурнаш, Г.Исхакый, Г.Камал, К.Тинчурин, С.Рәмиев, М.Фәйзи, Г.Колахмәтов исемнәре белән бер төркемдә китерелгән.

1926 елда Мәскәүдә нәшер ителгән «Татар театры тарихыннан» китабында да (авторлары — режиссер В.Мортазин-Иманский һәм Т.Ченәкәй) Ярулла Вәли иҗаты югары бәяләнгән. «1907—1909 елларда «Сәйяр» труппасы күп кенә шәһәрләрдә гастрольләрдә булганда «Оят, яки Күз яше»н уйнаган. Шуның белән зур уңышка ирешкән». Мәкәрҗә ярминкәсендә 1907 елда беренче мәртәбә уйналганнан соң, татар һәм рус газеталарында аңа карата хуплау мәкаләләре басылып чыга. «Татар тормышыннан алып язылган, труппаның моңарчы куелган әсәрләреннән барыннан да яхшысы», дигән сүзләр дә була ул мәкаләләрдә.

1930 елларда, чит илдә яшәгәндә язган «Шималь төрекләренең әдәбиятына бер караш» хезмәтендә Гаяз Исхакый да язучылар исемлегендә Ярулла Вәлине үзеннән соң өченче урында теркәгән. «Г.Исхакыйдан соң берничә ел соңрак әдәбият мәйданына Г.Камал чыга», диелә дә, ике бит чамасы урында әдип Галиәсгар Камал иҗаты тасвирлана. Аннары: «Шул ук чорда Ярулла Әлвәли исемле бер язучы берничә хикәя, роман һәм пьеса яза. «Ачлык кушты» исемле пьесасы шактый зур уңыш казана. Ләкин... әдәби сәләте җитәрлек булмавы аркасында, язучы бик тиз арада әдәбият мәйданыннан сәүдә базарына күчеп урнаша», — дип яза автор. Шул рәвешле Г.Исхакый каләмдәше Я.Вәлинең унынчы еллар урталарында бай кызына өйләнеп, «байларга ялчы булуын» өнәмәвен дә, Оренбург төбәгендәге кайбер каләм әһелләре белән, даими рәвештә диярлек, килешми яшәгәнлеген дә сиздереп куя. Ул елларда бу ике шәхеснең бер-берсен тәнкыйтьләп язган язмалары матбугатта даими рәвештә калка торган. Ә Ярулла Вәли шул елларда Фатих мәхдүмнең якыннары исемлегендә йөргән шәхес.

Г.Исхакиның бу хезмәтендә Ярулла Вәлидән соң китерелгән язучылар исемлегенә дә күз төшереп үтик. Менә алар: әдипнең Казан укытучылар мәктәбе буенча шәриктәше, гасыр башы театрларында тәрҗемә әсәрләре даими рәвештә уйнал-

ган, шул чорның әдәби-мәдәни һәм иҗтимагый вакыйгаларына багышлап китаплар чыгарган, мәкаләләре белән катнашкан Шакир Мөхәммәдъяров, күренекле шагыйрьләр Г.Тукай, С.Рәмиев, Дәрдемәнд, М. Гафури, Н.Думави һ.б.

Алтмышынчы елларда Ярулла Вәлинең әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлегенә Исмәгыйль Рәмиев тә игътибар иткән. Вафаты алдыннан (1969) нәшрияткa тапшырган энциклопедик эчтәлекле, зур күләмле хезмәтендә Ярулла Вәлигә, «милли-либерал «Вакыт» һәм «Яңа вакыт» газеталарына багышланган аерым мәкаләләре бар. Язучы һәм тәҗрибәле мөхәррир Рәис Даутов бик кыйммәтле булган ул белешмәлекне 2001 елда «Әдәби сүзлек» исеме белән бастырып чыгарган иде.

Бөек әдип Г.Исхакыйның Ярулла Вәли иҗатына карата әйткән сүзләрендә, мөгаен, дөреслек тә бардыр. Чынлап та 1913 елдан соң Ярулла Вәли язудан туктаган, яңа әсәрләр иҗат итмәгән ахрысы. Әллә, кайнатасы Дәрдемәнд үрнәгендә, язганнарын китап рәвешенә китерергә ашыкмаганмы? Дәрдемәнд тә бит әнә, күпме язган югары сыйфатлы әсәрләре һәм кул астында иң заманча җиһазлы басмаханәсе була торып, үз әсәрләрен китап рәвешенә китерергә тырышмаган диярлек. 1910 елда аның балаларга багышланган юка бер китапчыгы гына чыгып калган.

Ярулла Вәлинең шул замандагы газеталарда, яисә мәҗмугаларда чыккан әсәрләре турында да әлегә хәбәр күренгәне булмады. 1913 еллар тирәсендә аның «буржуй» Закир Рәмиевнең кече кызы Зәйнәпкә өйләнүе — Исхаки язганча, «байларга ялчы булуы» иҗат итәргә комачаулаганмы? Әллә соң җилкәсенә өелгән җаваплы эшләрнең күплеге аны иҗат эшеннән аерганмы — әйтүе кыен. Бу вакытта бит ул «Вакыт» басмаханәсенең эше өчен җаваплылыкны үз өстенә алучыларның берсе була. Ә 1917 елгы түнтәрешләр чорында ул ярты ел чамасы «Вакыт» газетасының баш мөхәррире булып та торган. Шул вакыйгаларның чагылышына бер дәлил итеп, архив фондында сакланган бер телеграмма караламасын да күрсәтергә була. Ф.Кәрими аны сентябрь аенда шул чорда Чиләбе шәһәре тирәләрендәге приискасында булган Закир әфәнде Рәмиевкә юллаган: хезмәткәрләр баш күтәрә, эш хакын арттыруны таләп итә, дип. Шуннан соң озакламыйча Ф.Кәрими үз кәнәфиеннән төшерелә, шул шау-шулар нәтиҗәсендә «Яңа вакыт» газетасы барлыкка китерелә. Исмәгыйль Рәмиевнең «Әдәби сүзлек» белешмәлегендәге «Яңа вакыт» мәкаләсенә күз төшереп алыйк. «Ф.Кәрими вә аның фикердәшләре, әүвәлге «Вакыт» идарәсе белән килешә алмыйча, аны ташлап чыкканнан соң, «Яңа вакыт» тирәсенә оешалар. Наширләре (ягъни яңа хуҗалары) — Дәминев, Галәлетдинов. Газетаның фикри юнәлешен Ф.Кәрими болай билгели: газета вә аның мөхәррире бер партиягә дә мөнасиб социалист түгел, ул хөр фикерле тәрәккъыйчы ... милләтчедер.» Газета 1917 елның 1 ноябреннән 1918 елның 3 октябренәчә нәшер ителгән.

Шул ук китапның 61 нче битендә И. Рәми: «1917 елны «Вакыт» газетасы мөхәррирлеге Ярулла Вәли кулына күчте», дип яза. Ул үзгәрешнең кайсы айда булганлыгын хәбәр итми.

1908 елда бертуган Рәмиевләр Дәрдемәнд яшәгән йорт янәшәсендә (арткы урамда) бер иркен бина бул-

дырып, шунда үз басмаханәләрен җиһазлауга керешәләр. Типография җиһазларын, сыйфатлы буяуларны чит илләрдән кайтарталар. Шул заман матбугатында берәр төрле хәбәр булгандырмы, юкмы — минем уйлавымча, баштарак ул басмаханәнең эшләрен җайга салу Кырым татары Нури Акчокраклыга йөкләнгән булса кирәк. Ә бераздан соң инде ул йөкне Ярулла Вәлиев җилкәсенә «аударганнардыр». Әлегә мин Я.Вәлинең кайчаннан ул басмаханәгә мөдир булганлыгын төгәл күрсәтүче язманы очратмадым. Ә аның 1910 елларда шул вазифаны башкаруы турында хәбәрләр күренгәләде. 1918 елның февралендә «Вакыт» басмаханәсе белән нәшриятын Совет хакимияте вәкилләренә тапшыру барышында Закир Рәмиев (Дәрдемәнд) белән Ярулла Вәли катнашканнар. Шул хакта истәлекләр бар.

Әлеге Кырым өлкәсе кешесе — Н. Акчокраклы белән танышып үтик. XIX йөз ахырларында аның Петербургта Ильяс Бораганский (шулай ук Кырымда, Бакчасарайда туган шәхес) басмаханәсендә эшләгәнлеге мәгълүм. Бу кеше оештырган нәшрият белән басмаханәдә безнең олугларыбызның бер дистәдән артыграк чамада китаплары басылып чыгуы да мәгълүм. Ф.Кәриминең «Аурупа сәяхәтнамәсе», Р.Фәхретдиновның «Мәгашәрәт адабе», К.Мотыйгыйның ике китабы — «Бәхетле Мәрьям» романы һәм хикәяләр тупламасы һ.б., казакъ әдәбияты классигы Абайның тәүге тапкыр дөнья күргән шигырь һәм поэмалар җыентыгы һ.б.

Европа илләре буйлап эшлекле сәяхәткә чыгып китәр алдыннан, 1899 елның март ае башында, Шакир Рәмиев һәм аның юлдашы, тәрҗемәчесе Ф.Кәрими берничә көн илнең башкаласы белән танышып йөриләр. Патша сараен саклаучы һәм патшаларны һәм гаиләләрен саклап, озатып йөрүче мөселмен гаскәриләре ахуны Гатаулла Баязитов, Россия тимер юлларының көньяк һәм көнбатыш юнәлешләрендәге күпчелек вокзал буфет-ресторіаннарын тотучы бай сәүдәгәр Максудовлар белән очрашалар. (Хәтерләсәгез, 1912 елда Г.Ибраһимов Киев шәһәренә нәкъ шушы Максудовлар нәселеннән булган берәүнең балаларын татарча укытырга дип бара.) Башкаланың музей, китапханәләрендә, Фәннәр академиясендә булалар. «4 март, якшәмбе көн, Петербургта матбага исламия имтиязы (тоту рөхсәте) алган морза Бораганский илә күрешергә бардык,» дип яза Ф.Кәрими «Аурупа сәяхәтнамәсе» китабында. Басмаханә эшчәнлеге белән танышып йөргәндә әлеге Нури әфәнде белән дә очрашалар, ул иҗат иткән тарихи һәм җәмгыяви эчтәлекле китаплар белән дә танышалар. Ул вакытта бу кеше әлеге нәшриятның әдәби мөхәррире вазифасын үтәгән. «Госман Нури Акчокраклызадә — Кырымның Бакчасарай бәлдәсеннән (шәһәреннән). Бу зат исламча вә русчадан гүзәл хәбәрдар булып, гүзәл язмыш булдыгы «Бакчасарай чишмәсе», «Тәнкәҗан ханым» (Туктамыш хан кызы), «Мөләхаза» исемле әсәрләреннән мәгълүмдер», дип таныштыра әлеге сәяхәтнамәне укучыны автор.

Шушы кешене соңрак Оренбургка Шакир әфәнде үземе, әллә Фатихмы чакырып китергән булырга тиеш. Аның анда килүе «Вакыт» басмаханәсенең ачылыш вакытларына туры китерелә. Шул елда алынган бер фотода ул Риза Фәхретдинов белән Дәрдемәнд арасында басып

төшкән. Аның янәшәсендә үк Ярулла Вәли дә басып тора. Рәмиевләр басмаханәсе ачылгач, Ярулла Вәлигә «Вакыт» газетасы белән Шура»га кагылышлы хуҗалык һәм финанс эшләрен үтәүдән тыш, яңа бурычлар да йөкләнгән. Ә инде беркадәр соңрак аны «Вакыт» басмаханәсенең мөдире итеп куялар. Шул вазифаны үтәгән вакытта ул Зәйнәп Рәмиевага өйләнә. Әмма кайчан? Бу кадәресен, мөгаен, «Вакыт» газетасы битләреннән укып белергә буладыр. Шунысы хак, 1914 елда аларның улы Баязид (1942 дә сугышта һәлак була), 1918 дә кызлары Асия туган. Асия 1979 елда Уфада вафат була. Зәйнәп Рәмиева да шул шәһәрдә кызы кулында 1977 елда бакыйлыкка күчә.

Хәзер Рәмиевләрнең «Вакыт» газетасында (1906—1918, февр.), соңрак шул исемдә ачылган «Вакыт» нәшрияты һәм басмаханәсе»ндә (1909—1918, февр.), «Шура» журналында (1908—1918) эшләгән шәхесләрне берәмләбрәк барлап үтик. Мәгълүм ки, бу басмаханәләрне ачучы һәм үз хисапларына тотучы бертуган Шакир вә Закир Рәмиевләр, әлбәттә, үз даирәләренә хөр фикерле һәм укымышлырак шәхесләрне якынайтырга тырышканнар. Татарстан Республикасы Милли Дәүләт архивының Кремль урамында урнашкан бинасында бу басмаларга кагылышлы бай бер фонд бар. Дәрдемәнд биографиясенә һәм эшчәнлегенә кагылышлы документларны барлаганда, анда миңа фотограф Зөфәр Бәширов белән булырга туры килде. Дөрес, безгә чаклы ул фондта сакланган документлар белән әдәбият галиме Мөхәммәт ага Гайнуллиның танышкан булуы турында да анда мәгълүмат бар иде. Сиксәненче елларда миңа ул 1370 санлы фондның барлыгын әдәбият галиме, мәрхүм Альберт Фәтхи әйткән иде. Ул фондка тупланган иллегә якын хат һәм утыз-кырыклап төрле документны яисә аларның копияләрен 1971 елда Закирә Шәрәф яисә аларның варислары тапшырган булгандыр. Зөфәр Бәширов белән бергә «Дәрдемәнд» альбомын бастырып чыгарырга әзерләнгәндә (ул 1990 еллар башында ук нәшрият планына кертелгән иде, илдә башланган үзгәрешләр, хаос нәтиҗәсендә исә ун елга соңлап борын төртте) шул фондтан төшереп алынган кайбер документларны кулландык. Соңрак та төшереп алган ул фотоматериалларның байтак өлеше «Бертуган Рәмиевләр» (2002), «Дәрдемәнд. Агарган кыл» (1999), «Фатих Кәрими» (2000) һ.б. китапларда урын алды. Шушы ук фондта теркәлгән бер документта Рәмиевләр басмаханәсенең 1908 елның ахырларында ук эшли башлаганлыгы турында да мәгълүмат бар. Декабрьдә бу басмаханәдә Ризаэддин Фәхретдиновның дини эчтәлекле «Гакыйдә» (ышану) исемле китабы басылып чыга.

Әбрар Кәримуллиның «Рәмиевләр басмаханәсенең төп хуҗасы Фатих Кәрими» дигән сүзләрендә өлешчә хаклык та бар. Бу фондтагы документлар белән танышкач та шул фикергә киләсең. Рәмиевләр матбагасының барлык тармагында диярлек төп эш башкаручылар аның кешеләре яки аның туганнары. Рәмиевләр аңа хезмәткәрләрне үзенә сайларга ирек биргәннәр. Билгеле инде, ул сайлау хуҗалар белән килешеп башкарылган. «Вакыт» газетасының губернатор канцеляриясе тарафыннан расланган исемлегендә баш мөхәррирнең бе-

ренче урынбасары Ризаэддин Фәхретдинов булганлыгын күрербез. Ваграк хезмәт үтәүчеләр исемлегендә Фатих мәхдүмнең энесе Камил дә, энисенең бертуганының улы, Риза хәзрәтнең уллары да теркәлгән.

Риза хәзрәтнең тагын бер хезмәтенә тукталу урынлы булыр. Туксанынчы елларда ул Оренбург янәшәсендәге Каргалы авылына багышлап (авылның беренче рәсми исемен истә тотып) «Сәгыйд» исемле китабын язып бастырган. Дин, гыйлем, тәрбия өлкәсенә багышлы ике дистәләп китап язып чыгарган хәзрәтне, Оренбургка күчеп килергә дип, бертуган Рәмиевләр үзләре кодалаган, һәм 1906 елның җәй урталарында Оренбургка килгәч тә, аның ишле гаиләсен матбугат хезмәткәрләре өчен дип төзелгән, Шакир Рәмиев йортына янәшәдә булган йортка урнаштырганнар. Өч бүлектән, өч секциядән торган бер катлы ул өйнең ике өлешендә Риза хәзрәт гаиләсе, тагын берсендә башка мөхәррирләр яшәгән. Шәһәр театры артындарак урнашкан ул йортның өченче өлешендә төрле елларда Рәмиевләр тарафыннан чакырып китерелгән кешеләрдән Ярулла Вәли, Борһан Шәрәф, Шәриф Камал, Кәбир Бәкер дә яшәп алганнар. Рәмиевләр матбагасына эшкә билгеләнүчеләр турында губернатор канцеляриясенә юлланган документларның кайберләрендә «живёт на улице Эссенской в доме Рамиевых» дигән сүзләр теркәлгән. Риза хәзрәтнең кызы Әсма Шәрәф (ул матбагачы Шәрәфләрнең иң кече энесендә — Галимҗанда кияүдә була) истәлекләрен карыйк. Оренбургта узган балачагын ул болай искә төшерә. Әлеге ике йорт арасында «Шакир бай»ның зур җимеш бакчасы гына булып, җәйге айларда, төп хуҗалар алтын приискаларындагы йортларында җәйне үткәргәндә, әлеге бакча, тулаем диярлек, хәзрәт гаиләсе карамагында кала. «Шул бакча эчендә безнең беседка бар иде, — дип искә ала Әсма апа. — Май аеннан сентябрь аена чаклы без шунда ашап, эчеп тора идек». 1908 ел башыннан Р. Фәхретдинов «Шура» мәҗмугасы мөхәррире итеп билгеләнә. Аның эш бүлмәсе дә шушы ук өйнең элекке «эш кабинеты»нда урнаша. Ә «Вакыт»ның икенче редакторы эшен үтәү аның улы Габдерахманга йөкләнә..

1908 елда Казанда, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә сәяси шау-шу чыгып, мәдрәсә башлыгы Галимҗан Баруди Вологда губернасына, башка мөгаллимнәр кайсы-кая сөргенгә җибәреләләр. Патша заманында, гадәттә, гаебе зуррак булганнарны шулай төньяк тарафка, гаепләре кечерәк саналганнарны туган якларына озата торган булганнар. Шул ук елларда Казанда Г.Исхакый төркеменә карата да җәза карары чыгарыла. Гаяз әфәндене еракларак олактыралар, ә аның төркеменнән кайберәүләргә фәкать «Казанда яшәргә рөхсәт итмәү» җәзасы гына бирелә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә бәйле вакыйгада да «яшь хәлфә һәм журналист» Борһан Шәрәф Казанда яшәү хокукыннан мәхрүм ителә. Ләкин ул башка кайберәүләр кебек туган төбәгенә — Сембер губернасының Буа өязендәге туган авылына кайтырга теләми. Казан матбагачылары Шәрәфләр дә энеләренә җылырак, төшемлерәк урын сайлаганнардыр күрәсең. Рәмиевләр белән элемтәгә кереп, аны «Вакыт» газетасына эшкә урнаштыралар. Тиз генә арада ул «Вакыт» мөхәрриренең беренче урынбсары (икенче мөхәррир) урындыгына да

утыртыла. Ф.Кәриминең сеңлесе Закирәгә өйләнә. Б.Шәрәфнең Казанда яшәү чорында ук каләм тибрәтә башлавы, газета-журналларга язышып торуы мәгълүм. Монда килгәч тә ул андыйга һәвәслеген онытмый, актив языша. Шул елларда «Вакыт» басмаханәсендә Борһан «Иран мәктүбләре» (1909) һәм «Гани бай» (1913) исемендә китаплар да нәшер итә. Ул туплап чыгарган һәм М. Рәхимкулова тарафыннан 1998 елда яңа шрифткә күчерелгән «Гани бай» китабы китап киштәмдә тора.

Ә Г. Фәхретдинов «Шура»га — «әтисе куенына» шундый ук вазифаны үтәргә дип күчерелә һәм ул анда алты ел чамасы эшли. Бер-ике мәртәбә, атасы айлап-айлап китеп торган араларда, баш мөхәррир вазифасын да башкара. 1916 елда аны хәрби хезмәткә алалар. Аннан соң «Шура»га элек Казанда «Әлислах» газетасында эшләп киткән, Петербургтагы «Нур» газетасы хезмәткәре булган Кәбир Бәкерне чакырып кайтаралар. Еш кына безнең матбугатта аның фамилиясен «Бәкерев» дип язалар. Югарыда телгә алынган архив фондындагы документларда ул «родом из бывших казаков Оренбургского казачьего войска Бакиров» рәвешендә теркәлгән.

Язучы Зариф Бәшири 1908—1910 еллар аралыгында Оренбургта яши, Кәримевләр матбагасында корректор булып эшли. Элегрәк тә «Вакыт», «Шура» битләрендә шигырьләре, башка төр язмалары басылып килгәнлектән, монда инде алар белән элемтәсе тагын да ныгый төшә. Берара ул «Шура»да әдәби хезмәткәр вазифасын да үтәп ала. Аның, байтак еллар үткәннән соң, Рәмиевләр матбагасына биргән бәһасына күз төшерик. «Закир Рәмиев редакция эшчеләренең тормыш ягыннан яхшы тәэмин ителүләрен, культуралы яшәүләрен күз уңында тота... Ул чорларда һичбер җирдә күрелмәгән рәвештә зур жалованье бирә иде. Мәскәү, Петербургларда ... чыга торган рус газеталарының редакторлары аена 70—80 сумнан артык жалованье алмаганда, «Вакыт» редакторы Фатих Кәримев белән «Шура» редакторы Риза казыйга аена 130ар сум жалованье бирә иде. Моны күпләр «министрлар жалованьесы» дип йөртәләр иде.» 1907 елда Рәмиевләрнең Габдулла Тукайны «Вакыт» газетасына эшкә чакырырга теләүләре, әдәби хезмәткәр вазифасын үтәгән өчен аена 40 сум вәгъдә иткәнлекләре билгеле. Бу чорда шундый ук вазифаны үтәүчеләрнең хезмәт хакы 25 сумнан артмаган. Уфада әдәби хезмәткәр вазифасын башкаручы күренекле шагыйрь Мәҗит Гафуриның да шундый ук хезмәт хакы алганлыгы, шуңа өч җан асраганлыгы мәгълүм. Риза казый үз истәлекләрендә Уфада мөфтияттә эшләгәндә елына 800 сум алганлыгын яза. Димәк, ул Оренбургка күчеп килгән елларында, элеккегә караганда, бер ярымга артыграк күләмдә хезмәт хакы алган икән. 1370 фондтагы бер документта бераздан редакторлар хезмәт хакының 180 сумга, тагын бераздан 225 сумга җитүе, 1917 елның март ае башыннан тагын 50 сумга артканлыгы күрсәтелә. Шәриф Камал белән Кәбир Бәкер элек 120 шәр сум алган булсалар, 1917 елда аларга «Закир әфәнде әмере белән» 180 шәр сумлык хезмәт хакы билгеләнгән. «Вакыт» газетасы чыга башлаганнан бирле анда хуҗалык һәм финанс эшләре өчен җаваплы булган Ярулла Вәли дә 1917 елга чаклы 180 сум алып эшләгән икән. Аның эш хакына тагын 70 сум өстәлә. Элекке һәм яңа

хезмәт хаклары күрсәтелгән бу таблица «Фатих Кәрими» китабының 179 битендә дә урнаштырылган.

Ярулла Вәли шәхесенә әйләнеп кайтыйк. Аны да Рәмиев байлар даирәсенә кертүче, «тартып китерүче» Фатих Кәрими булган. Узган гасыр башларыннан бирле алар аралашкан, иҗатташ кешеләр буларак дуслашканнар. Дөрес, Оренбург губернасының башкаласына 1906 елның февралендә «тартып китерелгәнче» Ярулла Самара губернасының зур бер өязе үзәгендә — Бозаулык шәһәрендә гомер кичергән. (1934 ел урталарыннан Бозаулык өязе биләмәсе Оренбург өлкәсенә кушыла.) Исмәгыйль Рәмиевнең алдарак искә алып кителгән белешмәлегендә: «Ярулла Вәлиулла улы Вәлиев Бозаулык каласында сәүдәгәр гаиләсендә туа, берара үзе дә сәүдә эше белән шөгыльләнә, шул ук вакытта хикәяләр, драмалар язып та бастыра (әсәрләр исемлеге китерелә. — *Л.Х*). 1906—1917 елларда «Вакыт» газетасы редакциясендә эшли», диелгән. Бу кыска мәкалә: «Ачлык кушты» драмасы аны әдип итеп таныта, драма озак еллар сәхнәдән төшми», дигән сүзләр белән тәмамлана.

Фатих Кәрими «Кырымга сәяхәт» әсәренең,1903 елның апреленә караган өлешендә, Бозаулык станциясе вокзалындагы 20 минутлык бер очрашуны болайрак тасвир итә: анда танышларымнан шәриктәшем Галиәсгар Гафуров белән сәүдәгәр Ярулла әфәнде Вәлиев бар иде. Оренбургтан китәр алдыннан аларга хәбәр иткән идем. Бозаулык вокзалында алар мине каршы алды. «Буфетка кереп каһвә эчкән арада күрештек, сөйләштек. Боларның икесе дә ачык фикерле вә хәмиятле (ышанычлы) затлар. Сүзебез, табигый, халкымызның мәгариф вә һөнәр җәһәтендә бик киредә булмаган «Тәрҗеман»ның 20 еллыгына мөнәсәбәтле иде... Ярулла әфәнденең «Мәңгелек мәсҗед», «Күз яше» исемнәрендә язылып таралган ике рисаләсе (китабы) бардыр. Бик ачык вә хуш лисан (тел) белән язылган бу рисаләләре —үземезнең милли мәгыйшәтемездәндер». Ягъни, үзебезнең татар тормышыннан алынган вакыйгаларга нигезләнеп язылган кызыклы әсәр, ди. Һәм озакламыйча ул шушы «ачык фикерле, ышанычлы» һәм шул ук вакытта эшмәкәрлек кәсебен дә үзләштергән сәүдәгәрне, Оренбургка чакырып китереп, «Вакыт» һәм ике елдан соң чыга башлаячак «Шура» матбагаларының коменданты итеп билгеләячәк. Әлбәттә инде, бу ышанычлы кандидатураны бертуган Рәмиевләр белән алдан таныштыру вакыйгаларын кичергәннән соң.

Алда әйтеп үтелгәнчә, «Әдәби сүзлек» белешмәлегендә Исмәгыйль Рәмиев Ярулланы «Бозаулык шәһәре сәүдәгәре гаиләсендә туа» дип күрсәткән. Шул ук авторның 1926 елда «Вакытлы татар матбугаты. 1905—1925» исемле күләмле китабы да басылып чыккан. Бәлки шунда теркәлгән сүзләргә таянып-тыр, бүгенгә чаклы диярлек безнең көндәлек матбугатта Ярулла Вәлине «Бозаулык сәүдәгәре» буларак кына искә алу дәвам итә. Ә бит чынында ул икенче җирдә туган. «Вакыт» газетасы идарәсенә эшкә алу документында аның «Сембер губернасы, Буа өязе, Рангун волосте Бикмураз авылында 1879 елда туган»лыгы теркәлгән (1370 фонд, опись 1, дело 6). Туган көне, ае күрсәтелмәгән. Димәк, ул матбагачы Шәрәфләрнең дә, язучы Шакир Мөхәммәдевнең дә

якташы булган. Узган гасыр башында, Харбиннан кайткач та, Шакир мелланың да Оренбургта яшәп, шунда бакый дөньяга күчкәнлеген искә алган идек инде. Бу язучылар икеләтә якташ була түгелме соң? Әйе. Ләкин әлегә икесенең дә ул чорларга караган истәлек язмалары барланмаган, басылмаган. Ә андый истәлек язмаларының аларда булуында шик юк. Оренбург каласы 1919 елның кышында гына Совет хакимиятенә тәмам буйсындырыла. Ярулла белән Зәйнәп Вәлиевләр 1918—1919 еллардагы вакыйгалардан соң да Закир Рәмиев-Дәрдемәнд йортында яшәүләрен дәвам иткәннәр. 1970 елларда Равил Бохараев тарафыннан Татарстан дәүләт музеена кайтарып тапшырылган ризык купоннары да Дәрдемәнд гаиләсенә шул вакытларда — 1921 елда бирелгән булган. Ләкин ул бер төргәк «ачлык купоннары»ннан беркем дә файдаланмаган бугай. Ул елда Закир белән Мәхүбҗамал һәм Искәндәр белән Шәрифзадә, Оренбургтан вакытлыча китеп тору сәбәпле, ул купоннарны куллана алмаганнар. Алар киткәч тә төп йортта калган дүрт кешелек Вәлиевләр гаиләсенә ул купоннарны куллану, шәһәрдән китеп торучылар исеменнән ризыклар алып йөрү мөмкин дә булмагандыр. Дөресрәге, алай эшләү аларга килешмәгәндер дә. Шуңа күрә купоннар тотылмыйча, Зәйнәп апаның кәгазьләре арасында илле ел чамасы тик яткан да инде. Равил Уфага барырга җыенгач, Зәйнәп апаның адресын һәм телефонын мин аңа язып биргән идем. Уфадан кайткач та ул иң элек минем эш бүлмәмә килде. Заводта ук сапларына көмеш йөгертелгән «З.Р» хәрефләре — Дәрдемәнднең исем-фамилиясенең баш хәрефләре бастырылган бер аш кашыгы белән чәнечке һәм әлеге купоннар төргәген күрсәтеп: «Боларны нишләтик икән? Зәйнәп апаның аларны музейга тапшыртасы килә», — диде. Минем бүлмәдән үк без музей хезмәткәре Дания Баһаутдиновага шалтыраттык. Шул рәвешле ул «ачлык купоннары» музейга эләкте һәм, соңрак, «Дәрдемәнд ачтан үлгән» дигән уйдырма хәбәр таралуга сәбәпче булды. Көмеш йөгертелгән шундый ук вензелле (басма тамгалы) кашык, чәнечке, аш табыны пычаклары Дәрдемәнднең Мәскәүдәге оныгы Бәширдә дә (алты пар иде бугай), Уфада яшәүче оныгы Равилдә дә сакланалар иде. Дәрдемәндкә багышланган альбомның 161 нче битендәге фотода Бәшир Рәмиев гаиләсендә сакланган шул әйберләрне дә күрәбез. Шундагы куш биттәге фоторәсемнәрнең калганнарында, башлыча, Зәйнәп апа тарафыннан 1959 елда Башкортстан дәүләт музеена тапшырылган әйберләр. Зәйнәп апаның Уфада соңгы көннәрендә яшәгән йортындагы күршесе (Казанда Г.Тукайга беренче куелган һәйкәлнең скульпторы Садри Ахунның сеңлесе) белән сөйләшеп утырган идек (Ленин урамы, 2 нче йорт). Зәйнәп апаның вафат булуын белмичә, аларга дип килгән чагым иде. Шунда бу апа миңа: «Зәйнәп күршем үләре алдыннан анасыннан калган көмеш самавырны да шул музейга тапшырмакчы иде. Гөнаһ шомлыгына, үзе бүлнистә чакта Асиясы аны урлатты. Соңгы вакытларда Асиянең бер дә хәтере юк иде, шул чире аны анасы үлгәч тә гүргә дә алып китте. Асиянең балалары да шул чир белән интегә, айлап-айлап бүлнистә яталар. Менә сез килгәндә дә алар икесе дә шунда әле. Хәл белергә барган күршеләрне дә таныр-танымас хәлдә

яталар», — дип, күршеләренең хәләхвәлен сөйләп бирде.

1920 елның апрелендә Оренбург Казакъ (ул вакытта «Кыргыз» дип атаганнар) автономияле мохтариятенең башкаласы буларак билгеләнә. Казакъ кардәшләрнең җитәкчеләре, Рәмиев, Хөсәенев кебекләрнең мәдәният, мәгариф өлкәләрендә кылган уңай эшләрен истә тотып булса кирәк, бу байларның гаиләләренә карата тискәре чаралар кылмый, йортҗирләрен тартып алмыйлар. Хәтта ки татар зыялыларының күпчелеге тарафыннан кылган гамәлләре беркадәр кире кагылган Вәли мулла Хөсәеневкә, «Дин вә мәгыйшәт» журналы наширенә карата да башта тискәре чаралар кулланылмый. 1925 елның июлендә бу мохтарият башкаласы Кызыл Урдага күчерелгәч, кысрыклаулар башлана. Вәлиевләрнең дүрт кешелек гаиләсе дә тиздән урамга куып чыгарыла. Йорт җиһазлары барысы да үз урынында кала. Бәшир Рәмиев сөйләвенчә, 1926 елда бу гаилә Уфага, Ризаэддин мөфти канаты астына барып сыена. Риза хәзрәт Ярулланы мөфтияткә исәп-хисап эшләрен башкаручы итеп ала. Мөфтият бинасының икенче катында аларга яшәү өчен бер бүлмә билгели. 1927 елның җәендә, алар мөфтият йортында яшәгәндә, тугыз яшьлек Бәшир беренче мәртәбә аларда кунакта була. Шуннан соң ул каникул вакытларында, ел саен диярлек, Баймактан Уфага кунакка бара торган була. Ярулла җизнәсен бик яратып сөйләгән, мактаган иде. «Мәрхәмәтле кеше иде... Яңа заман шартларына да яраргa тырышты. Кеше кайда гына эшләсә дә намуслы, тәртипле булырга тиеш»— дип тә еш кабатлый иде. Бик оста йөзә, һәркөн иртән Агыйделгә су коенырга төшә идек. Ул мине йөзәргә дә өйрәтте»,—дип сөйләде Бәшир ага.

Берме, икеме елдан соң Ярулла Вәлиев гаиләсе мөфтият утарыннан ерак булмаган Цюрупа урамындагы бер кечерәк өйне сатып ала. Йорт хуҗасы эш урынын да үзгәртә. Ә Бәширнең атасын — илдәге түнтәрешләргә чаклы Германиядә укып кайткан инженер Искәндәр Рәмиевне утызынчы еллар уртасында Уфага — «Башкирзолото» трестына эшкә билгеләгәч, «Ярулла кияү»дә шул трестка эшкә күчә.

Ләкин бу ике туганны, «буржуй баласы» белән «буржуй кияве» алда кара язмыш сагалап торган икән. Ярулла Вәлиев 1937 елның җәендә, советка дошман кеше буларак, кулга алына һәм шул елның ноябрь ахырларында төрмәдә юк ителә. Искәндәрне 1938 елда кулга алалар, 1943 елның 3 апрелендә ул Томск шәһәре тирәсендәге лагерьларның берсендә вафат була.

Гасыр башында Рәмиевләр матбагасында эшләгән, Дәрдемәнд даирәсенә кергән кайбер башка шәхесләрнең тормышы да утызынчы еллардагы милли шәхесләрне юк итүче тәмуг казанында юкка чыгарылган. Фатих Кәрими репрессияләр компаниясе башлану белән үк Мәскәүдә 1937 елның 4 августында кулга алынган. Ни өчен гаепләнүе дә төгәл ачыкланмаган, һәм, бер ай да берничә көн үтмәстән, шунда аның гомере дә өзелгән. Гадәттә зур бандитларны да шулай ашыктырып юк итмиләр. Аларның да күренеп торган гаепләрен дәлилләү өчен айлар, еллар дәвамында тикшерү гамәлләрен оештыралар. Сеңлесе Закирә Шәрәф хәбәр итүенчә, әдипне кулга алырга килгән солдатлар, урам тәрәзәләре төбенә ике йөк машинасын куеп, аның гомере буена җыйган-туплаган бай китапханәсен, кулъязмаларын,

архивын да төяп алып китәләр. Һәм бу байлык, татар милләтенең тарихына барып бәйләнгән бу хәзинә шул рәвешле юкка чыгарыла. 1937 елда безнең ил җитәкчеләре кылган кара гамәлләр, бер уйласаң, бер дә Явыз Иван заманында кылынган гамәлләрдән ерак тормый.

Байтак еллар Фатих кайнаганың да, Ризаэддин хәзрәтнең дә уң кулы вазифасын үтәп, татар мәдәнияте, әдәбияты үсеше өчен, һәм, әлбәттә инде, Рәмиевләр матбагасы дәрәҗәсен күтәрү өчен дә чын күңелдән, чын ихластан эшләп йөргән Борһан Шәрәфнең дә язмышы шулай төгәлләнә. Ләкин аңа төрмә тормышын озаграк татып, озаграк җәфа чигеп, якты дөньядан соңрак, 1942 елда гына китәргә язган булган. Аның агалары — Тукай, Әмирхан, Камал һ.б.ларның иҗат җимешләрен дистә елдан артыграк вакытта халыкка җиткереп торган Казан матбагачылары язмышы да энеләре язмышын кабатлаган. Шәһретдине — 1938 елда, Гыйльметдине бераз соңрак, 1942 дә юк ителгән.

Бу даирәдән үз үлемнәре белән гүргә кергән затлар күп түгел. Оренбургтан киткәч тә унбиш ел бик катлаулы шартларда дин башлыгы булган, мөфти вазифасын үтәгән Ризаэддин хәзрәт 1936 елда — Уфада, Дәрдемәнд күңелен йомшартырдай әсәрләр язган, шул сәбәпле, хезмәт хакы алудан тыш, алтын каләм кебек кыйммәтле бүләкләр дә алгалаган Шәриф Камал — Казанда 1942 дә, тынгысыз җанлы, әмма исәп-хисап өлкәсендә дә, сәясәткә кагылышлы мәсьәләләрдә дә беркадәр саклык, саранлык күрсәтә белгән «Тимершаһ кияү» Мәскәүдә 1947 елда вафат булганнар. Мөгаен, аларның барысына да — үзләренең җылы түшәкләрендә якты дөнья белән саубуллашучыларына да, рәхимсез җәллад газапларын кичеп үлгәннәренә дә Аллаһ Тәгалә оҗмак ишекләрен ачып куйган булгандыр. Үз милләтләренең рухи үсешенә, алга китешенә бераз булса да үз өлешләрен керткән затлар ич алар. Гадәтенчә сабыр гына атлап, гәүдәсен төз тотып, фикердәшләрен әйдәп, ачык оҗмах капкаларыннан беренче булып Дәрдемәнд үзе кереп киткәндер әлбәттә. Амин. Урыннары оҗмахта булсын!

***Лирон Хәйдәр улы Хәмидуллин,***
*Г. Исхакый исемендәге бүләк иясе*

УДК 39(=512.145)

***Н.Ш. Потеева-Фатыйхова***

## АЛТЫН УРДАГА СӘЯХӘТ

Статья посвящена истории древних тюрко-татарских государств на территории современной Астраханской области.

**Ключевые слова:** древние города Астраханской области, археологические раскопки, Золотая Орда.

Өйрәнелгән гадәт буенча без һәр җәй Алтын Урдага сәяхәткә барып кайтабыз. Ул елны Әстерханның «Сөембикә», «Бирлик», «Хаҗи-Тархан» җәмгыяте әгъзалары, студент яшьләр Алтын Урданың баш шәһәрләреннән берсе булган Сарай-әл-Мәхрүсәдә тарихи экскурсиядә булдык. Элеккеге башкала хәзерге Харабали районы, Селитренное авылы тирәсендә урнашкан.

Алтын Урда, алардан соң барлыкка килгән дистәгә якын төрки-татар ханлыклары хәзерге Әстерхан, Түбән Идел киңлекләре, бүгенге татар тарихында зур әһәмияткә ия. Безнең аяк астында берничә йөз-мең чакрымга сузылган элекке татар ханлыклары нигезләре җәелеп ята. Һәр торак пунктның аерым бер зур тарихы: Сәетләр, Орду-Муаззан шәһәре эзләре (соңгысында нугайларның Түбән Идел буендагы югары ставкалары булган). Шул тирәдә борынгы бер зират бар. Бу зиратта нугайның борынгы әүлиясе күмелгән, хәзер дә Казакъстаннан затлы нәселле нугайлар монда үзләренең мәрхүм булган якыннарын күмәргә алып килгәннәрен сөйлиләр.

Элеккеге Аксарай шәһәре тирәсендәге Бөек Ак мәчет хәрабәсе эргәсендә тукталабыз. Исеменнән аңлашылганча, бу мәчетнең ак манаралары су юлы һәм коры җирдән килүчеләрнең игътибарын үзенә тартып торган. Безгә Алтын Урда тарихын сөйләп баручы җирле археолог Вячеслав Васильевич Плахов: «Әгәр Алтын Урда корылмаларының бер өлеше генә хәзерге көнгә кадәр сакланган булса да, монда бүген Урта Азиядәге, Казакъстандагы кебек мавзолейларны, мең еллык тарихи биналарны күрер идек»,— ди. Моннан ханнар хәрби походларга, зур сәфәргә чыгар алдыннан гыйбадәт кылып, юл алганнар. Мәчет нигезендә хәзер дә ак, зәңгәр, күк төстәге керамика ватыклары чәчелеп ята. Мәчет чама белән 50 метрга 30 метр, аның түбәсендәге ае гына да утыз ике килограмм чиста алтыннан булган! В.В. Плахов Алтын Урда чорында монда чама белән нинди хан сарайлары, нинди корылмалар булганын матур итеп ясалган төсле рәсемнәргә күрсәтеп сөйли. Кайберләребез мәчет нигезеннән Алтын Урда чорына караган көмеш акчалар табып алдык, алар өстә генә ята иделәр, дөрес, вакытлар үтү белән алар җир белән буталып, каралып беткәннәр. Археолог әйтүенчә, Ак мәчет Археология институтының (Мәскәү) исемлегенә кертелмәгән, ягъни, ул булмаган булып чыга. Ак мәчет су буенда урнашкан, монда

хан кичүе — суның икенче ягына чыгып йөрү урыны булган. Су тирән булмау сәбәпле, теге якка көймәсезнисез чыкканнар. Хан заманнарында мөселманнар Югары һәм Урта Идел буйларыннан су юллары белән дә, җәяүләп тә Бөек Ак мәчет аша хаҗга йөргәннәр. Аксарай, Хаҗитархан аша Тимер Капу(хәзерге Дербент) шәһәренә, аннан гарәп илләренә чыкканнар. Иделнең без басып торган сул ягында һәр 25 чакрым саен торак урын, һәр 50 чакрым саен шәһәр булган. Ә уң ягында торак урыннар шактый сирәк, шәһәрләр 200 чакрымга бер генә очраган.

Алтын Урда корылмаларын, хан сарайларын, мәчетләрне ватып Әстерхан кремлен төзүгә тоталар, шәһәрнең үз вакытында ак шәһәр дип аталган өлешендәге өйләрне, башка биналарны салалар. Тик ак шәһәрдәге әлеге өйләр озак гомерле, бәхетле булып чыкмыйлар. Хәзерге Әстерхан кремле манараларының өске өлешләре Алтын Урда хәрабәләреннән алынган күк төсле квадрат формасындагы пластинкалар белән бизәлгәнен дә язып узыйк.

Юлыбызны дәвам итеп, дала эченә тирәнрәк керәбез, безне юл буйлап саксаул, кыргый мәк, лаләтюльпаннар озатып кала. Даланың һәр айда үз матурлыгы. Куйлар далага сибелеп чемченеп йөриләр. Көн эссе булуга карамастан, көтүчеләр өстендә затлы тиредән тегелгән жилет белән чалбар, май ае гына булса да, көтүчеләр инде кояшта нык каралып беткәннәр. Үзләре өчен тиредән тегелгән киемне бу шартларда иң яхшысы дип саныйлар: җәен эсседән, кыш көнендә салкыннан саклый, эре сөякләрне дәвалый. Элек Хаҗитархан җирләрендә дөя үрчетү белән шөгыльләнгәннәр, бу кәсеп XX гасыр башына кадәр дәвам иткән, кызганыч, алар совет елларында юкка чыккан. Соңгы елларда Әстерханда дөя үрчетү яңадан торгызыла башлады. Лапас авылы тирәсеннән табигать нык үзгәрә. Тимер юл полотносыннан, машина юлларыннан кала, цивилизация эзләре күзгә күренеп сирәкләнә. Тирә-якта су урынына, дәрья булып, ком ага, ул мәңгелек хәрәкәттә.

Лапас авылы алдында туктыйбыз. Түбәдә (калкулыкта) урнашкан мавзолейга күтәрелү өчен килгән юлдан 300 метрлап далага керәбез. Археолог сөйләвеннән аңлашылганча, мавзолейның тирә-ягында, түбәсендә агачлар утыртылган булган. Дөньяның борынгы картасында бу мавзолейда Алтын Урда ханнары күмелгән дип билгеләнелгән. Бер төркем галимнәр фикеренчә, монда Үзбәк хан, аның уллары, якыннары күмелгән булырга тиеш. Үз вакытында монда Алтын Урда шәһәре булып, мавзолейдан шәһәргә җир асты юллары булган. Лапас авылы халкы сөйләвенчә, көтүгә чыккан маллар әле хәзер дә, урыны-урыны белән җир убылып баталар икән. Җирле халык моны хайваннарның элеккеге җир асты юлларына эләгүе белән аңлаталар. Хәзер ханнар мавзолееның тышкы ягы элеккеге кебек матур түгел әлбәттә. Туфрак басылып, ул сөзәкләнеп калган, агачлар да үсми, өсте ташландык хәлдә. Кайбер җирләрендә җирле халык ком, балчыкны үз хаҗәтләренә алу нәтиҗәсендә, чокырлар хасил булган. Мавзолейның, ерактан карaганда, дүрт калкулыктан-түбәдән торганы яхшы күренә. Лапас, Досанг тирәләреннән мин көчле тарту көчен сизә башлыйм, нниндидер көч магнит кебек үзенә тарта башлый.

Алдыбызда мәрхәмәтле дә, дәһшәтле дә Бөек дала җәелеп ята! Ал-

тын Урда киңлекләре күңелемнең иң тирән хисләрен уяталар, мин төрки-татар бабаларыбызның борынгы нигезен бөтен барлыгым белән тоям. Монда җаным-тәнем тәмам тынычланып кала, сүзләр белән әйтеп бирә алмаслык рәхәтлек сизәм. Гәүдәмнең һәр күзәнәге Алтын Урда — безнең гомерлек эргә, без шул җирдән, без шул туфрактан, дип тибә. Үземне Алтын Урданың аерылмас бер кисәкчеге итеп тоям. Арабызда чынлап дингә бирелгән кеше юк, яшьләрдән руслар да бар. Мин читкәрәк китеп, Аллаһ ризалыгы өчен, шул җирләрдә яткан ханнар-ханбикәләр, морзалар, әүлияләр, сәхабәләр, ата-баба рухына, дип, Корьән сүрәләрен укыдым.

Ниһаять, без Сарай-әл-Мәхрүсәдә. Килгән юлдан сулда, калкулыкта Селитренное авылы кала, аста ялтырап Ахтүбә елгасы ага. Без элеккеге мәчет нигезендә басып торабыз, бу үз вакытында данлыклы Яшел мәчет нигезе. Мәчет үзенең мәһабәт манаралары белән ерактан балкып торган. Бу мәчет диварлары да Әстерхан кремленә, төзелә торган өйләргә, урамнарга җәю өчен төзү материалы булып хезмәт иткән. Мәчет нигезеннән китеп, башка түбәләргә күчәбез, кайберләренең исемнәрен язып үтәм: Ханнар түбәсе һәр яктан да күренеп тора, ул уртада, иң зуры, күркәме; Маячный бугор; Больничный бугор — монысы авыл янында. Археолог бик бирелеп казу эшләре вакытында табыла торган әйберләр турында сөйли. Шулардан: бассейнда балык скелеты табыла. Әстерханның Балык институты галимнәре моның алтын балык икәнен исбатлап бирәләр. Унөченче гасырда Европаның төшенә дә кермәгән Алтын Урда ханы бассейнында — алтын балык! Икенче бер түбәдә әле соңгы вакытка кадәр дә төрле кактуслар үскән, монда, ягъни ботаник бакча булып, кактусларны тропик илләрдән китерткәннәр (көтүдәге маллар кактусларны ашап үлә башлагач, җирле халык аларны XX гасырда гына юкка чыгарган). Ханнар түбәсеннән Ханнар күленә төшәбез, күлнең кечкенәрәген Изгеләр күле дип атыйлар. Бу тирәдә ике күл бар, аларны галимнәр, Каспий чигенгәндә барлыкка килгән, дип саныйлар. Гомумән, Әстерхан өлкәсендә тозлы күлләр (алар астында дәвалау өчен кулланыла торган ләм катламы) шактый. Калкулыклар арасында, уйсулыкта урнашканга, күлләр ерактан күзгә ташланмый. Бу ике күлнең арасын түбә аерып тора. Сулары тозлы, хәтта яткан килеш кеше гәүдәсен күтәрә. Судан роза чәчәкләре исен хәтерләткән хуш ис аңкый. Коенып чыккач, тән тиресе берничә көн бәрхетсыман булып тора. Май аенда әле тоз катламы утырмаган. Август-сентябрь айларында күлләр саегып кала, тирәягына, төбенә боз катламы кебек, тоз утыра. Яланаяк йөреп булмый. Тоз катламы астында ләм ята. Суның составын Мәскәү галимнәре тикшереп карагач, Израильдәге Үле күл су составы белән бер, дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Бу су тән-тире, буынсөяк авыруларын яхшы дәвалый. Дәваланып-сихәтләнеп китүчеләр күл төбенә рәхмәт йөзеннән алтын әйберләр ташлап китәләр. Җирле халык, ул әйберләрне алу начар хәлләргә китерә, дип сөйли. Күлдә коенсаң, имештер, йөзгә кадәр яшисең. Күлдән су алып, рәхмәтләребезне әйтеп, кайтырга чыгар алдыннан, дала уртасына утырып, ял итеп алырга булдык. Һәркем күңеленә хуш гамәлгә: яшьләр искән җил агымына кушылып, да-

ла биюенә бирелделәр. Татар-ногай яшьләренең бию хәрәкәтләре дала ритмы белән кушылып тулы бер гармонияне хасил итә. Икенче бер җирдә В. В. Плахов экскурсия вакытында табылган өч бөртек Алтын Урда акчасына, чүлмәк, керамика кисәкләренә бәя биреп бара. Ул акчаларның өсләренә бер кош яисә хайван рәсеме төшерелгән. Тирәякта чүлмәк, керамика кисәкләре чәчелеп ята.

Дөньямны онытып дала өнен тыңлыйм, күз алдыма хан сарайлары, мәчетләр, шул җирләрдә гомер сөргән ханнар-ханбикәләр килә, дөньяны дер селкеткән Алтын Урда татарларының ат тояклары тавышлары колак яныннан сызгырып үткәндәй тоела. Үзеңне Алтын Урда варисы итеп, шул ханнар-ханбикәләр белән ырудаш, аркадаш итеп тою нинди зур горурлык! Мин дә ике пакет алып, далага сибелеп керамика кисәкләре җыючы яшьләргә кушылдым. Беренче пакетка җыелганнар — үземә, таныш-белешләргә (монда теләгән һәркем, хәтта Әстерханның үзеннән дә, килә алмый). Икенчесе — Казанның 1000 еллыгына баргач тарихчыларга, башкала кунакларына, галимнәргә өләшү өчен. Бераз керамика җыйгач, сердолик бер төймәгә тап булдым. Ул далада яртылаш җир өстенә чыгып, кояш нурларында ялтырап, мине ал, дигәндәй, үзенә тартып, чакырган сыман. Иелеп, аңа озак кына карап торгач, әй төймәтөймә — милли ядкәр, син мине озак көттеңме, дип сорау бирдем дә, учыма алып кыстым. Ул миңа бик якын, май кебек җылы, йомшак булып тоелды. Мондый табылдыкларны археологлар җир куеныннан казып чыгаралар. Ул алты кырлы, шомартып эшләнгән, кызыл карлыганның пешә торган чагына охшаган. Менә кайдан килә икән хәзерге төймәләрнең үрнәге. Археолог Плахов төймәне үз кулы белән алмагач, башкалар да кагылмады. Ул аңа карап: «Дала — күзгә күренмәсә дә тере организм ул, килгән бөтен кешене кабул да итми, үзенең байлыгы белән бүлешергә ашыгып та тормый, — диде. — Хатын-кыз бу җирләрдә төймә таба икән — ул бары тик аныкы һәм бу — бәхет эше. Алтын Урдага җиденче тапкыр килгәндә син төймәле булдың, җиде — мөселман саны, монда һичшиксез бәйләнеш бар. Төймә унөченче гасырга карый, аны Памирдан килгән табигый таштан ясаганнар. Ул Алтын Урда рухын безнең көннәргә алып килүче кадерле бер ядкәр». Төймәгә мин шунда ук «Сөембикә» дип исем бирдем. Җирле төрки-татар халкының сөйләвенчә, Алтын Урда алтыннары, байлыгы артыннан килүче юлбасарларның хәзинә табып, далада адашып, икенчеләренең акылдан шашып, алтын-көмешләрен кочаклап яткан җирләреннән мәңге уянмаган очраклар булган... Дала рухы, дала өне җир астында калган шәһәрне, аның рухи һәм матди байлыгын саклый. Кара фикер, начар эш уйлап килгәннәрне чыгармый, үзендә алып калу очраклары була. Гомер бакый шул җирдә тормыш көткән татарлардан ишеткәнем бар: дала мәрхәмәтле ана да, дала тәрбия дә бирә, ачтан да үтерми, юлдан да яздырмый, кешене чыныктыра, сыный, үзенең хәзинәсе белән дә бүлешә, әмма бервакытта да артыгын алма! Даланы аңлый белергә, аның белән рухташ булырга кирәк, шул очракта син далада үз кеше. Аның үз законнары, мең ел буе килгән үз тәртибе бар, дала сине кабул итсен өчен шактый гомер шул җирдә яшәргә кирәк. Бу якларга

башка яклардан килеп төпләнеп калганнар, бигрәк тә урыс халкы далага чыкмый да, кирәксенми дә, аңламый да. Әйе, аларның канында дала рухы юк. Элек җирле халык авырып киткәч, 2—3 көнгә далага чыгып китеп, сихәтләнеп кайткан.

Алтын Урда турында язарга алынгач, аның һәлак булу сәбәпләрен дә бу якларда үзем ишеткәнчә язып үтәм. 1989—1991 елларда Әстерхан медицина институтында клиник ординатурада укыганда, фәнни эш белән шөгыльләнеп, бер төркем медицина академиясе галимнәре, табиблар белән Комсомольский поселогына йөри идек. Әстерханның өлкә клиник хастаханәсендә табиб булып эшли башлагач, тиз арада казакъ телен аңлый башладым. Комсомольский поселогында: «Безнең телдә сөйләшүче табиб килгән», — дип, олы яшьтәге халык минем тирәгә җыела, үзләренә кунакка чакыра иделәр. Автобус көткән арада, башкалардан аерылып, авылны, халыкның тормыш-көнкүрешен карап йөрергә ярата идем. Бер тапкыр таякка таянган бабай минем янга килде дә, без озак сөйләшеп утырдык. Ул минем күземә керердәй ук кебек булып сөйләде. Дөресрәге, баштан минем кем булуым, бу якларга ничек килеп чыгуымны сорашты да, аннан сүзгә кереште. Ул күп сөйләде, мин яшьрәк тә идем, җирле тарих белән ул вакытларда җитди шөгыльләнмәгәч, язып та алмадым, күбесе онытылган. Әмма, табиб буларак, бабайның холера-ваба авыруы турында сөйләгәне яхшы хәтердә калган, чөнки ул вакытта мин андый нәрсәне беркайдан да укыганым да, ишеткәнем дә булмады. Аның сөйләвенчә, Урданы хан сугышлары түгел (дөрес, алары да булган), ваба-холера авыруы бетергән. Урданың җимерелү сәбәбе — халык вабадан кырылган. Бабай бу сүзләрен таягын күккә селти-селти сөйләде, мин аңа гаҗәпләнеп карап тордым. Аның йөзе килгәндә юл буенда калган кечкенә ком барханнары кебек җыерчыклы, куллары, сеңерләре саксаул тармаклары кебек коры иде. Автобус килеп, мин китәргә җыенгач, ул тагын кабатлап, Урданы сугышлар түгел, ваба авыруы җир йөзеннән юк иткән, диде. Ком арасыннан чыккан бабай, дип, ничә елдан соң да исемә төшә ул.

Кешелек дөньясында холераның алты пандемиясе (ягъни бөтен Җир шарын басып ала торган) булып, шуның дүртесе Әстерхан аша уза. Шулай итеп, дөрестән дә, Алтын Урданың юкка чыгуының төп сәбәбе ваба авыруыннан булуы бик тә мөмкин. Европа белән Ислам дөньясын, Идел буйларын тоташтырган хәзерге Әстерхан җирлеге элек-электән кемнәрнең генә күзен кыздырмаган да, кемнәрне генә үзенә тартып китермәгән. Хәзәр каганлыгы, Алтын Урда күптән комга әверелсә дә аларның тарихи мирасы гаять зур, тирән һәм мәңгелек. Бу безнең тарихи мирасыбыз. Аңа элек урыс галимнәре генә дәгъва кылса, соңгы вакытта яһүд галимнәренең тавышы көннән-көн көчлерәк яңгырый. Дөрес, татар да йоклап ятмый. Дистә еллардан артык Алтын Урдада (хәзерге Харабали районы, Селитренное авылы) Казан дәүләт университеты профессоры Әзһәр Мөхәммәдиев казу эшләре алып бара. 1999 — 2002 елларда Казан археологы Альберт Борһанов та шул ук Селитренноеда казыну эшләре алып барды. Бер елны без, казу эшендә катнашкан Казан студентлары, Әстерхан яшьләре, укучылар белән бергә, Татарстанның Бәйсезлеге

көне —30 август хөрмәтенә багышлап 2 көн дәвамында «Алтын Урда археологиясе» конференциясен уздырдык. Конференция башланганчы да, тәмамлангач та үзәк урамнарда Алтын Урда, Кырым ханлыгы, Татарстан флагларын күтәреп йөрдек. Аннан Әстерхан кремленә кереп фотога төштек. Альберт Борһанов конференциягә Мәскәү галиме Эдуард Кульпинны алып килгән иде. Кызганыч, Әстерханда бүгенгә Хәзәр каганлыгы музее да, Алтын Урда музее да юк.

Әстерханда билгеле тагын бер тарихи фактка тукталып үтәм. Әстерханда төзелеш эшләре алып барганда (хәзерге Аксарай тирәсендә) бульдозер көрәгенә затлы агачтан ясалган зур сандык кебек әйбер килеп эләгә. Ул яхшы итеп ябылган, ачканнан соң, эшкәртелгән тире белән тышланган, зур-зур, яхшы кәгазьгә язылган китаплар килеп чыга. Язулар гарәпчә булып, китапта таблицалар, диаграммалар, план кебек нәрсәләрне күрәләр. Китапларны караган кешеләр моны Алтын Урда, Хаҗитарханда бер галимнең архивы, кулъязмалары дигән нәтиҗәгә киләләр. Бу хәл XX гасырның 90 нчы еллары башында булып, табылдыклар турында тиешле җиргә хәбәр ителә. Боларның татар китаплары икәне билгеле булгач, килгән кешеләр аларның Әстерхан өлкәсеннән чыгып китүен хуп күрәләр. Шулай итеп, китаплар чеченнар кулына барып керә. Алар бу борынгы китапларны Төркиягә сатканнар. Китапларда әлегә кадәр билгеле булмаган Алтын Урда тарихы, шул исәптән Хаҗитархан тарихы язылган, диләр.

2008 елда Рәсәй дәүләте Әстерханның 450 еллыгын билгеләп үтте. Бу хәбәргә җавап итеп, Төркия Әстерханның рәсми даирәләренә: дөрес тарихыгыз бездә, дип чыкса да, бу мөрәҗәгать җавапсыз калган. Ул материаллар матбугатта күренмәде.

Соңгы елларда Әстерханда нинди милләт вәкилләре генә казу эшләре белән шөгыльләнми? Рәсәйнең көньяк су һәм коры җир чиге булган элеккеге Хаҗитархан ханлыгы татарлары бүген дөнья арбасыннан төшеп калмас өчен җан талаша. Урыс Әстерханына 450 ел булса, татар Әстерханына 800 елдан артык, дип саныйбыз. Тик моны раслау бары тик Казан — Татарстан белән килешеп эшләгәндә генә мөмкин булачак.

## Гаяз Исхакыйның авылдашы —<br>Сөембикә ханбикәнең рухи сеңлесе

2013 елда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләренең чираттагы сәфәре Әстерхан өлкәсенә оештырылган иде. Фәнни сәяхәтебезнең башыннан алып ахырына кадәр диярлек, татарлар дип янып-көеп яшәүче милләтпәрвәр Наилә Шакирҗан кызы Потеева-Фатыйхова милләттәшләребезнең үткәне һәм хәзерге тормышы белән таныштырып йөрде.

Наилә ханым — Гаяз Исхакыйның якташы, ул Татарстанның Чистай районы, Яуширмә авылында туып үскән. Казан дәүләт медицина институтын тәмамлый. Чистайда интернатура үткәндә Әстерхан егете, врач Али Рафыйк улына кияүгә чыга. Кама Тамагы район хастаханәсендә 3 ел табиб булып эшләгәч, 1985 елда алар Әстерханга китәләр. Анда Потеева-Фатыйхова клиник ординатура тәмамлый,

Мәскәүдә Н.Н. Бурденко исемендәге нейрохирургия институтында белемен баета. Аннан Әстерхан өлкә клиник хастаханәсендә отоневролог булып эшли. Югары категорияле табиб дәрәҗәсенә ирешә. Аның исеме «Лучшие люди России-2004» энциклопедиясенә кертелгән.

Әстерхандагы гомере, 1989 елдан алып, милли хәрәкәт белән бәйле. «Дуслык» җәмгыяте советы әгъзасы, аның рәисе урынбасары булып сайлана. 1995 елда Әстерхан татарларының «Идел» газетасында татар бүлеген ачып, аны алып бара. Әстерхан татарлары турындагы 6 китапның төзүчесе һәм нәшриятка әзерләүчесе. 1999 елда «Ак калфак»ның Әстерхан бүлегенә нигез сала, 2002 елда аны өлкә «Сөембикә» берләшмәсе итеп киңәйтәләр. Туган ягына багышлап «Чал тарихлы Яуширмә» исемле китапның электрон вариантын эшли. Әнисеннән авыл тарихын, шактый күп итеп мәкальләр, әйтемнәр язып алып калган. 5—6 ел дәвамында Әстерхан мөселманнары өчен дивар календаре чыгарып килә.

Ул Идел Болгарстаны, Алтын Урда тарихы, Кырым, Әстерхан, Себер ханлыклары тарихы, татар әдипләре, милли хәрәкәт, бигрәк тә хатын-кызларның милли хәрәкәте мәсьәләләрен үз эченә алган, үзе төзегән «Татар төрки дөньясында» исемле программа буенча шәкертләр укыта. Милли хәрәкәттә яратып эшләгән тармаклары: төрки-татар тарихын өйрәнеп, аны халыкка җиткерү, яшьләрдә милли аң формалашу процессына йогынты ясау, әдәби кичәләр, очрашулар уздыру, Казан ханбикәсе Сөембикәнең язмышын өйрәнү. «Сөембикә» берләшмәсенең нигездә тарихи китаплардан тупланган шәхси китапханәсе бар. Алар ел әйләнәсендә кулдан-кулга күчеп укыла икән. «Уку елы дәверендә ана теленә игътибарны киметмәскә тырышсак та, беренче урында барыбер милли аң формалашу мәсәләсе тора. Чөнки үзен татар итеп танып, тарихыбыз белән кызыксына башлаган кеше, киләчәктә аны тагын да тирәнрәк өйрәнергә омтылачак», — ди Наилә Потеева-Фатыйхова.

Дин нигезләрен өйрәнүен, намазга басуын, бу изге гамәлләргә шактый табибларны, шәфкать туташларын да тарта алуын горурланып сөйли. Ул Корьәнгә бәйле төрле чаралар уздыруда катнаша. Гарәп графикасы белән укырга-язарга өйрәнә. Шул графикада язылган китапларны җыя.

Озак еллар артыннан йөри торгач, милли хәрәкәт ветераннары белән 2011 ел башында Габдрахман Гомәри исемендәге Әстерхан татарлары тарихы музеен ачуга ирешәләр.

Хәзерге вакытта да ул Әстерхан татарларының тарихын өйрәнүен дәвам итә, рухи мәдәниятен барлый, атаклы шәхесләр, тарихи урыннар турында мәгълүмат туплый. Алда әйткәнебезчә, фәнни экспедиция белән килгән Казан галимнәренә Наилә ханым Әстерхан шәһәренең татар халкы белән бәйле тарихи биналарын, татарлар яшәгән Тиякне, шәһәрнең күп санлы мәчетләрен (Кара мәчет, Яшел, Ак мәчет, Нугай мәчет, Кызыл (үзәк) мәчет, Камышлы, Сары мәчет), Печән кибете, Татар Капка кебек тарихи урыннарны күрсәтте, аларның һәрберсе турында этрафлы мәгълүмат бирде. Мәсәлән, дәваланырга дип Әстерханга килгән Габдулла Тукайның Татар-базардан ерак түгел генә урнашкан йортта вакытлыча яшәп китүен белдек. Замамында кызыл кирпечтән салынган

Кызыл Шәрекь клубында шыгрым тулы залда Һади Такташ кичке 9 дан төнге сәгать 2 гә хәтле (4—5 сәгать дәвамында) шигырьләрен укыган булган. Гомумән, татар дөньясыннан кем генә Тияктә булмаган: Риза Фәхретдин, Фатих Кәрими, Галимҗан Ибраһимов, Сәгыйть Рәмиев һ.б. Татарның бөек шәхесләрен генә түгел, ислам дөньясының олы укымышлыларын, галимнәрен дә хәтерли Тияк. Наилә ханым безгә Шиһабетдин Мәрҗанинең яраткан укучыларыннан берсе Габдрахман Гомәри (1867—1933) исеме белән бәйле, киң танулы Яшел мәчет турында сөйләде. Г.Гомәри 1892 елда, Казаннан кайткач, «Низамия» мәдрәсәсен һәм ярлыларга булышу фондын ачкан. Әстерханның Бирге Тияк бистәсендә татар нәшрият компаниясен ачып җибәргән: анда 6 елда 60—70 исемдәге китаплар басылып чыккан. 1907 елдан 1914 елга кадәр нәшер ителгән «Идел» газетасы редакциясен дә Г. Гомәри җитәкләгән. Тиздән газета бөтен Россиядә, кайбер елларда чит илләрдә дә тарала башлаган. Тагын бер кызыклы факт: ул чакта газетаның Төркиядәге хәбәрчесе вазифасын илдән сөрелгән Гаяз Исхакый башкарган. 1910 елдан 1914 елгача «Идел»нең әдәби бүлеген Сәгыйть Рәмиев җитәкли. Гомумән, ул елларда Әстерханда тормыш кайнап тора: клублар эшли, кинолар күрсәтәләр, чит җирләрдән дин әһелләре килә, Казан, Мәскәү кунаклары да еш була.

Наилә ханым бу төбәктәге авылларның да күбесен яхшы белә. Халык аны хөрмәт итә, аңа табиб буларак та мөрәҗәгать итәләр. Ул татар бистәсенең үзәге булган Тиякнең (Царево) бүгенге хәленә ачына. Алар хакындагы проблемаларны күтәреп, җирле газета-журналларда чыгышлар ясый.

2005 елда Н.Потеева-Фатыйхова «Сөембикә» бәләзеге лауреаты исемен яулаган милләтпәрвәр. «Минем максатым: халкыбызны бердәм милләт итеп саклау. Татар халкының язмышы хәзерге вакытта милли зыялыларыбыз кулында. Һәркем үз халкын саклап калыр өчен кулыннан килгәнчә нәрсәдер эшләргә тиеш», — ди ул. Наилә ханымның болай фикер йөртергә булы хакы бар: әстерхан татарларының тарихын, риваятьләрен, йола-бәйрәмнәрен, аш-су серләрен өйрәнгән. Без аны, халкыбызның бер фидакарь кызын, еракТагы якын кардәшебезне рәхмәт хисләре белән искә алабыз.

***Булатова Миңнира Рәхим кызы**, филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*лексикология һәм диалектология бүлеге фәнни хезмәткәре*
*E-mail: m.r.bulatova@mail.ru*

*Риза Газиз*

# ТАБИГЫЙМЕ ЯКИ ТАБИГЫЙ БУЛЫРГА ТИЕШ ТҮГЕЛМЕ?

Языковед Газизов Риза Салахутдинович (1894—1981) совместно с М.Х. Курбангалиевым заложил основы сопоставительного изучения татарского и русского языков. Известны труды по лексикографии, двуязычные словари и учебные пособия, изданные под его авторством. Предлагаемая вниманию читателей статья Ризы Газизова была опубликована в №№ 1—2 журнала «Магариф» от 1926 года и посвящена вопросам татарской орфографии на основе арабской письменности.

Некоторые проблемы татарской орфографии того времени не потеряли своей актуальности и сегодня. Так, например, до сих пор не разработаны единые унифицированные принципы и правила передачи на письме некоторых звуков, характерных для татарского языка, что приводит к разнобою в их написании. В этом плане статья автора включает в себя ряд интересных выводов и наблюдений.

**Ключевые слова:** татарская орфография, принципы орфографии, татарская письменность на основе арабской графики.

Төрек-татар телләрендә имля мәсьәләсе әле һаман проблема хәлендә яшәп килә. Бу мәсьәләне проблема хәленнән чыгару өчен булган көрәш безнең татарларда, шулай ук башка төрек халыкларында да, байтак еллардан бирле бара. Бу проблеманы чишү теләге Октябрь революциясеннән соң бигрәк тә ачык төс алды. Бу мәсьәләне чишүдә иң сулга хәтле барып җитәргә теләүчеләр дә, шулай ук, традиция принципларына ияреп, уңдарак бер позициядә калучылар да булды. 1920 елда игълан ителгән имлябыз менә шул уңдарак бер позициядә торучыларның алга сөргән принципларыннан килеп чыккан бер имля.

Иң сул позициядәгеләр, телнең канунда булмаган бөтен читкә тайпылулар (истисналар) имлядан чыгарылып, табигый бер имля төзү кирәклеген алга сөрәләр. Уңдарак торучылар гарәп сүзләре имлясында иң сул ноктага барып җитсәләр дә, кайбер мәсьәләләрдә «сарыф берлек саклыйбыз» яки «язу техникасы җиңелерәк булсын, язуны кыскартып икътисад ясыйбыз», дип традициягә ияргәләр, уңдарак бер позициядә калалар.

Язуны кыскартып икътисад ясау мәсьәләсе беренче гая [ахыр, чик, соң] иттереп куелса, ул вакытта безгә иң файдалы имля өч мәдле иске имлямыз, «Бакырган имлясы» булып чыга, анда «схр трмкны гадт кл» (сәхәр тормакны гадәт кыл) яки «млт трк(ый)» диеп языла иде. Ләкин без моның белән генә канәгатьләнеп кала алмадык. Димәк, икътисад аз урын алудан, язуның кыска булуыннан гына гыйбарәт түгел икән. Хәзерге имлямызда тәмам чишелеп җитмәгән һәм телнең табигатенә каршы булган түбәндәге пунктлар бар:

1. Саңгырау һәм яңгыраулы авазлар кануны (д-т, ғ-қ, г-к мәсьәләсе).

2. Авазларның бер берсенә иярүчәнлек кануны[1].

3. Һәмзә мәсьәләсе (сузыклар алдыннан һәмзә язу/язмау мәсьәләсе). Бу мәсьәләләр турында, йә болай, йә тегеләй булырга тиеш, диеп әйтүдән элек, бу турыда педагогикада нинди юллар барлыгы һәм шул юлларның

кайсы иң дөрес юллардан саналганлыгы, шулай ук ул юлларның кайсы безнең телебезнең табигатенә якынлыгы турында берничә сүз әйтелсә, артык булмас дип уйлыйм.

Дөрес язарга (имляга) өйрәтү өчен падагогикада түбәндәге принциплар күрсәтелә:

1) телнең фонетикасына нигезләнгән принцип,

2) тарихи принцип (традициягә иярү принципбы),

3) телнең сарфына нигезләнгән принцип,

4) мантыйкый принцип.

**Фонетика принцибы.** Бу принцип хәреф билгеләрен авазларның әдәби телдә әйтелешенә тәмам туры китереп алган вакытта һәм шул хәрефләр аркылы фонетика ягыннан мөһим булган бөтен авазларны әйтергә мөмкин булган вакытта дөрес язарга өйрәтүдә принцип була ала.

Безнең имлямыз фонетикага нигезләнгән булса, ул вакытта аннан бөтен читкә тайпылулар чыгарылып ташланган булыр һәм балаларны дөрес язарга өйрәтү эше артык дәрәҗәдә җиңеләер иде. Бу бер.

Икенчедән, фонетика буенча язганда язуга өйрәтүнең үзегендә сөйләшергә өйрәтү эше торыр һәм шуның аркасында сөйләшергә өйрәтүнең белем бирү кыйммәте тагын да артыр иде. Бу принцип Европада да, русларда да бер вакыт алга куелган булган, ләкин аларда бу принцип гамәлгә куелганда аларның грамматикалары тәмам җимерелә, бер үк сүз үзгәргән вакытында төрлечә язылырга тиеш була. Мәсәлән, бу принципны алган вакытта «вода» сүзе «вوُда» (за вوُду пошла), «чего» сүзен «чево», «кто» сүзен «хто» дип язарга кирәк булыр иде. Бу исә рус теленә яңадан وُ кебек яңа хәрефләр (ул вакытта аларның хәрефләре 70 тән арттып китә) арттырырга кирәк, дигән сүз булып чыга. Шуңа күрә алар бу принципны саф көенчә генә ала алмаганнар, югарыда саналган дүрт принциптан кушылган компромисслы бер принцип алганнар.

**Тарихи принцип (традиция принцибы).** Бу принцип сүзләр искедә язылганнарынча язылсыннар, һәм сүзләрнең язылышына карап телнең тарихи үзгәрешләрен күрергә мөмкин булсын, ди. Мәсәлән, безнең электә гарәпләргә ияреп «мәктәп» сүзен «мктп», «Гомәр» сүзен «гмр» дип, хәзерге көндә ярты-лаш гарәпләргә ияреп «өмет» сүзен «өмид», «Мәхмүт» сүзен «Мәхмүд» дип язуыбыз шикелле.

**Телнең сарфына нигезләнгән принцип.** Бу принцип, сүзләрнең язылышы үзләренең сарфына туры китерелгән булсын, ди. Хәзерге имлямызча «сарфи берлекне саклыйбыз» дип «китте»не «китде», «башта»ны — «башда» дип язуыбыз шикелле.

**Мантыйкый принцип.** Бу принцип бер төрле ишетелеп тә берничә мәгънәләре булган сүзләрнең төрлечә язылуларын алга сөрә. Бу — һәрбер язылган сүз үзенә аерым бер мәгънә белгертсен өчен кирәк, ди. Шушы принциптан чыгып иске грамматикаларыбызның кайберләре (хәзерге көндә бер төсле языла торган) «ташлар — камни» сүзен «ташлар — бросит»дан аерыр өчен беренчесен «ташлр» икенчесен «ташлар» дип язарга кирәк, диюләре кебек. «Эшлр — работы», «эшләр — будет работать» һәм башкалар.

Русларның «мир» сүзен «міp — мир» рәвешендә ике төрле язулары да шушы принципка нигезләнгән иде.

Менә шушы принципларның кайсыларында без имлямызны табигый ясый алабыз соң? Бу принципларның

педагогика тарафыннан иң дөрес дип табылганы һәм табигатькә, «безнең телебезнең табигатенә» бигрәк тә муафыйк булганы — фонетика принцибы.

Без соң шушы принципны ала алабызмы? Әлбәттә, ала алабыз. Безнең өчен бу принципларның иң кулай булганы да шул. Моның өчен фәкать имлямызда чишелеп җитмәгән, югарыда күрсәтелгән өч принципны чишәргә кирәк. Без шул өч принципны телебезнең табигате соравы буенча чишә алсак, фонетика принципына йөз процент диярлек күчкән булабыз. Димәк, безгә шул өч принципны чишәсе кала.

Килик «саңгырау һәм яңгыраукл авазлар канун»ына, ягъни саңгырау авазлардан соң «д» ның «т»гә, «ғ»-ның «қ»га, «г» нең «к» гә әверелүе мәсьәләсенә. Боларга килгәндә, хәзер куллана торган имлябызны яклаучылар бик кызык кына үзләренә каршылык ясыйлар. Алар саңгырау авазлардан соң «ға — гә»нең һәм «ған — гән»нең «қа — кә» һәм «қан — кән»гә әверелеп язылуына каршы килмиләр. Шулай язарга кирәк, диләр («сарыф берлекне саклап» һәммә җирдә дә «ға — гә», «ған — гән» язарга кирәк, диләр). Шул ук канун буенча «д»ның «т»гә әверелүенә «да — дә» урынына «та — тә», «дан — дән» урынына «тан — тән», «ды» урынына «ты», «дыр» урынына «тыр» язылуына каршы киләләр, «сарыф берлекне сакларга кирәк», диләр. Мондый мәсьәләдә турыдан-туры йә бөтен җирдә «сарыф берлекне сакларга», йә телебезнең табигате буенча «д» урынына «т», «ғ» урынына «қ» , «г» урынына «к» языла, дияргә кирәк. Имлямыз табигый булсын дисәк, без бу мәсьәләдә иң сулга барып җитәргә тиешбез. Хәзерге имлячыларыбыз уенча, тегеләй тартсаң да ярый, болай тартсаң да ярый, диган сүз булмасын.

Инде укучылар һәм язучылар иң күп хата ясый торган «ы», «о» мәсьәләсенә киләбез. «Ы» турында сүз барганда хәзерге имлячылар «язу техникасын җиңеләйтәбез, урында икътисад ясыйбыз», дип «ы»ны ябык иҗекләрдә язмаска тәкъдим итәләр. Аларның урында «икътисад» диюләрен минем Крылов баснясындагы медвежья услуга белән чагыштырасым килә. Урында «икътисад» тәкъдим иткән вакытта балаларны язуга өйрәтү эшендә кирәк булачак икътисад турында бөтенләй оныталар. «Ы»ның хәзерге имлябыздагы хәле табигый түгеллеге укучылар белән эш иткәндә бигрәк тә нык күзгә бәреләә. Мәктәптәге бөтен язуга өйрәтү эшләре баштан ахырына кадәр шул «ы» имлясын өйрәтүгә әйләнеп китә. Укытучының да, укучының да әллә ни кадәр вакыты әрәмгә китә. Урында «икътисад» исеменә безнең тормышыбызда иң кыйммәт булган «вакыт та икътисад»ка корбан ителә[2].

«О» имлясы да шулай тора. Аны укучыларда тәмам урнаштырыр өчен укытучыга бик күп көч куярга туры килә. Ни кадәр генә көчләп «икенче иҗектә «о» язылырга тиеш түгел» диеп өйрәтергә тырышсаң да, укучы һаман «өчөн», «бөтөн» диеп язу ягын карый. Укучыларыбыз гына түгел, укытучыларыбызның да күбесе монда ялгышалар. Бу да имлямызның табигый принципка — фонетика принцибына — корылмаганлыгыннан килеп чыга. Бу мәсьәләләрдә без бигрәк тә Мәйманның «ничек ишетелсә, шулай яз» дигән сүзләренә иярергә тиешбез.

Сузыклар алдыннан языла торган һәмзәгә килсәк, монда укучыларның сүзе җитсә кирәк, алар, һәмзәнең

нигә кирәге бар соң? диләр. Дөрестән дә сузынкылар алдында әллә нинди придыханиеларны эзләп, аларның алдына һәмзә тагып кую һичбер табигый булып исәпләнергә тиеш түгел. Кабинетта утырып эшләүчеләр, придыхание бар, дип танысалар да, телне гамәлдә кулланучылар өчен сузынкылар алдына артык бер һәмзә тагып язуның бер тиенлек тә кыйммәте юк. Киресенчә, моның зарары гына бар.

Балаларга сузынкыларны һәмзәсез өйрәтеп кил-кил дә, ахырдан инде, тот та сузынкы аваз хәрефе сүз башында килсә, аның алдына бер һәмзә арттырыла, диген. Алар, ни өчен? диячәкләр әлбәттә. Монда инде без ни кадәр генә придыханиеләр турында сөйләмик, алар аны барыбер аңлый алмаячаклар. Тик «әтиләр, бабайлар шулай язганнар инде» дип традициягә генә ияреп көчләнеп язачаклар. Һәмзә тарафдарлары һәмзәне алып ташлау белән «йа» белән «уау»га яңа билгеләр табарга кирәк булачагыннан куркалар. Кирәк булсын, бу барыбер табигый гына булачак. Башкорт һәм казакъ иптәшләребез инде һәмзәне алып ташлаганнар. «йа»га да, «уау»га да билге тапканнар. Безгә дә шулай эшләү имляның табигыйлегенә зур бер адым булачак.

Кыска гына тикшергәндә имлябызның табигый принцип — фонетика принцибы — нигезендә корылуына киртә булып торган нәрсәләр шушылар.

ГУС программалары һәрнәрсәнең табигый булырга тиешлеген алга сөргән вакытта, «уйны, тойгыны баштан кичерүләрне һәм төшенүне белгертүче корал» (ГУС программаларыннан) булган телебезнең бер бүлеген, ягъни аның имлясын, табигыймеккә өстерәүгә без бигрәк тә күп көч куярга тиешбез.

**Искәрмәләр**

1. Авазларның бер-берсенә иярүчәнчек кануны шуннан гыйбарәт: 1) төрек телләрендәге сүзләр үзләренең бөтен ялгаулары белән бергә йә бөтенләй калын гына, йә бөтенләй нечкә генә әйтелә; 2) төп иҗекнең (беренче иҗекнең) сузык авазы хуҗалык итүче аваз булып, алдагы иҗекләрдәге сузык авазларга тәэсир итә, аларны үзенә буйсындыра, икенче сүз белән әйткәндә, үзеннән соң мәгълүм сузыкларның килүенә генә ирек бирә. Мәсәлән, төп иҗектә «а» булса, икенче иҗекләрдә «а, ы», «ый» һәм «у» гына була. Шушы канун буенча тикшереп караганда, уңдагыларның «беренче иҗектәге «о» алдагы иҗекләрдәге «о»ны «ы»га әйләндерә» диюләре ялгыш булып чыга. «Өчн» сүзен алып карасак, бу сүзнең беренче иҗектәге «Ө», икенче иҗектә дә «ө» килүен сорый. Моның шулай икәнен күрер өчен «өчн», «бөтн», «төтн», «торр» кебек сүзләрне табигый рәвештә, ягъни иҗекләргә бүлмичә, әйтеп карасагыз, күрерсез. Инде «өчн» сүзен «ө» — «чн» дип иҗекләргә бүлеп, гайре табигый рәвештә әйткәндә, билгеле «ө»нең икенче иҗектәге сузыкка тәэсире югала да, «чен» иҗеге килеп чыга. Соңгы юл белән эшләгәндә бөтен сүзләрнең табигыйлеген шушы рәвешчә бетерергә мөмкин.

2. وُ имлясын дөрес язучыларның саны бөтен Татарстанда 10—15 тән артмаганлыгы (моның шулай икәне гәзит һәм журналларга килгән материаллардан күренә) аның хәле имлябызда табигый түгеллеген бигрәк тә ачык күрсәтә.

*Басмага әзерләде:* ***Асылгәрәев Шәрифҗан Нурлыгәрәй улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

*Р.Р. Солтанова*

## ТАШ МОҢЫ

«Казан Кремле» музей тыюлыгында скульптура буенча «Таш моңы» дигән Халыкара симпозиум булып узды (кураторы — Р. Солтанова). Шушы елның 29 июненнән 18 июленә кадәр дәвам иткән бу чара 2014 елда «Казан — төрки дөньяның мәдәни башкаласы» кысаларында үткәрелде. ТР Мәдәният министрлыгы, ТР ФА Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы, Россия рәссамнарының Татарстан берлеге тарафыннан оештырылган симпозиумда Төркия, Азәрбайҗан, Украинадан һәм Башкортстан, Татарстан, Россиянең башка төбәкләреннән килгән 8 скульптор үзләренең иҗади фантазияләрен тормышка ашыру процессын демонстрацияләделәр. Осталарга Мәскәүнең В.Суриков исемендәге институты Казан филиалы студентлары һәм аны быел гына тәмамлаучылар, яшь скульпторлар өйрәнчек буларак булыштылар. Скульпторлар катнашында «Сын сәнгатендә бүгенге актуаль проблемалар» дигән темага «Түгәрәк өстәл» узды.

Симпозиумны оештыручыларның максаты кече архитектура формаларына әллә ни бай булмаган Казанны яңа скульптуралар белән баету иде. Цифрлы технологияләр һәм тоташ глобальләштерү киңлегендә (шартларында) этник бердәйлек (тәңгәллек) сыйфатларын чагылдыру, төрки халыкларга хас пластик фикерләрнең символик телен гәүдәләндерергә һәм аны җанландырырга мөмкинлек тудыручы милли традицияләрне алга таба тагын да тирәнәйтү скульпторлар өчен төп бурычлар булып тора. Шул ук вакытта форум эше тасвирый сәнгатьнең күп көч һәм зур чыгымнар таләп итә торган төре саналган скульптураны популярлаштыруга, этник скульптура үсеше перспективасын яңа мөмкинлекләр белән баетуга юнәлдерелде. Осталарга Идел Болгарстаны һәм Казан ханлыгы чорында архитектур корылмалар төзүдә кулланылган известняктан (аны Лениногорскидан китерделәр) скульптур формалар ясарга тәкъдим ителде.

Известняк, үзлеге белән, ташның уалучан токымы булып санала, шуңа күрә аннан очлы яки үткен кырлы формалар эшләп булмый. Аны җиңелчә эшкәртелгән монументаль скульптуралар гәүдәләндергәндә кулланалар (Борынгы Грециядәге архаик декоратив скульптураларны гына күз алдына китерик). Сынчының концепциясе материалның үзенчәлеге белән билгеләнми (билгеле, ул да зур әһәмияткә ия), ә сәнгать әсәренең мәгънәви асылы, идеясе, максаты беренче планда тора. Шуңа күрә симпозиумда катнашкан скульпторларга тематика сайлау һәм стилистик мөмкинлекләрен файдалану буенча ниндидер чикләүләр куелмады. Симпозиумның исемен «Таш моңы» дип атау үзе үк бу төр сәнгатьнең асылын ачып бирә. Таш белән эшләүче сынчы каты токымның тыгызлыгын, авырлы-

гын җиңә барып, аңа үз эмоцияләре аша җан өрә. Конфигурацияләре, үлчәмнәре, үзләрендә чагылыш тапкан идеяләре белән төрле булган скульптур эшләнмәләр, гадилеге һәм нәфислеге ягыннан, Казан Кремленең борынгы архитектур төгәллегенә аһәңдәшлек тудыралар. Аларны карап йөргән кешенең карашы төрле типтагы фигураларга төшә һәм гадәттән тыш төрлелекне чагылдырган микродөнья белән очраша. Алар, Көнчыгышның «тылсымлы бакчалары» кебек, тамаша кылып йөрүчене төрле фантазияләргә этәрәләр, ассоциатив фикерләр уяталар. Бу композицияләр, «Ташлар бакчасы» кебек, борынгылыкны һәм киңлекне күз алдына китерергә ярдәм итәләр, туристлык үзәгендәге тынгысызлыкны һәм шау-шу ритмын бозып, кеше күңелен мәшәкатьләрдән азат булган хыялый тирәлеккә этәрәләр. Алар, «чокылган изге тамгалар» — иероглифлар, табигый гәүдәләнештән ерак торган орнаментлар (арабесклар) кебек, серләрен (шифрларын) ачуны, интелектуаль игътибарны таләп итәләр, чөнки аларга яшерен мәгънәләр сеңдерелгән, алар символларга, тамгаларга һәм аллегорияләргә тартым.

Симпозиум барышында ачыкланганча, индивидуль пластик мөмкинлекләр ягыннан скульптура гаҗәеп бай, аны тематик мотивлар белән генә чикләү мөмкин түгел. Симпозиум кысаларында Казанның танылган остасы **Илдар Ханов** идеяләрен үтәп карау үзенә бер символик мәгънәгә ия. Аның хыялында 1970 еллар ахырында ук барлыкка килгән «Кешелек язмышы» дигән тема буенча яшь скульптор **Фәнил Вәлиуллин** (2014 елда В. Суриков исемендәге институтның Казан филиалын тәмамлый) эшләп күрсәтте. Метр чамасы үлчәмендәге зур булмаган бу композициянең элементлары тәртипсез рәвештә югарыга үрләгән өермәне хәтерләтә, бу алар динамикасындагы пластик форманы тоеп эшләүне таләп итә. Өч үлчәмле форма, күпертеп һәм уеп эшләүнең гипнотик (ясалма) ритмы чагылышы белән нәкъ менә шушы иҗатта очрашабыз. Әллә ни зур булмаган бу скульптура үзенә шундый энергия тупланышын, тормышны югары дәрәҗәдә тоюны сеңдергән ки, ул тамашачыда иҗат процессында автор тарафыннан кичерелгән тойгыларны уята. Бу хезмәткә төрле яктан игътибар белән карасаң, сынык һәм кискен линияләрдә берберсенә гармонияле, аһәңле итеп үрелеп үскән ике фигура — ир-ат һәм хатын-кыз бердәмлеге — һәммә тереклекнең башлангычын тәшкил иткән Илаһи бердәйлек чалымнары күзгә ташлана. Шул ук вакытта Илдар Хановның «Кешелек язмышы» — ул кителмәгән борылышлар һәм киртәләр белән тулы гомер юлы метафорасы, ул — зирәклеккә, югары акылга омтылу.

Уфа скульпторы **Руслан Нигъматуллин**ның «Ашина» дип исемләнгән нәфис һәм зәвыклы композициясендә, скульптураның рельефлы төзелеше үстерелә барып, Борынгы Мисыр сәнгате пластикасына аваздашлык тоемлана. Рәссам нәфис итеп чокып эшләнгән рельефта тоташ, талгын линияләр ярдәмендә, риваятьләрдән мәгълүм булган барлык төрки халыкларның ыру башы — әнкә бүрене гәүдәләндерә. Аның фигурасы пластик зифалыгы, нәзакәтле грациясе белән аерылып тора. Кул бөгелешеннән, иңнәренә таралып торган чәчләре белән ба-

шын июеннән, килешле итеп тез бөгүләреннән аның нәфислеген, дулкынлануын тоясың. Нәфислеге белән җир кешеләренекеннән аерылып торган бармаклары аның алиһәгә тиң образ булуын ассызыклый. Кешеләргә хас булмаган бөеклекне тудыру идеясе бу образның статик хәрәкәтсез, тораташсыман позасында чагылыш тапкан.

Мәскәү скульпторы **Таһир Сөбханкулов** иҗатында төп темаларның берсе — хатын-кыз матурлыгы. Аның стилистик эзләнүләре Европа сынчылары (Майоль һ.б.) традициясенә, XX гасырның өчтән беренче чорында иҗат иткән модернистларның (Бранкузи, Г.Мур һ.б.) экспериментларына таяна. Останың «Кабан күле серләре» скульптурасы зәвыклы грациясе һәм пластик матурлыгы белән кыйммәтле. Бу хатынның түгәрәк тыгыз тәнендә борынгы цивилизацияләр ташлары да, таш балбаллар сыннары да, шулай ук Г. Мур, А. Майоль хезмәтләренә охшашлык та чалымлана. Анда яткан хәлдәге фигурага хас динамиканың иң югары дәрәҗәсе яуланган, бер үк вакытта юмор белән монументальлекнең, дәрт белән сүлпәнлекнең үзенчәлекле бәйләнеше чагылыш тапкан.

**Рөстәм Габбасов**ның (Казан) «Моң» скульптурасы үзенең табигыйлеге һәм хәрәкәтләренең көйле ритмы белән аерылып тора. Ул курайда уйнаучы музыкантны гротеск рәвешендә символлаштырып гәүдәләндергән. Кайсы яктан якын килсәң дә, бу хезмәт тәэсирле итеп башкарылган. Автор музыканың сихри магиясен һәркемнең күңеленә үтеп керерлек итеп бирә алган. Курайчының фигурасы, өслегән шомартып эшләү нәтиҗәсендә, чынчынлап графиканы хәтерләтә. Җыйнак итеп, аерым детальләрне күрсәтми генә эшләнеше белән ул тамгага охшап кала һәм үзенә юнәлдерелгән яктылыкта аны кабул итүнең яңадан-яңа нюанслары ачыла.

Әгәр дә тамашачы «Моң»ны Галәмнең бер әйләнәдә туктаусыз хәрәкәт итүе белән тиңләп кабул итә икән, **Асия Миңнуллина**ның «Гаскәри» фигурасы үзенең рельефка омтылган төрки шәрык традицияләрен дәвам итүе, фронтальлеге, эпиграфикага аваздашлыгы белән игътибарны бер ноктага туплауга исәп тотып эшләнгән. Сугышчының тулы киң яңаклы йөзе матурлыкның төрки тибы үрнәген чагылдыра. Авторның башлангыч нияте җәячене (җәядән атучыны) гәүдәләндерү булса, симпозиум вакытында ул Казан Кремлен саклаучы образын тудырырга карар кыла. Җәя шәһәр сакчысы символы саналган калканга алыштырыла.

Төркия сынчысы **Метин Кар**ның «Гашыйк» дигән абстрактлы динамик композициясе шактый гадиләштерелгән. Ул гарәп хәрефләре пластикасын хәтерләткән ике антропоморф формадан гыйбарәт булып, ислам мәдәниятендә кешене чагылдыру үзенчәлекләренең берсен тасвирлый. Автор күңелгә кабул итүнең яңадан-яңа ситуацияләренә юл ачкан мәңгелек матурлыкны, зирәк әйтемнәрне, метафорик күзаллау мөмкинлеген тамашачының хәтеренә төшерә. Бу сында каршылыкны да, бердәмлекне дә, кодрәтне дә, гаҗизлекне дә, шул ук вакытта вертикальнең югарыга омтылышын — Илаһи тантаналылыкны да тоясың. Сынчы оста аморф массадан тере образ тудырырга омтылуын үз эшендә эшкәртелмәгән материал эзләре саклануы аша күрсәтергә тырышкан.

Азәрбайҗан сынчысы **Мамед Рашидов**ның (Баку) скульптурала-

рында борынгы фигуратив һәм орнаменталь мотивларга мөрәҗәгать итәргә омтылу күзәтелә. Аның эшенең монументальлеге аңлы рәвештә борынгы мотивларны сайлауга нигезләнгән: беренчедән — музыка белән бәйле («гавалдаш» — төркичә — «таш-бубен»), икенчедән — «таш-балбал», саклаучы һәм яклаучы «тотем багана». Автор, ташның табигый төсләре гаммасын саклау максатыннан, архитектур өслеккә бүгенге граффитистның дивар-коймаларга ясаган рәсемнәре кебек, ачык төсләр белән эксперимент ясый. Патина (металларның, ташларның тышкы тәэсирләрдән табигый төсләрен үзгәртүе) эффектындагы төсләр белән эш итү ташларга тагын да борынгылык һәм табигыйлек өсти. Таш өслегенә төшерелгән тылсымлы рәсем — «идиограммалар», почмакланган сырлар һәм штрихлар, горизонталь полосалар, өчпочмаклар үзләренең график формалары һәм линияләре белән ташның геометрик монолитлыгын ассызыклыйлар. Тотемнарның тылсымлы һәм серле Шүрәлене хәтерләткән могҗизави формалары борынгы кешеләрнең кыяны уеп сыннар ясавын хәтерләтә.

**Айдер Алиев**нең (Кырым) «Утрау» дип исемләнгән скульптур композициясе, бер яктан — Евразия, икенче яктан — Көнчыгыш белән Көнбатышның мәдәни традицияләрен сеңдергән Кырым ярымутравының феноменын пластика телендә гәүдәләндерүгә багышланган. Анда табигать стихиясе, кыялар һәм үрләр стихиясе, диңгез романтикасы, яктылык һәм шәүлә чаткылары җемелдәве тантана итә. Җиһанның хәрәкәтен тою һәм тереклекнең мәңгелеген аңлау, билгесезлек һәм төшенеп булмый торган әйтеп бетермәгәнлек — болар әлеге символик скульптураның төп сыйфатлары. Аның өслеге пластик массаларның хәрәкәтчәнлеген, тылсымлы көчләр белән хәрәкәткә китерелгән һәм әле хәзер дә тынычлана алмаган пластик субстанциянең җанлылыгын хәтерләтә.

Казанда булып узган «Таш моңы» дип аталган Халыкара симпозиум, бүгенге иҗади процессның социаль-мәдәни феномены буларак, зур иҗади мөмкинлекләрне ачыкларга ярдәм итүен раслады.

Беренчедән, ул төрле регионнардагы профессионаллар белән иҗади элемтәләр урнаштырырга һәм бердәм мәдәни пространство булдырырга нигез бирә. Икенчедән, төрле буын рәссамнарының иҗади мәгълүмат алмашуларын тәэмин итә, тамашачылар белән иҗатчылар арасында турыдан-туры контакт урнаша һәм аларга скульптура барлыкка килүнең җанлы процессын күзәтү мөмкинлеге туа. Өченчедән, симпозиум эшендә бу өлкәнең заманча үсеш тенденцияләре ачыклана һәм, шуннан чыгып, яңа перспективалар билгеләргә нигез барлыкка килә. Ә нәтиҗәләрнең иң мөһиме — Казан Кремле территориясендә гаҗәеп кызыклы пластик әсәрләр иҗат ителде, алар безнең хәтергә Казаныбызның 2014 елда төрки дөньяның мәдәни башкаласы дигән горур исемгә өстәлгән җанлы үрнәкләр булып уелыр.

***Солтанова Рауза Рифкать кызы**, сәнгать фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге җитәкчесе*
*E-mail: rauzasultan.art@mail.ru*

УДК 76:821.512.145

*М.Р. Газизова*

# «ЧАЯН» ЖУРНАЛЫНДА ТУКАЙ ҺӘМ АНЫҢ ПЕРСОНАЖЛАРЫ (1950—1980 еллар)

Статья посвящена изучению того, как тема татарского поэта Г. Тукая и персонажи его произведений использовались художниками-сатириками на страницах сатирического журнала «Чаян». Примечательно, что к образу самого Тукая художники обращались, чтобы коснуться достаточно возвышенных тем: объединения народов, стремления к миру, почитания своих корней; либо же Тукай выступал олицетворением мудрости. Персонажи его произведений часто использовались сатириками, чтобы обратить внимание читателей на тот широкий круг проблем, который существует на сегодняшний день в нашей стране и мире в целом. Особенно был популярен образ Шурале.

**Ключевые слова:** журнал «Чаян», Тукай в изобразительном искусстве, карикатура, сатира в искусстве графики, Шурале.

Милләтебезнең яраткан шагыйре Г. Тукай — татар әдәбиятында сәяси һәм иҗтимагый сатира жанрларына нигез салучыларның берсе. Үз заманының иң актуаль проблемаларын тәнкыйть утына тоткан шигырь, поэма, фельетоннары газета-журналларда даими басылып килгән. Шагыйрьнең ачы сарказмы астына буш вәгъдәләр белән йөргән сәясәтчеләр дә, үзләре үк шәригать кануннарын бозган руханилар да, фабрика-заводларында кеше чыдамаслык эш шартлары булдырган эшмәкәрләр дә эләгә. Шагыйрь Тукайның исә әдәбиятта гына түгел, ә татар сынлы сәнгатендә дә сатира жанры үсешенә йогынты ясавы аерым игътибарга лаек.

Татарстанның сатирик графика сәнгатендә Тукай образы, аның персонажлары дистә еллар буена актуальлеген саклап, һаман басыла килә. Сатирик рәссамнарга Тукай темасы якын, алар шагыйрь иҗатын тирән аңлап, аның яраткан ысулларын — ирония, сарказм, гротеск, пародияне — кулланып эш итәләр. Тукай әсәрләре персонажларыннан төзелгән җыелма образлар еш кына карикатура геройлары булып китәләр. Бу очракта рәссам, Тукайның сатирик әсәрләренә мөрәҗәгать итүдән бигрәк, аның иң билгеле әсәрләренең геройларын куллана.

Тукай темасының Татарстан сынлы сәнгатендә, шул исәптән нәкышь, графика, скульптурада, чагылыш табуы шактый өйрәнелгән. Ләкин сатирик рәссамнар иҗаты бу җәһәттән каралмаган диярлек. Без исә «Чаян» журналы мисалында бу теманың үсешен тикшерергә булдык. «Чаян» — Татарстан Республикасында бердәнбер сатирик журнал, Россиядә юмористик басмаларның иң олыларыннан берсе. Журнал 1923 елда дөньяга килә. Шул заман вазгыятеннән чыгып, карикатура геройлары — муллалар, байлар, кулаклар, бюрократ һәм милләтчеләр. Төп игътибар ил эчендә барган вакыйгаларга юнәлтелә, халыкара сатира алай күп урын алмый. 1941 елда «Чаян»ның бер генә саны чыгып кала. Басма 1951 елда гына яңадан торгызыла. 1950—1980 еллар — журналның чын-чынлап чәчәк ат-

кан чоры. Бу вакытта ул укучылар арасында зур популярлык казана. «Чаян»га чын мәгънәсендә карикатура осталары — И.Е. Бобровицкий, Э.Б. Гельмс, Д.Г. Булат, И.С. Хантимеров һ.б. килә. 1950—1980 елларда популяр сатира темалары төрле: көнкүрешкә дә, иҗтимагый тормышка да, халыкара тематикага да зур урын бирелә. «Чаян» бүгенге постсовет пространствосында сакланып кала алган сатирик басмаларның берсе, ул традицияләрен саклап, заман белән бергә атлавын дәвам итә.

«Чаян»да Тукай темасы беренче тапкыр 1953 елда 7 номерда басылган, шагыйрьнең вафатына 40 ел булуга багышланган материалда очрый. Тукай образы журналның тышлыгында китерелгән. Рәссам Х. Усманов тышлыкның уртасына Тукай фотосын куйган. Фото журнал битен икегә аерып тора: бер як акка кара белән ясалган рәсем (ярлы крестьян кечкенә генә авылда җир сөрә), икенче якта — төсле рәсем (заманча шәһәр күренешләре, крестьян җирне инде комбайн белән сөрә). Автор уенча, Тукай хыялланган якты җитеш тормыш чынга ашкан.

Л. Фәттахов ике халыкның бердәмлеге темасына мөрәҗәгать итә (Чаян. 1957, № 9, б. 4). «Олуг юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре» шигыренә таянып, ул рус егете һәм татар кызының шагыйрь һәйкәленә чәчәкләр китерүен күрсәтә. 1957 ел ил тарихында шактый кызыклы: беренчедән, Мәскәүдә Татарстан Республикасы әдәбияты һәм сәнгате декадасы үтә, икенчедән, VI Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивале булып уза. Шуңа мөнәсәбәтле билгесез авторның «Чаян» журналының 1957 елгы 9 нчы санында басылган рәсеме кызыклы (б. 6): төрле милләттән булган яшьләр белән бергә Шүрәле атлый, ул инде урманның явыз көче түгел, шаян, күңелле, куллары да азат. Янәшәсендә — Батыр, урман шаянын күзәтә. Автор-рәссам Тукай әсәрләренең халык арасында популяр булуын һәм күп телләргә тәрҗемә ителүен күрсәтергә тели.

Тукай әсәрләре арасында ялагайларны көчле сатира утына алган ярымкөлке шигырьләр шактый. М. Гайнуллин язганча: «Часто ирония Тукая достигает жгучего сарказма. Стремясь наиболее ярко вскрыть социальные язвы, поэт прибегает к приему большой силы: нарисовав явление как бы положительно, он в последней заключительной строфе показывает подлинную отрицательную сущность его. Парадоксальное и алогичное соотнесение описываемого и действительного помогает Тукаю достичь той степени иронии, когда она переходит в сарказм» [Гайнуллин, с. 105]. Шагыйрьнең андый әсәрләре 1950 елларда да актуальлеген югалтмый, журнал битләрендә урын ала килә. Рәссамнар исә, шундый ук ирония кулланып, аларга карикатуралар ясыйлар. Мәсәлән, И. Игламов ялагай образын бик төгәл күрсәтә (Чаян. 1953, № 7, б. 3). Бер рәсемдә ялагай коллегасын зур ихтирам күрсәтеп мактый, ә икенчесендә — бик «текә» кыяфәт чыгарып, аның турында чираттагы гайбәтне сөйли. Бу темага «Ялагай» дигән тагын бер рәсем бар (шунда ук). Җитәкчесе алдында реверанс ясап, ялагай аның һәр хәрәкәтен диярлек тотып ала. Язмасы да бар: «Партнерыннан алда тәмәкесен дә кабызмый хәтта!»

Тукай темасы сәяси сатирада да кулланыла. Шагыйрь тудырган төр тискәре геройларга нигезләнеп, дөньякүләм сәяси лидерларның ке-

шелеклелек сыйфатларын югалтуын күрсәтү — төп максат булып тора. Бу темага К. Шаммазов рәсеме кызыклы (1953, № 7, б. 6—7). Нигез итеп «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» алынган. Рәсемнәргә бирелгән башисем дә шулай ук диярлек яңгырый: Янки базары, яхуд яңа Кисекбаш. Сатирик АКШ сәясәте һәм фашистлар режимы арасында параллельләр үткәрә: журнал битенең бер ягында АКШ флагыннан тегелгән һәм тәңкәле акча тутырылган капчык, икенче ягында — Гитлер башы. Сугыш бетүгә карамастан, фашизм күләгәсе Гитлер башы кыяфәтендә Европа буйлап йөрүен дәвам итә. Сәяси аренада АКШ акчасы күп нәрсәне хәл итә, яңа сугышлар башларга нигез булып тора, шул акчага Европаның иң эре сәясәтчеләре сатып алынган. Европа картасы өстендә сыртлан (гиена) басып торуы да очраклы түгел, бу — яңа куркыныч барлыгын, көрәшнең туктамавын күрсәтә, ә солых һәм килешү һаман юк.

1960—1970 елларда чыккан «Чаян»да Тукай темасы шулай ук популяр булып кала. Бу чорда аның персонажлары күбрәк көнкүреш сатирасында файдаланыла. Шүрәле — әлбәттә, иң популяр герой. Нинди генә ситуацияләргә эләкми ул!.. Рәссам И. Игнатьев каләменнән төшкән «Яңа өйдә» рәсемендә (1960, № 14, б. 8) әле бүген дә актуаль булган төзүчеләр темасына мөрәҗәгать ителә. Төзүчеләр һәм подрядчиклар, акча экономияләү йөзеннәнме, әллә вакыт кысан булгангамы, яшәү өчен яраксыз диярлек йортлар салалар. Рәсемдә исә Шүрәле, яңа йорттан фатир алып, урманнан шунда күченә. Фатирга кереп тә өлгермәстән, аягы белән идәнгә кысыла. Язуы да кызыклы: «Тагын кыстылар!».

Иҗтимагый сатираның тагын бер үрнәге булып И. Хантимеров рәсеме тора (1961, № 7, б. 9). Нигез итеп «Җегетләр» шигыре алынган. Рәсем шигырь сюжетын 1960 еллар җирлегенә күчерә. Гөлчәчәкләр сибелгән келәм буйлап вәкарь генә яшь егет атлый. Ул ата-анасының бөтен нәрсәне дә алып бирүләренә шулкадәр күнеккән, тормышта башка нәрсәләр дә шулай булырга тиеш, дип уйлый.

Журналның шул ук битендә Тукай темасына тагын бер жанр кулланыла — дусларча шарж. Мәсәлән, П. Новичков рәсеме. Автор Шүрәле өчен шактый көтелмәгән образ эшли — интеллигент. Шүрәле өстенә затлы пальто киеп алган, дөнья буйлап сәяхәт итә, кулында чәчәкләр бәйләме, тамашачылар бүләге, күрәсең. Рәсемне вак детальләренә кадәр уйлап эшләгән автор геройның милли булуын ассызыклый: башында түбәтәй, өстендә чуар күлмәк, кыска гына сакал һәм хәйләкәр караш. Рәсем асты язмасыннан күренгәнчә, бу эш безне «Шүрәле» балетына илтә икән. Бу балет Европа театрларында уңыш белән бара. П. Новичков ассызыклаганча, «Шүрәле» поэмасы да күп илләр тамашачылары арасында абруй казанган.

1960—1970 еллар арасында басылган карикатуралар арасында экология, браконьерлык темасы популяр. Бу тема Б. Старчиков рәсемендә дә чагылыш таба (1965, № 23, с. 4). Рәсем сюжеты буенча Шүрәле үзе тоткан браконьерны хакимият кулына тапшыра. И. Хантемиров авторлыгындагы рәсемдә исә нык ачуы килгән Су анасы завод пычраткан сулыктан чыгып килә. Янәшәсендә — үлгән балык, ә экологик күзәтү инспекторы, Су анасы үченнән куркып, куаклар астына яшеренгән (1976,

№ 7, с. 6). Шуны да әйтеп китик, автор Су анасын нимфа образында, ягъни шәрә хатын-кыз итеп бирүдән курыкмаган: «Чаян» рәссамнары бу вакытларда ню алымын бик кулланмыйлар әле.

«Кәҗә белән сарык хикәясе» пероснажлары да «Чаян» битләрендә еш күренә. И. Әхмәдиев карикатурасында, мәсәлән, СССРда колач җәйгән планлы икътисад темасы күтәрелгән. Кайчакта чынбарлыктан шактый ерак торган планнарны үтәү темасына багышланган рәсемдә бүре-начальник хезмәткәрләре Кәҗә белән Сарыкка шелтә белдерә, янәсе, 12 урынына 1 генә бүре башын китергәннәр (1974, № 18, с. 5).

Л. Насыйровның, «Шүрәле» темасын нигез итеп алып, Бөек Җиңүнең 30 еллыгына багышлап «Чаян»ның тышлыгында чыгарылган (1975, № 8) рәсеме халык лубок картиналары стилендә эшләнгән. Батыр образында — совет солдаты, Шүрәле образында сугыш алласы Марс гәүдәләнгән. Поэмадагы кебек үк, Марсның кулы бүрәнә ярыгына кысылып калган, ә солдат, бүрәнә өстендә тәмәке тартып утырган килеш: «30 ел элек кыстырдым», — ди.

Тагын 2 кызыклы гына сюжет Э. Гельмс (1970, № 16, с. 12) һәм Х. Әхмәтҗанов (1979, № 4, с. 2) тарафыннан эшләнгән. Шүрәле образын кулланып, Э. Гельмс урман җан ияләренең тулы бер гаиләсен тудыра. Бу рәсемнәрдә «Чаян» журналына реклама бара: бүрәнәдә кысылып калган Шүрәлегә ярдәм йөзеннән берсе «Чаян» күтәреп килгән. Журнал боларга шулкадәр ошаган, хәтта кысылган Шүрәле дә, кулы авыртуын онытып, «Чаян» мәзәкләреннән көлә. Х. Әхмәтҗанов Шүрәле образын законсыз урман кисү һәм алкоголизм темаларын яктырту өчен куллана. Монда Шүрәле сәрхүш итеп күрсәтелгән, ә браконьерлар исә, аны исертеп, законсыз киселгән агачларны алып китеп баралар.

1980 елларда Тукай персонажларын сатирик рәсемнәрдә куллану кими. Шулай да кызыклы образлар очрый. Төп темалар булып көнкүреш һәм иҗтимагый сатира тора. Иң популяр герой — шул ук Шүрәле. Э. Дышаев җиңел ироная белән бу юлы инде автобус ишегенә кысылып калган Шүрәлене күрсәтә (1981, № 9, с. 8). Шул ук авторның совет кешеләре өчен яңа тема — имениятләштерүгә багышланган рәсеме дә бар (1985, № 7, с. 7). Имият агенты урманда Шүрәлене эзләп табып, аңа төрле куркыныч хәлләрдән страховка эшләргә өнди. СССРда 1985 елда кабул ителгән «коры закон» темасына А. Шульпинов мөрәҗәгать итә (1988, № 10, тышлык). Рәсем законсыз рәвештә аракы куу темасына корылган: автор фикеренчә, бу продукт начар сыйфатлы булганга, бик еш үлемгә китерә. Сюжет — Убырлы карчык яшерен генә аракы куа, ә ишектән кинәт Шүрәле килеп керә. Коты алынган Убырлы карчык: «Куркытып йөрисең инде, Шүрәле! Участковый дип торам!» — ди.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин, Тукай һәм аның персонажлары темасы «Чаян» журналы битләрендә шактый еш урын ала. Бу темага караган рәсемнәр рәтендә юбилей даталарына багышланган Тукай портретлары да, шагыйрьнең сатирик шигырьләренә иллюстрацияләр дә, персонажларын кулланып эшләнгән карикатуралар да, шаржлар, сәяси плакатлар да бар. Тукайның үз образына мөрәҗәгать иткәндә, авторлар югары темалар күтәрәләр: халыклар дуслыгы, тыныч-

лык, ата-баба мирасын саклау һ.б. Ул аксакал сыйфатында да, гыйлем туплаган кеше буларак та гәүдәләнә. Персонажлары исә дөнья һәм ил күләмендә актуаль булган теге яки бу проблемага халык игътибарын җәлеп итү максатыннан кулланыла. Бигрәк тә Шүрәле образы популяр. Нинди генә ситуациягә эләкми ул, нинди генә көлке хәлдә калмый. Ул күбрәк көнкүреш һәм иҗтимагый сатира кысаларында файдаланыла. Рәссамнар исә аны бервакытта да куркыныч итеп сурәтләмиләр, Шүрәле аралашучан, шат күңелле, бераз самими итеп күрсәтелә. Сәяси һәм халыкара темаларга багышланган сатира рәсемнәрендә дә рәссамнар Тукай персонажларын яратып кулланалар. Мәсәлән, «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» әсәрен, шигырь мотивларын атарга була. Кешегә хас иң түбән сыйфатларны фаш итү йөзеннән, Тукай шигырьләренең иң ачы теллеләренә иллюстрацияләр иҗат ителә. Әйтергә кирәк, Тукай каләменнән төшкән җыелма образлар бүген дә актуаль, шуңа да рәссамнар бүгенге җәмгыять проблемаларын ачу максатыннан әле һаман аларга мөрәҗәгать итеп торалар.

**Әдәбият**

*Амирханов Р.* Татарская дореволюционная пресса в контексте «Восток-Запад». Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. 240 с.

*Габдулла Тукай.* Избранное. Стихи. Поэмы. Сказки. Казань: Татар. кн. изд-во, 1969. 419 с.

*Гайнуллин М.* Татарская литература и публицистика начала XX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. 350 с.

*Червонная С.* Искусство Советской Татарии. М.: Изобразительное искусство, 1978. 293 с.

***Газизова Марина Ренат кызы,***
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге аспиранты*
*E-mail: gazizovamr@yandex.ru*

## ТӨРКИ «ЙОСЫФНАМӘ»НЕ БАРЛАУ ЮЛЫНДА: Нурмөхәммәт Хисамовның «Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә» (XIII—XV йөзләр)» хезмәте

Төрек телендә татар китабы басылып чыгу хәзерге көндә гайре табигый хәл түгел. Утызынчы еллардан тамыры киселгән бу күренеш бары тик туксанынчы еллар башында яңадан әкренләп тернәкләндерелә башлады. Елдан-елга мондый аралашулар куәтләнә торды. Соңгы вакытларда китаплар алмашу да эзлекле төс ала барды. Аларның тугандаш халык телендә Истанбулда, Әнкарада, Искешәһәрдә басылуы китаби үсеш ягыннан аеруча зур традицияләре булган кавемнәребезнең мөнәсәбәтләрен якынайтуда аеруча мөһим гамәл булып тора.

Менә Кара диңгез белән Ак диңгез арасында урнашкан төрки кардәшләребез илендә тагын бер татар китабы дөнья күрде. Сүз күренекле әдәбиятчы-галим Нурмөхәммәт Хисамовның «Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә» (XIII—XV йөзләр)» дигән китабы турында бара. Татарчадан төрек теленә тәрҗемә итүчеләр Әнкара университеты мөгаллимнәре Паша Явызарслан һәм Бүләнт Бәйрәм. Бу зыялы егетләр туксанынчы елларда, Татарстанга килеп, төрек лицейларында эшләп, безнең телебезне дә камил итеп өйрәнгәннәр иде. Китап Әнкараның «Turk DiI Kurumu» нәшриятында басылган.

Без инде, Нурмөхәммәт Хисамов диюгә, аңыбызга «Йосыф» исеме дә килүенә күнеккәнбез. Коръәннән үк күңелебезгә сеңгән бу исемгә кагылышлы шәрехләүләр, Шәрык әдәбиятларында иң затлы мәүзугларның берсе буларак, билгеле әдипләрнең сурәтләү традицияләре тагын да яңартылып һәм өстәлеп башка каләм әһелләренә күчә-күчә, тулы бер махсус әдәби оя барлыкка китергән. Гәрчә әлеге сюжет китаплы башка диннәр кавемнәренә дә таныш булуга карамастан, аларда бу образны уртага куеп сурәтләү киң таралыш алмаган. Монда төп сәбәп шушы мәүзугка мөрәҗәгать иткән Шәрык сүз сәнгате осталарының чагыштыргысыз дәрәҗәдә талантлы булулары һәм әсәрләрне язганда үз алларына куйган максатларның зурлыгы һәм затлылыгы булса кирәк. Коръәннең уникенче сүрәсендә бәян ителгән вакыйга Шәрык даһиларын сәнгатьчә, берсеннән-берсе гүзәл әсәрләр тудыруга илһамландырган. Изге китабыбызның Ногмани тәфсирендә әйтелгәнчә, аңарда «Гакыл ияләренә гыйбрәтләр бар. Коръән хак китаптыр вә һәрнәрсәнең хөкемен бәян итеп иңдерелмештер» [Коръән..., б. 259]. Әйе, биредә бәян ителгәннәрнең иң төп бурычы — ул да булса адәм балаларына чын мәгънәсендә асыл табигатьле булу өчен нинди хәл-әхвәлләрдә үзеңне ничек тоту мәслихәт, шул ук вакытта нинди булу ярамый икәнлекне күрсәтеп бирү. Башка бик күп сүрәләрдән аермалы буларак, биредә нәрсәнең яхшы, нәрсәнең яман икәнлеге кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне шәрехләү ярдәмендә, ягъни тормышчан мисалларга

нигезләп аңлатылган. Шушыларны җентекләү барышында Аллаһының төп сыйфатлары да ассызыклана. Болар, әлбәттә, каләм осталарында Йосыф башыннан үткәннәрне укучыларга һәм тыңлаучыларга тагын да тәэсирлерәк һәм җир кешеләренә хас гадиерәк һәм эзлеклерәк җиткерү ихтыяҗын тудырганнар. Табариның «Олуг тәфсир»е, Фирдәүсинең «Йосыф вә Зөләйха» поэмасы, Габдуллаһ Әнсаринең «Әнисел мөридин» дигән чәчмә әсәрләре моның беренче күркәм адымнары һәм уңышлы мисаллары иде. Коръәндә җыйнак кына бирелгән юлларны тасвирый итеп сурәтләүнең башлангычы нәкъ менә алардан юл ала. Ләкин әлеге әсәрләр, төрки телдә булмаулары сәбәпле, безнең борынгы әби-бабаларыбызга ераграк торганнар.

Әдәбият үсешендә сәнгатьчәлек традицияләренең әһәмияте әйтеп бетергесез мөһим. Әйтик, Й. Баласагунлы («Котадгу белек»), Ә. Ясәви, С. Бакырганилар юл салган өслүб, шәкел һәм гәүдәләнеш арсеналының тупланмасы булмаса, мондый дөньякүләм уртак сюжетка алыну мөмкин булыр идеме икән? Кол Галинең болардан хәбәрдар булганлыгы шик тудырмый. Ягъни төрки әдәбият казанышлары аңа яхшы таныш булган. Шулар өстенә классик гарәп һәм фарсы телләре дә аның өчен ят түгел. Чөнки, бу телләрдәге әдәби казанышларга нигезләнмичә, мондый сюжетка мөрәҗәгать итеп булмаганлыгы үзеннән-үзе аңлашыла. Кыскасы, ул үз заманы әдәби-филологик казанышлар югарылыгында тора. Шул ук вакытта аның бу мохиттә үз карашы да бар. Әйтик, сюжетның үзәген тәшкил итүче кысаларга таяна, ләкин аңа гына хас булганча эш итә. Аның, хәзергечә итеп әйткәндә, бу новаторлыгы мәңгелек һәм үзгәртелмәс булып канунлашкан хәл-әхвәлләрне үзе тойганча яңартып тасвирлавын китереп чыгара. Н. Хисамов гомуми фонда нәкъ менә К. Гали алып килгән үзенчәлекләрне барлауга, аның төрки дөньяда бу сюжетны эшкәртүнең юл башында торуын дәлилләү эшенә алынган. Бу гаять катлаулы бурычны тормышка ашыруга гыйльми яктан нык әзерлекле, дөнья әдәбиятларының, аерым алганда, гаять күпкырлы Шәрык сүз сәнгатьләренең тарихын һәм хасиятләрен җилегенә төшеп белгән галим һәм шагыйрь генә алына ала. Юкса, аны нәтиҗәләренең, карашларының бары тик хосусый булып калу ихтималы сагалап тора.

Безнең халыкта «бер тамчы суда кояш чагыла» дигән гыйбарә бар. Ягъни әнә шул күз яше кадәр генә микъдардагы су бөртегенә күге безнең иң зур җисеме дә сыя ала икән. Шуның шикелле, «Кыйссаи Йосыф» әсәренең төрки әдәбиятлардагы тоткан урынын ачыклау өчен дә дөнья сүз сәнгате, аның тарихы, анда «ат уйнаткан» шәхесләрнең гамәлләрен һәм карашларын, үзара иҗади мөнәсәбәтләрен, шул гасырлардагы рухи кыйммәтләрнең төрле җәмгыятьләрдә тоткан урыннарын һәм тагын бик күп мәгълүматларны нечкәләп белергә кирәк. Нурмөхәммәт Шаһвәли улы менә шундый дәрәҗәдәге әзерлекле шәхес.

Үзенең билгеле бер зур китабын өч-дүрт айда язып бетергәнлеген әйткәч, бер акыл иясеннән сораганнар:

— Шундый катлаулы һәм үтә тирән фикерле хезмәтне ничек өч-дүрт айда барлыкка китерә алдыгыз?

Акыл иясе әйткән:

— Дөресен әйткәндә, моны — әлеге өч-дүрт айга бөтен гомеремне

кушып, дип аңларга кирәк.

Н. Хисамовның да әлеге китабы гомер буе алып барган тикшеренүләренең нәтиҗәсе. 1979 елда Мәскәүнең «Наука» нәшриятында «Поэма «Кысса-и Йусуф Кул Али» һәм 1984 елда Татарстан китап нәшриятында басылган «Бөек язмышлы әсәр» монографияләре фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан галимнең бу өлкәдә алып барган тикшеренүләренең бик саллы нәтиҗәләре буларак кабул ителгән иде. Х. Күроглы, Г. Таһирҗанов, Ә. Тенишев кебек олы галимнәр белән аралашып һәм дә мәслихәтләшеп эш итүе Н. Хисамовның бу даирәдә үз кеше икәнлегенә дәлил. Татар укучысы өчен сүз бара торган китап та яңалык түгел. Ни өчен дигәндә, ул, 2006 елда туган телебездә Татарстан китап нәшриятында басылып, укучылар кулына килеп кергән иде инде. Ул вакытта филология фәннәре докторы Х.Ш. Мәхмүтов белән безгә әлеге китапка эчке бәяләмә язу, аны киң даирә укучыларга тәкъдим итү насыйп булган иде. Менә инде сигез елдан соң, тагын да камилләштерелеп, хезмәт бөтен төрки дөнья киңлегенә тәкъдим ителә. Татарстанның халык шагыйре Р. Харисның кыска гына, әмма тирән фикерләр уздырылып язылган кереш мәкаләсе белән ачылган бу китап төрле илләрнең галимголәмәсен, рухи тамырларыбыз, кардәшлегебезнең нигезләре турында уйланучы зыялы затларны җәлеп итәчәгенә шикләнмәскә мөмкин. Чөнки «Кыйссаи Йосыф» хакында кызыксыну бервакытта да тукталып тормады. Хәтта аның кайсы төрки кавемгә нисбәтле булуы турындагы бәхәсләргә әле дә юлыгырга мөмкин. Гәрчә бу хакта фәндәге абруйлыларыбыз күптән уртак фикергә килгән булсалар да. Күренекле профессор Г. Таһирҗанов сүзләре бу җәһәттән бәхәскә урын калдырмый. «Әсәрнең теле, стиле һәм рухы татар халык сөйләменә якын. Менә шуның өчен дә татар укучылары аны төрлечә көйләп, үзенчә якын итеп, ихлас күңелдән яратып укыганнар» [Таһирҗанов, б. 94]. Әмма кайбер милләтләрнең зыялылары, без дә өлешсез калмыйк, дип, болгар-татар шагыйрен үз якларына тартуны дәвам иттерәләр. Бу хакта Татарстан Республикасы Дәүләт бүләге иясе М. Әхмәтҗановның әле яңарак кына «Кол Гали һәм «Йосыф китабы» дигән мәкаләсе дөнья күрде [Мәдәни..., б. 14—15]. Ул анда субъектив нигездә чыккан әлеге бәхәсләрнең сәбәпләрен тәфсилләп ачыклый, бу мәсьәләдә методологик таяныч булырдай карашлар белән чыга. Үзенең әлеге китабында Н. Хисамов та мондый икеләнүләргә урын калдырмый. Кол Галине болгар-татар шагыйре дип атый (бу мәсьәлә үзебез өчен ачык булса да, читләрнең колагына тагын бер тапкыр әйтеп кую артык түгел). Соңгы унъеллыкларда «болгар» этнонимы тирәсендә шау-шулар куертылса да (бигрәк тә татарны болгар дип алыштыруны яклаучылар тарафыннан), «татар» этнонимына карата мәсьәлә хәл ителгән. Төрки халыкларның берсе дә инде «татар» этнонимына дәгъва кылмый. Без исә бу исем белән горурланабыз, һәм, Н. Арслан әйткәнчә, шушы исем белән «киләчәктән урын барлыйбыз».

Н. Хисамовның төрки телдәге Йосыф пәйгамбәр язмышына бәйле әсәрләр белән эш итүе Г.У. Имәни эшчәнлеген хәтерләтә. «Кыйссаи Йосыф» текстының төрлечә үзгәртелеп язылуына игътибар иткән Г.Утыз Имәни, күп кенә күчермәләрдән бер төзек нөсхә барлыкка китереп, мон-

дый төрлелеккә чик куя. Н. Хисамов та дөньядагы төрки телләрдәге версияләрне (ул аларны төрдәш дип атый) тирәнтен белгән хәлдә, шул контекстта Кол Гали язган әсәрнең текстын җентекли һәм бик тә мөһим нәтиҗәгә килә — «Төрки Йосыфнамәне башлап җибәрүче Кол Гали булган». Кыйссаның төрки халыклар тарафыннан да яратып кабул ителүенең бер сәбәбен, «төрки дастан эпосы һәм тылсымлы экият традициясе»нең табигый кулланылышында күрә. Мондый раслау хезмәтнең буеннан-буена бихисап мисаллар белән ныгытылып бара. Димәк, без урта гасырлар болгар-татар шагыйрен үзенә кадәрге төрки рухи хәзинәләрне күңеленә бик яхшы сеңдергән зат буларак та күрәбез. Һәм инде аннан соңгы гасырларда Йосыф сюжетын сәнгатьчә эшкәртергә алынган төрки каләм әһелләренең Кол Галигә мөрәҗәгать иткәнлекләрен билгеләү кебек шактый катлаулы эшне Н. Хисамов башкара. Ул, иң әүвәл, төрки «Йосыфнамә» кысаларында иҗат итән авторларны билгели, аларны хронология тәртибендә өйрәнә, эзлеклелекне күрсәтеп бирә. Шул рәвешле, әйтергә яраса, «Йосыфнамә»не иҗат итү чылбыры барлыкка килә: Кол Гали — Шәййад Хәмзә — Сули Фәкыйһ — Әхмәди — Хәмди. Әхмәди версиясе буенча шушы ук чылбырга Дүрбәк тә килеп тоташа. Н. Хисамовка аларның үз әсәрләрен иҗат иткәндә ни рәвешле Кол Галигә барып чыгуларын күзәтү кызыклы, ул моны мавыгып, әйтергә кирәк, бу талант ияләренең осталыкларын бәяләүдә төгәл эш итә. Монда инде Н. Хисамовның әлеге талантлар чылбырындагы төрки элгәрләребезгә ихлас хөрмәте һәм алар иҗатына игътибарлылыгы күренә.

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре сюжетында катлаулы, төп герой язмышына кагылышлы борылышлар шактый, вакыйгалар тезмәсе бик төрле хәлләрне эченә ала. Шуңа күрә кайбер тикшерүчеләр әсәрне, роман жанрына туры килә, дип тә билгеләделәр. Ләкин, шуңа карамастан, ул — поэма, тагын да төгәлрәк әйткәндә, маҗаралы лиро-эпик поэма. Чөнки әсәрнең «Кыйссаи Йосыф», ягъни «Йосыф хикәяте» дип аталуы да шуны күрсәтә. Димәк, биредә үзәктә бер герой һәм аның белән бәйле вакыйгалар тезмәсе бар. Бу инде сюжетның бер сызык белән хәрәкәт итүен күрсәтүче төп билге.

Әйе, әсәрдә вакыйгалар, күренешләр байтак. Аларның һәммәсен Кол Гали сурәтләве белән чагыштырып караганда бик күпкә китәр, әлеге монографиянең артык зураеп китүенә китерер иде. Ул вакыйгаларның иң мөһимнәрен санап кына чыгу өчен дә хәйран вакыт кирәк: Йосыфның төш күрүе; Йагкубның төш юравы; Йагкубның бүре белән сөйләшүе; Йосыфны коега салу; Ана кабере янында елау... Һәм, ниһаять, Йосыф белән Зөләйханың үлүе; Әсәрнең хатимәсе. Алар өч дистәгә тула. Әмма боларның һәрберсенең йә Кол Галидәгечә, яки башка авторларда бүтәнчә сурәтләнүен карап, билгеләп чыкмыйча гына, төрки «Йосыфнамә»не җентекләүгә багышланган тикшеренүне тулы итеп күз алдына китерү мөмкин түгел. Н. Хисамов боларны бөртекләп эшләп чыккан. Монографиядә исә бу чагыштыруларның кайберләрен генә эзлекле итеп яктырту юлыннан киткән. Чөнки гыйльми китапның тема белән билгеләнгән аерым бер чикләре бар. Шуңа күрә бәян итүнең нindидер бер чамасы белән

канәгатьләнергә туры килгән. Шулай да, теге яки бу мәсьәләдә бәхәс туган, яки исбатлау өчен төгәллек таләп ителгән очракта, галим арсеналында сюжетның һәр борылышы уңаеннан ясаган нәтиҗәләре әзер. Бу — хезмәттә даими сизелеп тора. Алар алга таба шулай ук җае белән фәнни җәмәгатьчелеккә җиткерелер дип уйларга кирәк.

Шулар арасыннан аеруча җәлеп иткәне әсәр сюжетының төенләнешен тәэмин иткән «Йагкубның төш юравы» күренешен, төрле версияләрдә сурәтләү үзенчәлеген күзәтүе, дип атарга кирәктер. Чыннан да, алга таба бәян итү өчен бу күренешнең әһәмияте шулкадәр зур, дөресен әйткәндә, Йагкуб бу урында, үз сүзләре белән әйткәндә, җаны кебек яраткан улының башыннан нинди хәлләр кичерәсен алдан күрәзәләп куя. Әйтерсең лә, ата улына карата «Ләүхелмәхфүз»дә язылганнарны икърар итә. Бу вакыйга Коръәндә бик кыска гына бирелә. Кол Гали шушы монологны сәнгатьчә тәэсирле, образлы сөйләмгә әверелдерә. Коръәндә бәян ителгәннәргә шактый үзгәрешләр кертеп, бигрәк тә хикәяләргә Зөләйха образын өстәгән фарсы шагыйре Фирдәүси версиясеннән этәрелеп эш иткән Кол Гали төрки сүз сәнгате хасиятләренә дә эзлекле нигезләнгән. Шуңа күрә аның әсәре башка төрки авторларга аеруча якын һәм аңлаешлы булган да. Югыйсә, ул гасырлардагы төрки каләм осталары өчен фарсы әдәбияты белән дә азыклану гадәти хәл саналган. Әмма бу очракта тел буенча гына түгел, сәнгатьлелекнең башка чараларында да төркичелекне табигый куллану ягыннан безнең татар-болгар шагыйре билгеле дәрәҗәдә үрнәк булып торган. Шунысы игътибарны җәлеп итә, Кол Гали әсәре Якын Шәрык төбәкләрендә, хәтта Кара диңгез артында да билгеле булган, ягъни шул җирлекләрдәге шагыйрьләр дә аны белгәннәр, иҗатларына өлге итеп алганнар. Ул гасырларда китапларның кулдан күчерелеп таралганлыгын искә алсаң, Кол Гали әсәренең төрле җирлекләрдә никадәр билгеле булганлыгын күреп, гаҗәпләнергә генә кала. Үз заманында гына түгел, язылуына җиде-сигез гасыр үткәч тә киң таралыш ягыннан «Кыйссаи Йосыф»ка тиң әсәрне табу кыен.

Инде башлаган сүзебезнең җеп очына кире кайтып, Н. Хисамов аеруча җентекләп тукталган «Төш юрау» күренешенең аерым төрки авторларда төрлечә сурәтләнүенең үзенчәлекләренә игътибар итик. Моның үзәгендә Кол Гали версиясе торуын Н. Хисамов шулай ук җентекле күзәтә. Аның гөманынча, әлеге күренешне детальлерәк һәм тормышчанрак итүдә Габдуллаһ Әнсари үрнәге аеруча йогынтылы. Кол Гали аңардагы чәчмә белән язылган сурәтләнешне тезмә белән биреп, шагыйрьләргә хас тирбәлешләр өсти, күренешнең тәэсирлерәк бирелүенә ирешә. Дөрес, Г. Әнсаринең чәчмә сөйләме дә укучыларга шигъри әсәр кебек тәэсир иткән икән. Әйтик, Дүрбәк тә аның әсәрен шагыйранә сурәтлелеге өчен яраткан. Кол Гали дә Г. Әнсаридәге байтак өлешләрне тезмәгә салу юлынан киткән, чөнки аларда ул чын мәгънәсендә шигърият күргән. Төрки «Йосыфнамә»нең тууында һәм кардәш әдәбиятларның тизләтелгән үсешендә, шул рәвешле, «Әнисел-мөридин вә шәмсел-мәҗалис» («Мөридләрнең дусты һәм мәҗлесләр кояшы») әсәренең әһәмияте чиксез. Бу — Н. Хисамов тикшренүләрендә ясалган төп нәтиҗәләрнең берсе. Кол Гали элгәре

Г. Әнсари версиясендәге гади генә сөйләп бирүләрне шагыйранә нәфисләүдә, детальләштерүдә, ягъни иҗади якын килүдә беренче юл салучылардан. Сюжетның төп интригасын тәэмин итә торган юраманы, ягъни Йосыфның киләчәктә идарәче булачагын әйтүне, алай гына да түгел, «нәбилек һәм рәсүллек алачаксың, һәм мәмләкәт иясе булачаксың» дигән хәбәрне җиткерүнең, Г. Әнсари әсәрендәгегә караганда, ата авызыннан үтә җылылык белән әйтелүе игътибарны җәлеп итми калмый. Бу Йагкубның Йосыфны башка улларына караганда аерып яратканлыгын раслый. Аның «җаным угыл» дип эндәшүе генә дә моның шулай икәнлегенә ишарә.

Н. Хисамов Кол Галигә Г. Әнсаринең зур тәэсирен күрсәтсә, Шәййад Хәмзә белән Сули Фәкыйһны исә «турыдан-туры Кол Галинең дәвамчылары» дип атый. Әйтик, шул ук төш юрау күренешенең Шәййад тарафыннан Кол Галичә бирелүен искәртә, аерымлык бар икән, аларның кайбер атамаларда гына булуын билгели (мәсәлән, «Солтанлыкта үтәр гомereң») [Хисамов, б.37]. Шулай ук текстның кайбер кыскартуларга дучар ителүе дә галимнең игътибарыннан читтә калмаган. Сули Фәкыйһ исә, Ш. Хәмзәгә якынрак булуга өстенлек бирсә дә, Н. Хисамов билгеләвенчә, «Кыйссаның эмоциональ төсмерен тагын да көчәйтеп, төрки әдәбиятта сюжетны башлап ачучы элгәресе (ягъни Кол Гали — *Ф.Г.*) эзеннән китә» [Хисамов, б.38]. Әлбәттә инде, мөстәкыйль хәл ителгән урыннар да бар, алар билгеле күләмдә сюжетның да үзгәрешен китереп чыгаралар. Мәсәлән, Кол Галидә Йагкуб башка балаларының киләчәктә Йосыфка хезмәт итәчәкләрен әйтсә, С. Фәкыйһта, алар Йосыфка кол булачаклар, диелә. Бу инде балалар арасындагы мөнәсәбәтләрнең тагын да кискенләшүенә китереп чыгара.

Н. Хисамов хезмәтенең тагын бер яңалыгы — анда төрекләрнең әлегә үзләренә дә мәгълүм булмаган шагыйрь Әхмәдинең «Йосыф вә Зөләйха» поэмасы контекстка кертелә. Әсәрнең әлегә бердәнбер билгеле тексты профессор Г. Таһирҗановта сакланган. Ленинградта яшәгән бу галимебез әле 1976 елда ук Алма-Атада узган төрки конференциядә бу әсәр турында махсус доклад ясаган булган. XIV йөздә язылган бу төрдәш төрки «Йосыфнамә»гә тагын бер затлы өлеш булып тора. Ул С. Фәкыйһ белән Хәмди версияләре арасында билгеле бер күпер хезмәтен үти. Әхмәди поэмасы, Ш. Хәмзә һәм С. Фәкыйһ төрдәшләренә караганда, үзенең Кол Галигә якынрак иҗат ителгәнлеге белән үзенчәлекле икән. XV йөз шагыйре Хәмдинең исә, Кол Галидән бигрәк, Җами традицияләренә барып тоташуын билгеләү өчен дә Н. Хисамовка чагыштыру планында бөртекләп эшләргә туры килгән. Хәмди, монография авторы раславынча, гомумән, «элгәрләреннән тәвәккәл рәвештә котылу» [Хисамов, б. 45] юлыннан китеп, үзенә бер төрдәш барлыкка китергән. Йосыфның үги агаларының үчлелеген алгы планга чыгарып, драматизмны тагын да үткенләндергән.

Йосыфның гарәп сәүдәгәрләре аша атасына хәбәр җибәрүе эпизодын чагыштырып карау ярдәмендә дә тикшерүче бик кызыклы күзәтүләр ясый, бер үк сюжетның төрле төрки авторларда күптөрле һәм һәрберсе үз мохите, үз карашлары яктылыгында үзенә бер рәвештә тасвирлануын ача. Нәтиҗәдә Кол Гали-

нең болгар-татар әдәбиятына гына түгел, гомумән төрки әдәбиятлар үсешенә этәргеч биргән шагыйрь икәнлеге раслана. Хезмәттә төрле гасырларда яшәгән һәм иҗат иткән шагыйрьләрнең «сәнгатьлелек традицияләренең үсеше барышында» «Йосыфнамә»не тагын да камилләштерү юнәлешендәге иҗади хәрәкәтләре күрсәтелә. Борынгы әдәбиятта иркен кулланылган нәзыйрә алымының иҗади ярыш мөмкинлеген бирүе тагын бер тапкыр раслана.

Шул рәвешле, Шәрыктан күп йогынты алып тармакланып үскән татар әдәбиятының төрки дөнья әдәбияты үсешенә үзенең дә җитди тәэсир иткәнен күрсәтү җәһәтеннән Н. Хисамовның сүз бара торган китабының әһәмияте зур. Аның Төркиядә бу ил халкы телендә (дөресендә барлык төрки халыклар өчен аңлаешлы телдә) дөнья күрүе әлеге хезмәттә бәян ителгәннәрнең даирәви офыкларын тагын да киңәйтә. Монографиянең кыйммәте барыннан да элек шуның белән билгеләнә.

**Әдәбият**

*Әхмәтҗанов М.И.* Кол Гали һәм «йосыф китабы» // Мәдәни җомга. 2014. 11 июль. Б. 14—15.

Коръән тәфсире (Ногмани). Казан: Ислам динен кабул итүенә 1000 ел тулу хөрмәтенә салынган Кабан арты мәсҗеде. 1992. Б. 259.

*Таһирҗанов Г.* Тарихтан — әдәбиятка. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. Б. 91.

*Хисамов Н.* Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә». Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.

***Галимуллин Фоат Галимулла улы**, филология фәннәре докторы,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры*

# АЙДАР ГАЙНЕТДИНОВ. АДНАШ ХАФИЗНЫҢ «СИРАҖЕЛ КОЛҮБ» ӘСӘРЕ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА АНЫҢ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

Безнең дәвер мәгълүмати яктан киң кырлы булуы, басма китапларның бай төрлелеге, язма хезмәтләрнең муллыгы белән аерылып тора.

Әмма тарих чоңгылларына, үткән гасырларга тирәнрәк кагылган саен без мондый чыганакларның, язма мирасның ярлылыгын ныграк тоя барабыз. Бу хәл бигрәк тә татарларда кискен төс алган, чөнки гасырлар буе тупланган кулъязма истәлекләрнең шактый өлешенең төрле милли һәм тарихи сәбәпләр белән юкка чыгарылуы һәркайсыбызга мәгълүм. Шуңа күрә безнең өчен һәм документ, һәр басма хезмәт, һәр әсәр, хәтта алардан ертылып төшкән кәгазь кисәге дә зур кыйммәткә ия. Дөрес, соңгы дистә елларда татар халкының рухи мирасын барлап өйрәнүдә билгеле бер дәрәҗәдә уңышларга ирешелде, шулай да тарихыбызның ачылмаган битләре, милли язма хәзинәләребезнең ачыклыйсы өлкәләре байтак әле. Фән өчен күптән мәгълүм тарихи ядкарьләребезнең әлегә хәтле монографик планда тикшерелмәгәннәре күп, аларны бүгенге укучы аңламый, кабул итә алмый. Шундый китапларның берсе — Аднаш хафиз тарафыннан язылган «Сираҗел колүб» әсәре (ул аны 1554 елда Мәскәү зинданында ятканда тәмамлаган). Шуны да әйтеп үтү урынлы булыр, заманында бу хезмәтне җитди өйрәнеп тикшерүгә Әмир Нәҗип (1899—1991) һәм Мәсгут Гайнетдинов алыналар. Бу могтәбәр галимнәрнең әйткән фикерләре һәм фаразлары тагын да тирәнәйтүне, киңәйтүне көтеләр. Әлеге монографиянең язылуына да нәкъ менә шушы фәнни һәм гамәли ихтыяҗ сәбәп булгандыр.

«Сираҗел колүб» — жанр ягыннан «тартмачыл композиция» әсәрләре төркеменә карый. Ул чагыштырмача мөстәкыйль хикәятләрдән, композицион берәмлекләрдән гыйбарәт. Аның язылышында интертекстуаль принцип зур роль уйнаган. Шуңа күрә мондый хезмәтләрне анализлаганда чыганакларны ачыклау, алынма материалларның үзләштерелү характерын билгеләү мөһим. Әлеге монографиядәге «Сираҗел колүб» әсәренең чыганаклары һәм структур бүленеше» дип аталган беренче, төп бүлеге нәкъ менә шушы бурычларны ачыклауга багышланган.

В.Бартольд, А.Щербак раславынча, бу исемдәге әсәр иң элек гарәп телендә язылган булган. Аннан соң фарсычага күчерелгән. Аның төрки телләрдәге версияләре дә булган. Аднаш хафиз, ягъни «Аднаш хафиз бине Мөхәммәд-Аднаш хафиз» төрле телләрдәге текстлар һәм вариантларга нигезләп үз әсәрен иҗат иткән. Айдар Гайнетдинов, «Сираҗел колүб» Коръән материалларыннан, пәйгамбәребезнең хикмәтле сүзләреннән файдаланып язылган, дип белдерә. Монографиядә Әхмәд бине Хәнбәл, Мөхәммәд бине Исмәгыйль әл-Болгари, Мөслим бине Хәҗәҗ (ән-Нишапури), Мөхәммәд бине Гайсә әт-Тирмизи һәм башка күренекле дини эшлеклеләрнең хәдисләре җыентыклары тасвирлана. Болардан тыш, Аднаш хафиз әсәрендә Борһанетдин Рабгузи, Мәхмүд Болгари, Хисам Кятиб хезмәтләре, шулай ук «Мәлики китабы» белән ге-

нетик һәм типологик яктан охшаш материаллар (сюжет, образлар, мотивлар...) да бар. Айдар Гайнетдинов үзенең монографиясендә үзенчәлекле хикәятләрне, мотивларны чагыштырма планда анализлый, төрки-татар авторы керткән теге яки бу үзгәрешләргә, яңалыкларга махсус туктала. «Сиражел колүб»нең идея-тематик эчтәлеге аның структурасы һәм чыганаклары белән тыгыз элемтәдә карала. Мәгълүм булганча, бу әсәр татар тарихының фаҗигале дәверендә иҗат ителә. Монография авторы фикеренчә, Аднаш хафиз яңа, катлаулы вазгыять шартларында үз укучыларына киңәш бирергә омтыла. Монографиядә, бик кыскача формада гына булса да, китаптагы суфичыл мотивлар да яктыртылган. Беренче бүлектә шулай ук «Сиражел колүб»нең кайбер поэтик үзенчәлекләре турындагы фикерләр дә урын алган. Әйтик, дөньяви һәм ахирәт тормышы турында мифологик кузаллаулар тудыра торган образлар, детальләр яктыртыла, аларны автор диалог формасында, антитеза ысулы белән бирә; әсәрнең синкретик табигате ассызыклана; җәнлекләр, кошлар һ.б. «теле»н мавыктыргыч итеп анализлый.

Икенче бүлектә XVII—XVIII гасырлар татар әдәбиятында «Сиражел колүб» традицияләренең дәвам итүе белән бәйле проблемалар күтәрелә. Колониаль хакимият тарафыннан татарларга карата үткәрелә торган христианлаштыру сәясәте Аднаш хафиздан соңгы дистә еллар дәвамында тагын да көчәя. Мондый социаль-сәяси һәм иҗтимагый шартларда татар халкын, мөстәкыйль этнос буларак, саклап калу иң актуаль бурычларның берсе санала. Менә шуңа күрә дә «Сиражел колүб» нигезенә салынган идеяләр алдагы гасырларда татарлар өчен бик якын була. Бу халкыбызның рухи елъязмаларында, аерым алганда, Мәүлә Колый, Суфи Аллаһияр, Таҗетдин Ялчыгол иҗатларында киң чагылыш таба. Чыннан да XVII гасыр шагыйрьләре хикмәтләрендә үзләренең элгәрләре тудырган образлар, детальләр, мотивлар еш очрый. Мәүлә Колый, мәсәлән, сабырлыкка, Аллаһка таянырга өнди. Суфи Аллаһияр иҗатында да (аеруча «Сөбател-гаҗизин» поэмасында) без шул ук күренешкә тап булабыз, Идел — Урал буйларында яшәүчеләр өчен ул аеруча зур популярлык казана. Аднаш хафиз белән Таҗетдин Ялчыгол әсәрләренә аһәңдәшлек һәм охшашлык хас.

Шуны ассызыклау мөһим, Айдар Марсил улы Гайнетдинов тарафыннан сайланган тема гадәттән тыш үзенчәлекле, аны яктырту өчен филология һәм әдәбият белеме буенча әзерлек кенә җитми, монда татар халкының тарихын, мөселманнарның дини канунарын, суфичылыкны яхшы белү, гарәп, фарсы һәм төрки телләр белән таныш булу, гарәп графикасындагы текстлар (аеруча кулъязмалар) өстендә эшләү күнекмәләренә ия булу мөһим. Монография белән танышып чыккач, авторның бу өлкәләрдә билгеле бер дәрәҗәдә әзерлекле икәнлегенә төшенәсең, һәм бу аңа тикшерену эшен кирәкле юнәлештә, тиешле фәнни-теоретик дәрәҗәдә башкарып чыгарга мөмкинлек ачкан.

***Миңнегулов Хатыйп Йосыф улы**, филология фәннәре докторы,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры*

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**Казан (Идел буе) федераль университетының Халыкара багланышлар, тарих һәм Шәрыкны өйрәнү институты вәкилләре Япониянең Симанэ префектурасы университетында уздырылган семинар эшендә катнаштылар.**

Танылган тюрколог һәм монголовед, лингвист, профессор Хаттори Сиро (1908 — 1995) архивының әлеге университет китапханәсендә саклануы Казан галимнәренең кызыксынуын уятырлык фактор булып тора. Профессор Диләрә Госманова, доцент Лариса Усманова һәм Ш. Мәрҗани исем. Тарих институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Марат Гибатдинов составындагы делегация сәфәренең төп максаты — Хаттори Сиро архивы фондларында татар тарихы һәм төрки-татар филологиясенә кагылышлы материаллар табу иде.

Токио университетының мәртәбәле профессоры Хаттори Сиро озак еллар буе Япония телчеләр җәмгыятен җитәкли. Ул танылган лингвист һәм урал-алтай телләре, шул исәптән татар теле белгече. Аның тормыш иптәше Маһира Агиева тырышлыгы белән гаилә архивында «Милли байрак» газетасының (Мукден шәһәрендә 1936—1945 елларда басылган) тулы диярлек комплекты, татар китаплары (шул исәптән эмиграциядә басылганнары да) сакланган. Галимнең вафатыннан соң аның варислары архивны Симанэ префектурасы университетына тапшыралар.

Архив материалларын тикшерү мәсьәләсенә багышлап 28 июнь көнне аерым семинар үткәрелде. Семинардан соң Татарстан галимнәре Токиода 1920—1930 елларда татар общинасы лидеры булган Рәшид Ибраһим каберен зиярәт кылдылар.

Сәфәр дәвамында Казан галимнәре Токио университеты, Токио чит телләр университеты, Симанэ префектурасы университеты, Хоккайдо университеты белән таныштылар. Бу танышу шактый кызыклы һәм мәгълүмати булды. [http://kpfu.ru/news]

**2014 елның 14 августында VI Халыкара Болгар форумы ачылды.**

Татарстан инициативасы белән оештырылган әлеге форум ел саен Болгар цивилизациясенең тарихы, мәдәнияте белән шөгыльләнүче белгечләрне берләштерүне максат итеп куя. Соңгы ике ел эчендә ул Россия, Украина, Болгария, Венгрия, Молдова, Казакъстан һ.б. илләрнең галимнәре арасында фикер алышу, тәҗрибә уртаклашу үзәгенә әйләнеп китте. Моннан да бигрәк бу форум иҗтимагый-тарихи әһәмияткә дә ия. Татарстан территориясендә яшәгән халыклар арасында мәдәни һәм иҗтимагый хезмәттәшлек турында тарихи хәтер саклау — күпмилләтле һәм күпконфессияле Татарстанның ныклы үсеше өчен төп һәм зарури нигез булып тора.

**28—29 август көннәрендә «Казан — төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы» программасы чараларының берсе — төрки әдәби журналлар форумы булып узды.**

Татарстан Язучылар берлегендә оештырылган кичәдә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге җитәкчесе М.Х. Вәлиев чыгыш ясап, Татарстан Фәннәр академиясе быел гына гамәлгә куйган «Фәнни Татарстан» журналын якын һәм ерак чит илләрдән, Россия төбәкләреннән килгән төрки кардәшләребезнең гыйльми һәм әдәби җәмәгатьчелегенә тәкъдим итте, төрки халыкларның әдәбиятын өйрәнүдә Институт галимнәренең соңгы еллардагы эшчәнлеге белән таныштырды.

**2014 елның 3—4 сентябрь көннәрендә Казан (Идел буе) федераль университетында төрки дөньяның XII халыкара иҗтимагый фәннәр конгрессы булып узды.**

Конгресс барышында Төркия, Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Казакъстан, Кыргызстан, Македония, Иран, Әфганстан һәм Россиянең төрле төбәкләреннән килгән фән эшлеклеләре гыйльми тикшеренүләренең нәтиҗәләре белән таныштырдылар. Анда шулай ук төрки илләрнең тарихы, мәдәнияте, икътисады, сәясәте мәсьәләләренә багышланган проблемалар да күтәрелде. Конгрессның төп координаторы Әхмәт Вәҗи Җан ассызыклаганча, әлеге фәнни чараның төп максаты — бергәләп башкара торган проектларның санын арттыру, төрки халыклар арасында дуслык һәм хезмәттәшлек җепләрен ныгыту.

**2014 елның 13 сентябрендә Казан (Идел буе) федераль университының Актлар залында университетта тарихи дисциплиналар укытыла башлауның 210 еллыгы, тарихи белем бирүнең 80 еллыгына багышланган тантаналы чара булып узды.**

Әлеге чара Казан университетының 210 еллыгына да багышланган иде. Кичәдә «Тарих», «Сәнгать тарихы» юнәлешләре буенча Укыту-методик советы вәкилләре, халыкара багланышлар буенча проректор Линар Наил улы Латыйпов, Халыкара багланышлар, тарих һәм Шәрыкны өйрәнү институты җитәкчеләре, студентлар катнашты.

Казан университетында тарихи белем бирүнең башлангычлары һәм үсешенә багышланган чыгышында Тарих, Шәрыкны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты җитәкчесе, тарих фәннәре докторы Алла Сальникова билгеләп үткәнчә, бүгенге көндә Казан университеты тарихчылары Германия, Италия, АКШ университетелары белән берлектә төрле халыкара проектларда уңышлы эшләп киләләр. Традиция һәм яңалыкларың, эксперимент һәм интеллектуаль капиталның бердәмлеге Казан университетында тарих фәне үсеше өчен ныклы нигез булып тора.

**2014 елның 4 сентябрь көнендә Россия ислам университетында «Якупов укулары» сериясеннән 3 нче конференция булып узды.**

Конференция барышында татар традицияләрен, танылган дин белгече, җәмәгать эшлеклесе Вәлиулла Якуповның тормыш юлын һәм хезмәтләрен яктырткан 15 ләп доклад укылды.

**2014 елның 23—24 сентябрь көннәрендә Казанда «Төрки халыклар әдәбияты һәм музыка сәнгатенең тамырлары һәм үсеше» дип исемләнгән халыкара фәнни-гамәли конференция булып узды.**

Әлеге чара «Казан — төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы» программасы кысаларында Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты һәм Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе тарафыннан оештырылды. 2014 елда танылган төрекмән шагыйре һәм фикер иясе Мәхтүмколый Фирагыйның тууына 290 ел тулуны һәм, шуңа нисбәтән, 2014 елның ТҮРКСОЙ тарафыннан Мәхтүмколый елы дип игълан ителүен исәпкә алып, конференциянең бер секциясе Мәхтүмколый иҗатына багышланган иде. Конференция эшендә, Россиянең төрле төбәкләреннән килгән галимнәр белән бергә, Иран, Төркия, Төркмәнстан, Үзбәкстан, Азәрбайҗан вәкилләре дә катнашты.

Конференция барышында яңа гына чыккан ике китапны — филология фәннәре докторы Нурмөхәммәт Хисамовның «Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә» (XIII—XV йөзләр)» хезмәтен (Әнкара, 2014; төрек телендә) һәм Мәхтүмколый Фирагыйның шигырьләр җыентыгын (Казан, «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты, 2014; татар телендә; җыентыкны төзүче һәм кереш сүз авторы Р.М.Миңнуллин) фәнни җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү дә булды..

***Мөхтәрәм авторлар!***

«Фәнни Татарстан» журналы татар теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере темаларын яктырткан мәкаләләрне бастырып, киң җәмәгатьчелеккә таратуны күздә тота.

Материалларга түбәндәге таләпләр куела:

Мәкалә тексты *.doc. форматында җыела, аерым хезмәтләрдән алынган өзекләр, сылтамалар автор тарафыннан җентекләп тикшерелә. Файл автор фамилиясе белән исемләнә (Әхмәтов. doc).

Мәкаләгә түбәндәге мәгълүматлар өстәлә:

— авторның фамилиясе, инициаллары

— мәкалә исеме

— аннотация (рус телендә)

— төп сүзләр (рус телендә)

— сылтамалар.

Мәкаләдән тыш, *.doc форматында аерым файлда автор турында мәгълүмат җибәрелә (исеме, әтисенең исеме, фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, эш урыны, вазифасы, электрон адресы һәм телефоны).

Сылтамалар текст азагында ГОСТ Р 7.0.5-2008 таләп иткәнчә алфавит тәртибендә урнаштырыла.

Мәкалә белән бергә аңа карата фән докторы яки фән кандидаты тарафыннан язылган рецензия җибәрелә.

Редакциягә килгән мәкаләләр шулай ук бәйсез рецензияләүгә тәкъдим ителә, мәкаләне басмага алу-алмау аның нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә.

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31, 3 нче кат, 133 нче бүлмә
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 292-76-59
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

*Уңышлар теләп һәм Сезнең белән хезмәттәшлек итүебезгә өмет баглап,*
*«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе*

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2014. № 3

Бизәлеш авторы
*Э. Бәшәрова*

Басарга кул куелды: 12.11.2014.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,25. Тираж 500. Заказ К-15

Журнал Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында
нәшер ителде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 292-76-59
E-mail: f_tatarstan@mail.ru